Мәдәни җомга

www.madanizhomga.ru

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 41 (1406) 21 октябрь 2022 ел

1995 елның июленнән башлап чыга

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:

madani_zhomga madanizhomga

madani_zhomga



8

Атаклы биюче Рудольф Нуриевнең чит илдә калу теләге шулкадәр көчле була ки, хәтта үз-үзенә кул салу белән куркыта.

12

Рәссам Рәшид Әсәдуллинның дуслары, хезмәттәшләре аны искиткеч эш сөючән, чын оста кул дип искә ала.

24

«Әкият» театрының Т.Миңнуллин әсәре буенча куелган «Авыл эте Акбай» спектакле чыннан да курчак тамашасы булуы белән куандыра.

Татар Яңарышын кыйбла иткән Ике Габдулланың берсе ул!

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Татарстан Язучылар берлегенең Чаллы бүлегендә Факил Сафинның иҗат студиясе ачылды.
- Төмән өлкәсе Пышны (Муллаши) авылы татар теле укытучысы Азалия Габдрәхимова Россия Президенты премиясенә лаек булды.
- Ноябрь аеннан Г.Кариев театрында «ӘйдәБас» татар биюен үстерү остаханәсе – педагог һәм хореографлар өчен татар биюенең төбәк үзенчәлекләре турында түләүсез уку-укыту атнасы башлана.
- Татар китабы йортының «Гыйлемле Йорт» лекториенең тәүге лекциясе борынгы грек дине һәм фәлсәфәсенә багышланды.
- Санкт-Петербург дәүләт кино һәм телевидение институтында «ПитерКиТ» Халыкара студентлар фильмнары фестивале кысасында «Төбәк кинематографының уңышлы тәҗрибәсе. Татарстан киносы көне» узды.
- Екатеринбург дәүләт академия опера һәм балет театры Нурбәк Батулланы П.И.Чайковскийның «Черевички» операсында биюләр кую өчен чакырган.
- Самара өлкәсенең Похвистнево районы Яңа Мансур авылында, үз тарихында бер тапкыр да сүтелмәгән мәчеткә нигез салынуга 235 ел тулуга багышлап, бу мәчет турында мәгълүмати такта куелды.
- Бөгелмә шәһәрендә «Милли моң» Россиякүләм мөнәҗәтләр фестивале үтте.
- Костромадагы Изге Троица Ипатий ир-атлар монастырендә татарлар тарихы турында «Бер җеп белән бәйләнгәннәр» дип исемләнгән күргәзмә ачылды.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Марат ӘХМӘТОВ, Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары:

«Беркем өчен дә сер түгел: телне саклау өлкәсендә җитәкчеләрнең шәхси үрнәге бик мөһим. Телләгән нәтиҗәне бирмәсә дә, Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты базасында дәүләт органнары җитәкчеләре өчен узган «Татар теле: рәсми чыгыш» курслары да шул максаттан оештырылган иде. Бүгенге көндә сиксәннән артык министр урынбасары татарча чыгыш ясау серләренә өйрәнә. Шулай ук КФУ базасында Казан, Чаллы һәм Алабуга шәһәрләрендә татар телен өйрәнергә теләүче һәркем өчен бушлай курслар эшли».

СЫНАМЫШЛАР

Көз озын килсә, яз соң килер ● Суганның кабыгы ике кат булган елны кыш җылы килер, ә кабыгы күп катлы икән – кыш салкын булыр ● Октябрь аенда кояш тотылса, киләсе апрель-майда яңгыр ямаc ● Агач яфракны соң койса, ел авыр килә.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **6 сәгать 26 минутта** чыкты, һәм ул **16 сәгать 29 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **10 сәгать 03 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **30 минутка кыскарачак** һәм киләсе җомгада, ягъни **28 октябрьдә 9 сәгать 33 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

21 октябрь – биюче һәм хореограф, Башкортстанның һәм Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе, Салават Юлаев исемендәге премия лауреаты Фәйзи Гаскәровның тууына 110 ел (1912–1984);

– шагыйрә Илзирә Сәмигулла кызы Шаһиевага (Вәлиуллина) 50 яшь (1972).

22 октябрь – шагыйрә Лилия Рәфхәт кызы Фәттаховага 50 яшь (1972).

23 октябрь – театр белгече һәм тәнкыйтьчесе Дания Әхәт кызы Гыймрановaның тууына 85 ел (1937–2014).

24 октябрь – Берләшкән Милләтләр Оешмасы көне.

27 октябрь – язучы, журналист Рөстәм Зәет улы Зариповка 70 яшь (1952).

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Октябрьнең магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Бу атнада андый магнитлы көн юк.**

* * *

Гадәттә, айның соңгы чирегеннән яңа айга кадәр **(17-25 октябрь)** организм киңәюгә бара. Мондый көннәрдә юан эчәклекне чистартуга бәйле процедуралар үткәрү файдалы.

Шунысын да онытмагыз: **14 августтан 24 октябрьгә кадәр** үпкә һәм юан эчәклек актив булучан. Шушы вакыт аралыгында аларны ныгыту һәм дәвалау уңай нәтиҗәләргә китерә.

###ҺИҖРИ БУЕНЧА 1444 ЕЛ

Бүген рабигүл әүвәл аеның 25 нче көне

ҖАН АВАЗЫ

Фәрзәнә КУЛИЕВА

Университетны кулдан ычкындырдык

Ерактагы Иртыш ярларында урнашкан Омск өлкәсенең Тара шәһәрендә татар урта мәктәбен 1960 елда алтын медальгә тәмамлап, Казан дәүләт университетының физика-математика факультетына укырга кердем. Аннан соң 40 ел югары математиканы КАИ, КХТИ һәм ТМУ студентларына укыттым. 1993 елның 20 нчы сентябрендә татар халкының тарихында беренче мәртәбә иҗтимагый нигездә ачылган Татар милли университетында (ТМУ) һәм КХТИда югары математиканы татар телендә укыта алуыма бик бәхетлемен. Татар халкының бер төркем дәртле кешеләре үз җилкәләренә авыр йөк алды: без ике урында эшләдек – төп эш урынында эшләп хезмәт хакы алдык, ә ТМУда түләүсез хезмәт иттек. Студентлар шулай ук түләүсез укыды. Югары квалификацияле укытучылар икътисад, филология, тарих-археология, технология, медицина җиһазлары һәм юридик факультетларында 700 гә якын студентларыбызга белем бирде. Алар арасында Фәннәр академиясенең өч әгъза-корреспонденты, фән докторлары һәм кандидатлар, шулай ук төрле югары уку йортларында эшләүче тәҗрибәле укытучылар дәресләр алып барды. 20 ел элек бомж дигән атама юк кебек иде, ә без ул вакытта инде бомжлар идек, чөнки укыту өчен үз бинабыз булмады. Шуңа күрә лекцияләрне, практик һәм башка дәресләрне Казан шәһәренең төрле урыннарында үткәрергә туры килде: Казан дәүләт университетында, КАИда, КХТИда, Казан педагогика институтында, авыл хуҗалыгы, төзелеш институтларында, 6 нчы номерлы татар гимназиясендә. Аның директоры Таң Мәхмуд улы Еникеев безнең белән бергә борчылды, студентларга гимназиянең акт залын, иң уңайлы классларын тәкъдим итте. Укулар Школьная урамындагы 4 нче мәктәптә дә, хәтта Мәгариф министрлыгында да барды. Минем күз алдымда мәсхәрәле күренеш: бүлмәгә сыймаган студентлар коридор идәнендә тезләнеп утырып лекция яза! Такта янындагы укытучыны ачык ишек аша тыңлыйлар, нинди аяныч күренеш! Иң фаҗигалесе: без бит Мәгариф министрлыгында шундый уңайсызлыклар кичерәбез. Безнең туган илнең Мәгариф министрлыгы беренче чиратта татар тарихында тәүге ТМУга ярдәм оештырырга тиеш иде түгелме? Әйе, андый «зур ярдәм» булды – бер-ике мәртәбә лекция үткәрергә бүлмә бирелде. Себердән минем янга яшәргә кайткан 88 яшьлек әнием өйдә ялгызын калдырып, укытулардан тыш берөзлексез ТМУ эшләрен канунлаштыру өчен ярдәм сорап, төрле даирәләрдә йөрдем.

Милли университет эшчәнлегенә кирәк чакта ярдәм итәргә мөмкинлекләре булган кайбер кешеләр татар телен саклап калуда хәзер фәлсәфә оештыра, моны күзәтү үк хурлык. Ярдәм сораганда мөмкинлекләре була торып та, кул селтәделәр, ләбаса! Алардан яклау да, ярдәм дә, акыллы тәкъдим дә булмады.

Милли университет эшләү елларындагы бер туры эфир вакытында Татарстанның бер җитәкчесенә сорау бирдем: «Кайчан Татар дәүләт милли университетын рәсми төстә ачарсыз да, дәүләт тәэмин итүенә куярсыз икән?» 1990 елда бу университет Татарстан дәүләт программасына кертелгән иде. Ахыр чиктә, 1995 елда рәсми статус – дәүләт статусы бирергә тиеш иделәр. Безнең югары дәрәҗәдәге чиновник тупас кына: «Безнең укытучылар да, дәреслекләр дә, кулланма әсбаплар да юк» – диде. Ничек булмасын? ТМУ эшли, димәк укытучылар, студентлар бар. Дәреслекләр дә җитәрлек: Гали Даутов физика-математика фәне докторы, профессор, КАИда физикадан татар телендә 4 томлы дәреслек язды. КХТИ галимнәре Абрик Вәлиуллин – сопроматтан, Г.Хисамиев – химиядән, төзелеш институтындагы Р.Шакирҗанов – теоретик механикадан китаплар әзерләде. Ә мин, Р.А.Рәхмәтуллин белән бергә ике дәреслек: беренчесе – «Сызыкча алгебра һәм аналитик геометрия элементлары», икенчесе – «Дифференциаль исәпләү». «Интеграл исәпләү» дәреслеген төгәлләп бетерә яздык. КДУда Равил Һади информатикадан ике дәреслек язды. Алда санап үткән бар дәреслекләр дә татар телендә нәшер ителгән. Ә Гөлнара Арсланова инглиз теленнән татар теленә күчереп, ТМУ студентлары өчен методик кулланмалар, күнегүләр әзерләде. Әйтелгән дәреслекләр, кулланмалар авторлары барысы да безнең ТМУда укытты. Шулай итеп, безнең ана телебездә югары математика, физика, химия, инглиз теленнән, информатика, сопромат һәм башка фәннәрдән, һәрбер югары уку йортында зарур булган уку-укыту, календарь планнары, һәр факультетның дәрес расписаниеләре булдырылды. Кыскасы, укыту өчен барлык мәсьәләләр хәл ителгән иде. Без бит тәҗрибәле укытучылар, деканнар, уку-укыту мөдирләре идек, иң мөһиме, безнең энтузиазмга теләсә кем көнләшерлек иде. ТМУның ачылуы зур резонанс (яңгыраш) тапты. Безнең университетта чит төбәкләрдән, башка милләттән булган шәкертләр дә белем алды. Татарстанның Илфат Фәйзрахманов, Римма Ибраһимова һ.б. кебек билгеле кешеләре дә икенче югары белем үзләштерде. Университет тулы канлы тормыш алып бара иде. Әмма республика җитәкчеләре моны танырга теләмәде.

Минем йөрәкне ике ут телгәли: бу – сәяси репрессия елларында гаепсез вафат булган, ярдәм ала алмаган туганнарым, ватандашларым һәм тулы көченә эшли башлап та, астыртын рәвештә җимертелгән Татар Милли Университеты.

Туган телне саклау һәм үстерү өчен, ул телдә югары белемне алырга кирәк, башка юл юк. Моны мин 80 еллык гомерем юлыма һәм 40 еллык татарча, русча укыту тәҗрибәмә таянып әйтәм. Бу барлык милли телләргә дә кагыла. Туган телебезне саклау һәм үстерү өчен, һичшиксез, Татар милли университетын эшләтеп җибәрергә кирәк. Татар телендә югары белемне бирүнең икенче юлы – КФУның һәр факультетында татар төркемнәрен оештыру. Үткән гасырның 30нчы елларында шулай, КДУның һәр факультетында татар төркемнәре бар иде. Н.Лобачевский исемендәге университет китапханәсендә татар телендә барлык белгечлекләрдән китаплар, дәреслекләр әле дә саклана. ТМУда укытканда, мин бу китапханәдән 1953 елда И.А.Алексеев тарафыннан татарча «Югары математика нигезләре» дигән дәреслек алган идем, миңа аны 10 көнгә генә бирделәр.

Җәмәгатьчелек нигезендә оештырылган Татар милли университетына 28 ел вакыт үтте, безнең хәзер дә ТМУны аякка бастырырга мөмкинлегебез бар. Моның өчен объектив сәбәпләр: беренчедән, Татарстан Республикасы Президенты Р.Миңнеханов узган 2021 елны безнең туган телебезне саклау һәм үстерү елы дип игълан иткән иде. Икенчедән, В.Путинның 2012 елдагы 1666 номерлы «Стратегия Государственной политики РФ на период до 2025 года» указында «Стратегия направлена на активизацию всестороннего сотрудничества народов РФ, развитие их национальных языков и культур» дип язылган. Бу указ автоматик рәвештә 1994 елгы Татарстан Дәүләт программасын яңадан торгызырга мөмкинлек бирә, нигез булып тора. 1994 елгы Татарстан Югары Советы сессиясендә 1995 елда КДУ кысаларында Татар гуманитар институтын ачу турында карар кабул ителде. Киләчәктә аны Татар дәүләт университеты итеп үзгәртү каралган иде.

(Дәвамы 4 нче биттә).

Җидегән
вакыйгалар
хәбәрләр
яңалыклар

Сәясиләштерелгән мәгариф

«Үзгәрешләр чорында яшәргә язмасын» дигән гыйбарәне кытайларга нисбәтлиләр. Ә реформалар бездә, үзгәртеп кору чорын да кертеп санасак, инде 40 елга якын бара булыр. Ихтимал, илдә бүген каткат реформаланмаган өлкә инде калмагандыр да. Тик алай да, бу чорда алар арасында тоташтан һәм иң нык туналганы, мөгаен, мәгариф өлкәсе булгандыр. Бер караганда, гади мантыйк буенча исәпләгәндә дә, озак еллар барган андый үзгәрешләрдән соң бу өлкә инде тел-теш тидермәслек итеп камилләштерелгән булырга, укыту һәм тәрбия кылу да методика вә сыйфат ягыннан күзгә күренерлек итеп яхшыртылырга, кыскасы, чын мәгънәсендә мәгърифәт учагына әйләнергә тиеш иде кебек. Ә чынлыкта нәрсә күзәтелә соң? Белгечләр әйтүенчә, ошбу өзлексез реформалардан соң мәгариф өлкәсенең сыйфат дәрәҗәсе совет чорындагыга караганда да түбән төшкән. Хәер, моның нәкъ шулай икәнлеге көндәлек тормыштан да бик ачык күренә. Кызганычка, мондый аяныч хәл укучыларның аң-белем дәрәҗәсендә генә түгел, әдәпәхлак халәтендә һәм мәдәни үсешендә дә чагылыш таба. Ахыр чиктә, җәмгыятьтә күзәтелә торган рухи деградация дә күп яктан шуның белән аңлатыла.

Тән азыгы – икмәк, җан азыгы – гыйлем вә мәгърифәттер, ди мәкаль. Ил-көндәге кыен хәлләрне дә бүген әнә шул җан азыгы җитмәү нәтиҗәсе дип карарга кирәктер. Туган телләр мәктәпләрдән куылган, ә милли мәгариф системалары дәүләт тарафыннан сәяси максатларда җимерелгән хәзерге чорда бу четерекле проблема инде аеруча зур актуальлек ала. Ул тулысы белән илдә сан ягыннан икенче урында торган татар халкына да кагыла. Дөрес, аның мондый кыен хәлләрдән, хак юлны табып, авырлыкларны җиңеп һәм шактый ук ныгып та чыгу тәҗрибәсе бар. Бу җәһәттән, XIX гасыр ахыры, XX йөз башында мәктәп вә мәдрәсәләрдә реформалар үткәрүне максат иткән җәдитчелек хәрәкәтен генә искә төшерик. Яңалыкка омтылу һәм наданлыктан арынуны ният иткән шул хәрәкәт тәэсирендә булса кирәк, бөек Тукай ул чорның рухи омтылышын үзенең «Сабыйга» шигырендә хәтта бер юлга сыйдыра алган: «Мәгърифәт нуры ачар күп нәрсәләрнең ялганын», – ди шагыйрь. Күрүебезчә, анда тирән мәгънә дә, киләчәккә өмет һәм даһилык та сыйган. Шуңа күрә ул әле дә гаять актуаль яңгырый, хәтта ки, бүгенге җаһил чорның шигаре булып та ишетелә.

Әйе, Урталык җирләрендә тормыш бүген тоташтан диярлек ялганга корылган. Ялган тарих, ялганга корылган сәясәт, ялган сайлаулар, ялган яшәеш... «Кара»ны – «ак», «ак»ны «кара» дип тәкрарлауларны көн саен һәм тәүлекләр дәвамында ишетеп һәм күреп торабыз. Чөнки илдә яшәеш тулысынча сәясәткә буйсындырылган. Хокук яклау һәм суд системалары, дәүләт төзелеше һәм гаммәви мәгълүмат чаралары, рухият вә мәдәният өлкәләре, икътисад һәм көнкүреш, хәтта социаль өлкә һәм медицина да сәясәткә хезмәт итә, аңа буйсынып яши. Әлбәттә инде, мәгариф өлкәсе дә шактый нык сәясиләштерелгән һәм 40 елга якын өзлексез бара торган «реформа»лар иң элек шуның белән аңлатыла. Бу чорда ялган патриотизм һәм бөекдержавачыл мин-минлек рухында тәрбияләнгән тулы бер буын үсеп җитте. Хөрлек елларында ачылган һәм әле ныклап аякка да басмаган татар гимназияләрендә бериш мәгариф түрәләре, ялган сәбәпләр табып, төп фәннәрне укытуны инде ул чакта ук урысчага күчерде. Әлеге түрәләр татар халкының милли университетын ачтырмау өчен дә бик нык тырышты. Татарстанда заманча эшләп киткән татар-төрек лицейлары исә Мәскәү әмере белән ябылды һәм илдәге халыкларның милли мәгарифләрен җимерү инде дәүләт дәрәҗәсендә башланды. Шул чорда Татарстанда (саф татар районнарында!) кадет мәктәпләре дә күпләп ачылды. Дөресен әйткәндә, бүгенге хәтәр хәлләргә яшьләрне әзерләү инде шул елларда ук башланды.

Халык кыенлыклар күргән арада, мәгариф «реформа»сы шыпырт кына бүген дә бара. Хәзер инде ул дәүләт федераль мәгариф стандартларын (ФГОС) яңарту юлы белән үткәрелә. Алары исә, 2012 елда Россиядә 2025 елга кадәрге чор өчен кабул ителгән «РФ дәүләт милли сәясәте стратегиясе»нә туры китереп (ә ул, асылда, илдә милли күптөрлелекне бетерүне максат итә) төзелә. Әле күптән түгел мәгариф стандартлары кабат яңартылды һәм мәктәпләрдә бердәм белем бирү программалары турында закон да кабул ителде. Нәтиҗәләр исә шул ук: мәгариф системасы катлаулана, әмма сыйфаты яхшырмый. Чөнки ул, җәмгыятькә түгел, күбрәк сәясәткә хезмәт итә (шуңа анда милли мәгарифкә урын юк та). Андый «мәгариф»нең яшәеш өчен яраксызлыгын бүген тормыш үзе күрсәтә. Татар халкына килгәндә, ул бүгенге кыен шартларда да үзенең тулы циклы (балалар бакчасыннан алып, югары уку йортларына кадәр) һәм заманча мәгариф системасын булдырырга сәләтле. Аллаһ теләсә, иртәме-соңмы, ул аңа ирешәчәк тә. Моның өчен аңа фәкать комачауламаска гына кирәк.

Фоат УРАЗАЙ.

«Казан арты»нда «Идегәй» рухы

«Казан арты» тарих-этнография музеенда рәссам Рәшит Гаимов күргәзмәсе эшли. Шул уңайдан монда сәнгать остасы белән очрашу узды.

Очрашуны музейның туган якны өйрәнү бүлеге мөдире Ленар Гобәйдуллин алып барды. «Рәшит Хәмит улының балачагы Ашытбашта үтә, чөнки аның әнисе Гарифә шушы авылдан», – дип сөйләде ул. Күптән түгел Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исем алган рәссам Казанда туса да, әтисе Башкортстаннан булса да, ул Арча ягын якын итә, үзенең туган ягы итеп саный. Р. Гаимов белән очрашуга Ашытбаш авылыннан аның туганы Равил Рәхмәтуллин да килгән иде.

Күргәзмәне ачу тантанасына Мөдәрис Минһаҗев, Альфред Шәймәрданов һәм башка хөрмәтле кунаклар килде. Район мәдәният идарәсе җитәкчесе Илфар Әюпов рәссам Р.Гаимовка үзенең сурәтләрендә татар халкының тарихын, туган ягына мәхәббәтен чагылдырганы өчен олы рәхмәтен белдерде. Берничә ел рәттән рәссам татарның «Идегәй» дастаны буенча иллюстрацияләр сериясен эшли.

Рәшит Хәмит улы Казанның 11 нче музыка мәктәбендә балаларны рәсем сәнгатенә өйрәтә. Мәктәп директоры, күргәзмә ачылышында катнашкан Анжелла Гургенидзе да үзләрендә шундый күренекле рәссам эшләвенә куануын белдерде.

Дәрдемәнд үзгендә фәнни җыен

Шушы көннәрдә Россия кооперация университетының Татар мәдәнияте үзәгендә Татар сәүдәгәрләре һәм меценатлары эшчәнлегенә багышланган III халыкара конференция узды. Ул Татар мәдәнияте үзәге, Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты, Татарстан Дәүләт Советының «Мәрхәмәт» хатын-кыз депутатлары берләшмәсе, Дөнья мәдәнияте институты (ЮНЕСКО), Бөтендөнья татар эшкуарларына ярдәм итү ассоциациясе, Казан шәһәре мәгариф идарәсе, Әлки районы «Якташлык» җәмгыяте белән берлектә оештырылган иде.

Конференциядә катнашучыларны Россия кооперация университеты ректоры, «Мәрхәмәт» берләшмәсе рәисе Алсу Нәбиева сәламләде. Ул үз чыгышында Татар мәдәнияте үзәгендә татар сәүдәгәрләре һәм меценатларының тарихы өйрәнелүен, бирердә иҗат лабораториясе эшләвен сөйләде. «Киләчәктә яшьләр дә үз эшләрен меценатлар югарылыгында алып барырлар. Институтта очраклы рәвештә генә Сәүдәгәрләр музее эшләми», – дип искәртте ул. Университет ректоры залдагыларга бик матур хәбәр дә ирештерде. Уку йортының Татар мәдәнияте үзәге телебезне, мәгарифебезне саклауда зур эшләр башкарган меценат, олуг шагыйрь Дәрдемәнд исемен йөртәчәк.

Тарих институты директоры урынбасары Марат Гыйбатдинов, Бөтендөнья татар эшкуарларына ярдәм итү ассоциациясе башкарма директоры Фәрит Уразаев конференциянең яшьләр өчен аеруча мөһим булуын белдерде.

Конференциядә катнашу өчен Австралиядән килгән Диләрә һәм Шөхрәт Вәлиләр үз нәсел тарихы белән таныштырды. Свердловск өлкәсеннән Миләүшә Салаватованың сәүдәгәр Сакаевлар нәсел дәвамчыларына багышланган, Серов шәһәренең хезмәт күрсәтү һәм туклану техникумыннан Розалия Разницинаның Урал төбәгенә күченергә мәҗбүр булган татарлар, Таллиннан Фәузия Яхина-Һадиуллинаның шул якта яшәүче татарлар тормышы, Әлки үзәк китапханәсенең туган якны өйрәнү һәм милли әдәбият бүлеге җитәкчесе Алсу Низамованың үз җирлекләрендә сәүдәгәрләр эшчәнлеген дәвам итүче якташлары турында һ.б. чыгышлар да бик мәгълүматлы һәм эчтәлекле иде. Казанның Абдулла Алиш исемендәге 20 нче гимназия директоры Рәхимә Арсланова хәйриячеләргә багышлап музей ачарга җыенуларын хәбәр итте.

Татар сәүдәгәрләре һәм меценатлары эшчәнлегенә багышланган Халыкара конференциядә катнашучылар саны елдан-ел арта. Тиздән уку йортында Халыкара татар мәдәниятләре үзәкләре фестивале дә уздырылачак, конкурска килгән мәкаләләр исә туплап нәшер ителәчәк.

Конференция кысаларында «Татар сәүдәгәрләре һәм меценатларының үткәне һәм бүгенгесе» дигән темага үткәрелгән конкурска да йомгак ясалды. Бәйгегә чит илләрдән, Россия төбәкләреннән һәм Татарстан районнарыннан 50 гә якын язма эш килгән.

Сөембикә КАШАПОВА.

Көмеш Коръән

VIII гасыр кульязмасы нигезендә көмештән эшләнгән Коръәнне «Казан Кремле» музей-тыюлыгында урнашкан Ислам мәдәнияте музее күргәзмәсендә тәкъдим иттеләр. Ул көмешнең 999 пробалы иң югары сыйфатлы үрнәгеннән ясалган һәм 162 биттән тора.

«Көмеш Коръән» – ислам традициясендә ясалган сәнгать предметы, ул Россиядә генә түгел, Казахстанда, Үзбәкстанда, Катарда һәм башка илләрдә дә саклана. «Көмеш Коръән»дә мәңгелек текст затлы материалда сурәтләнгән һәм Россия зәркәнчеләренең осталык үрнәге булып тора.

«Көмеш Коръән» 2010 елның ноябрендә РФ Финанс министрлыгы карамагындагы «Гознак» оешмасының Мәскәүдәге «Монетный двор»ында ясалган. Идеянең авторы – «ВТ» компаниясе хуҗасы Владимир Прусаков.

«Көмеш Коръән» өчен Изге китапның иң борынгы һәм сирәк очрый торган нөсхәсе булган «Госман Коръәне» нигез итеп алынган. Дөньяның төрле почмакларында – Истанбул, Ташкент, Каһирә һәм Санкт-Петербургта – изге китапның дүрт борынгы нөсхәсе саклана. Көмеш пластиналарга нәкъ менә Петербург кульязмасы күчерелгән.

1 нче биттә – татар театрына нигез салучы Габдулла Кариевка Норлат районында куелган яңа һәйкәл. Фото: nurlat-tat.ru

Башкала үзәгенә аерым игътибар

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Казанның тарихи үзәгендә төзелеш объектларын карады. Яңа төзелешнең барлык проектлары да тарихи җирлекләрдә шәһәр төзелеше эшчәнлеге мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия утырышында каралды, аларны кабат тикшерү турында карар кабул ителде.

«Ферма-2» урамында комиссия территорияне төзү планы белән танышты. Шәһәрне үстерү институты архитекторлары Рөстәм Миңнехановка тарихи объектлар һәм тирә-яктагы яшеллекне дә күздә тоткан үз тикшерүнәтиҗәләрен тәкъдим итте.

Аннан соң Волков ур., 12 адресы буенча урнашкан торак йорт төзелешенә юнәлделәр. Рөстәм Миңнеханов шәһәр структураларына төзелеш тирәсен тәртипкә китерергә тәкъдим итте. Ул билгеләп үткәнчә, шәһәрнең тарихи үзәгендә кунаклар һәм туристлар күп, территорияне төзекләндерү, шулай ук торак йортларның, шул исәптән агачларның тышкы кыяфәте билгеле бер стандартларга туры килергә тиеш.

Аннары Татарстан Президенты Һади Атласи урамындагы торак йорт төзелеше проекты белән танышты. Биредә 10 фатирга исәпләнгән торак йорт төзеләчәк, объект катларын киметү шарты белән расланды. Бутлеров ур., 22 адресы буенча урнашкан күп фатирлы торак йорт төзелеше дә хупланды. Чираттагы объект – Жуковский урамындагы шәхси торак йорт авария хәлендә, хуҗалары бар, әмма әлеге йорт урнашкан җир кадастр хисабында тормый. 2018 елның маенда йортта янгын чыккан.

Рөстәм Миңнеханов Казан мэриясенә һәм Мәдәни мирас объектларын саклау буенча комитетка бу мәсьәләне җентекләп тикшерергә кушты, чөнки бу XIX гасырның икенче яртысында төзелгән әһәмиятле бина булып тора.

Сара Садыйкова урамындагы ике торак йорт та, катлар санын азайтканнан соң, рәсми рөхсәт алды.

Сәфәр ахырында Рөстәм Миңнеханов Каюм Насыйри урамында булды. Мансур хәзрәт Җәләлетдин урамны үстерү проекты турында сөйләде – бу урында элек ике катлы табышлы йорт булган, аны торгызу күздә тотыла. Проект хупланмады, чөнки объект Казан шәһәренең хәзерге йөзенә туры килми.

Рөстәм Миңнеханов шулай ук Мәрҗани мәчетен карады. Бу мәдәни мирас объектында соңгы реставрация 2005 елда булган. Президент реставрация эшләре өчен документлар әзерләргә, федераль әһәмияттәге әлеге мәдәни мирас объектының фасадын һәм түбәсен тәртипкә китерергә кушты. Реставрация эшләрен берничә этапта башкару күздә тотыла.

Төркиядән китап кайтты

Татарстан язучылар берлегендә Төркиядә басылып чыккан «Татар хикәяләре антологиясе» тәкъдим ителде. Җыентыкка кергән хикәяләрне төрек теленә тәрҗемәче Фатих Котлы тәрҗемә иткән.

«Төркиядә XX гасыр татар хикәяләре басылып чыкты – бу зур вакыйга. Төркия китапны үз хисабына бастырып чыгарды һәм авторларга китаплар да җибәрде. Басылып чыгуга караганда кайтарту кыйммәткәрәк төште», – диде Татарстан язучылар берлеге рәисе, җыентыкны төзүче Ркаил Зәйдулла китапны тәкъдим итеп.

«Әлеге антология Мәскәүдә рус телендә басылып чыгачак. Азәрбайҗан телендә дә басылачак, Казахстан белән дә сөйләшүләр бара. Бәлки, ул вакытта үзгәрешләр кичереп яңа авторлар да өстәлер. Әдәби процесс үзгәреп тора һәм шулай булырга тиеш тә», – дип дәвам итте ул.

Ркаил Зәйдулла мондый антологияләрнең унбиш ел саен басылып торырга тиешлеген ассызыклады. Татар әдәбиятында бу рәвештәге антология соңгы тапкыр 1992 елда – 30 ел элек басылган булган.

«Татар хикәяләре антологиясе» китапка хикәяләре кергән язучылар – Батулла, Марсель Галиев, Вахит Имамов, Ринат Мөхәммәдиев, Фоат Садриев, Галимҗан Гыйльманов, Рифә Рахман һәм Хәбир Ибраһимга тапшырылды.

«Фатих Котлыны безнең Татарстанга Аллаһ Тәгаләнең бүләге дип саныйм. Төркиядә килеп татарча өйрәнеп, татар теленнән турыдан туры күпме китапны төрек теленә тәрҗемә итте һәм итәчәк. Мондый егетнең кадерен белергә, сакларга һәм рәхмәтле булырга кирәк», – диде Ринат Мөхәммәдиев. Аның фикеренчә, төрек әдәбияты тарихына кереп татар язучысы үзен мәңгеләштерү юлында җаваплы эш башкара.

«Язучының исән булуы тәрҗемәченең бәхете ул. Һәр хикәя буенча автор белән озаклап сөйләштек, хата китмәсен дип тырыштык. Төркиядә җыентыкны яратырлар дип уйлыйм», – диде җыентыкның тәрҗемәчесе Фатих Котлы. Ул бу хезмәтнең чит җирләр үз ватаннарына, ватаннары исә чит җиргә әйләнгән Төркия татарларына багышлануын телгә алды.

Рузилә МӨХӘММӘТОВА.

Университетны кулдан ычкындырдык

(Ахыры. Башы 2 нче биттә).

1996 нчы елның сентябре беренче абитуриентларны кабул иту вакыты дип билгеләнде, Премьер-министр урынбасары И.К.Хәйруллин билгеләгәнчә, ТГИ бурычы – Татарстанның башлангыч һәм урта белем бирү өчен уку йортларына югары квалификацияле укытучылар әзерләү иде. Казан дәүләт университеты профессоры Ю.Г.Коноплев ярдәме белән күркәм эшнең нәтиҗәлелегенә ирешүгә иң яхшы юл сайланган: бар дөньяга билгеле Казан дәүләт университетының материаль-техник, методик-укыту базасын һәм югары квалификацияле укытучылар штатын изге эштә куллану бик отышлы хәл. Укытучылар татар телен генә түгел, татар тарихын һәм әдәбиятын, математикасын, физикасын, химиясен, биологиясен һәм башка предметларны да татар телендә укыта белергә тиеш, шундый кадрлар әзерләү ТГИнең беренче бурычы булып тора, бу эшләрнең бер өлеше инде ТМУ укытучылары тарафыннан эшләнелгән һәм кулланыла иде. 1992-1995 елларда Татар милли университетын тулы хокуклы итеп эшләтеп, анда студентларга һәр предметтан татар телендә белем биреп, туган телебезне саклап һәм үстереп җибәрү өчен инде күп көч куеп кабул ителгән хөкүмәт планнарын тормышка ашырырга нәрсә комачаулады икән?

Мин 1990 нчы елларда чын мәгънәсендә татар теле өчен көрәшеп йөргән милли пәрвәрләребезнең исемнәрен саныйк: Вахит Хаков, Гомәр Саттаров, Хәләф Гарданов, Әнвәр Хуҗиәхмәтов, Фоат Галимуллин, Фәүзия Бәйрәмова, Илдус Әмирханов, Рафаэль Тукшаитов, Альберт Борһанов, Тәэминә Биктимирова, Равил Һади, Ринад Галимуллин, Рәфкать Рәхмәтуллин, Фәрзәнә Кулиева, Бәһрам Кочкаров, Әнисә Мусина, Сәвия Михайлова, Ким Шакиров, Әнис Галимҗанов, Гөлнара Арсланова, Әзһәр Мөхәммәди, Наил Газетдинов, Мәрьям Ахиярова, Илһамия Курганова, Гөлсинә Хәйдәрова, Дамир Юнысов, Хаҗип Нәҗипов һәм тагын бик күп, үз-үзләрен кызганмыйча татар халкына хезмәт итүчеләр. Кайберләре арабызда юк инде, рухлары шат булсын.

Нинди кулай мөмкинлекләребез була торып та, без туган телебезне саклап калу өметен кулдан ычкындырдык. Республика җитәкчелеге безне якламады. Шуңа йөрәк әрни.

Казан.

«Мәдәният» проекты чынга ашырыла

Россия мәдәният министры урынбасары Надежда Преподобная, Татарстан Премьер-министры урынбасары Ләйлә Фазлыева, Татарстан мәдәният министры Ирада Әюпова катнашында Креатив индустрияләр мәктәбе ачылды.

Креатив индустрияләр мәктәбе – «Россиядә уйлап табылган» федераль проекты кысаларында барлыкка килгән яңа мәгариф үзәге. Татарстанда аның беренчесе Н.И.Фешин исемендәге Казан сынлы сәнгать училищесы базасында эшли башлады.

«Биредә бик күп эш башкарылган. Беренчедән, мәктәп мәдәни мирас объектында, зур тарихлы бинада ачылды. Монда илһамланмый мөмкин түгел. Сезнең очкынланып янган бәхетле күзләрегезне күрү зур шатлык», – дип сәламләде Надежда Преподобная мәктәпнең беренче укучыларын.

«Бу проект алга таба да дәвам итәчәк. Креатив индустрияләр мәктәбе ачу өчен яңа заявкалар әзерләдек. Киләсе елда республикада тагын ике шундый мәктәп ачылыр дип уйлыйбыз. Монысы – сынлы сәнгать юнәлеше, алга таба музыка юнәлеше буенча да эшлибез», – дип хәбәр итте мәдәният министры Ирада Әюпова.

Татарстанның мәдәният министры белән бергә, Н.Преподобная «Мәдәният» илкүләм проекты кысаларында ремонтланган Арча балалар сәнгать мәктәбе белән танышты. Арча районына сәфәр вакытында кунаклар Штерә авылында яңа клуб төзелешен дә карады. Авыл клубы да «Мәдәният» илкүләм проекты кысаларында төзелгән. Моның өчен 12 миллион сумнан артык акча бүлеп бирелгән. Шуның 7 миллионы – федераль бюджет һәм 5 миллион чамасы – республика бюджетыннан. Клубта 50 урынлык уңайлы зал булырга тиеш.

Хәзерге вакытта монда 10 төрле түгәрәк эшли: «Сәйлән» һәм «Назгөл» балалар бию коллективлары, «Сердәш» өлкәннәр бию коллективы, «Сүнмәс йолдызлар» театраль коллективы, өлкәннәр өчен «Энҗе бөртекләр» тегү-чигү клубы һ.б. Ачылу тантанасын ноябрь аена планлаштырылган.

● Credit Suisse мәгълүматлары буенча, хәзер кытайлар европалыларга караганда баерак: Кытайда җан башына уртача 26 752 доллар, Европада исә уртача 26 690 доллар туры килә. Шулай да кытайларның уртача байлыгы Америка халкы байлыгының өчтән бере кадәр генә – анда ул җан башына 93271 доллар тәшкил итә (Бельгиядә исә әлеге күрсәткеч 256 336 долларга тәңгәл). Кытай муллык арту тизлеге буенча беренче урынга чыккан, чөнки соңгы ике дистә ел эчендә җан башына туры килгән байлык күләме сигез тапкыр арткан – 2000 елда ул 3111 доллар гына булган.

● 2021 елда җиһан байлыгы 9,8 процентка арткан һәм барлыгы 463,6 триллион долларга җиткән.

Серовта Җәлилне хөрмәтлиләр

Татар төбәк тарихын өйрәнүчеләрнең «Урал ягы татарлары: тарих һәм заман» VII Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясенең чираттагы утырышы Свердловск өлкәсенең Серов шәһәрендәге Металлурглар мәдәният сараенда узды. Ул бу юлы Советлар Союзы Герое, патриот-шагыйрь Муса Җәлилнең Серов шәһәрендә булуына 90 ел тулуга багышлап һәм «Татарларның заводлар төзелешләрендә, Уралның төньяк биләмәләрен үзләштерүдә катнашуы, Уралга репрессияләнеп сөрелгән татарларның язмышлары һәм аларның Уралдагы тормышлары» дигән темага үткәрелде.

Серов шәһәре әллә ни зур түгел, әмма ул Урал якларының капкасы кебек. 1934 елга кадәр – Надеждинск, аннары өч ел Кабако́вск исемнәрен йөрткән. Аннары якташлары, Советлар Союзы Герое Анатолий Серов хөрмәтенә аның исемен алган. Хәзер шәһәрдә 94 мең кеше яшәве теркәлгән, аның биш меңгә якыны – татарлар. Серов шәһәр башлыгы Василий Сизиков конференция ачылышында билгеләп үткәнчә, татар халкының Россия мәдәниятенә керткән өлеше гаять зур булган.

Серовта яшәүчеләр шәһәрдә 1932 елда каһарман шагыйрь Муса Җәлилнең булып китүе белән ихластан горурлана. Инде шагыйрь һәм журналист буларак танылып өлгергән ир-егет ул вакытта Мәскәүдә «Юные товарищи», «Октябренок» балалар журналларының җаваплы редакторы, «Коммунист» әдәбият һәм сәнгать газетасының бүлек мөдире булып эшли.

М.Җәлил Надеждинскига Урал өлкәсе газеталарының эшче хәбәрчеләре слетына килә һәм шәһәрдә дүрт көн була. Киңәшмәне исә «Коммунист» татар газетасы (Мәскәү), «Социализм юлы» (Свердловск) һәм «Эшче» (Надеждинск) газеталары редакцияләре бергәләп оештыра. Киңәшмә Металлург сараенда уза, анда 300 кеше катнаша. М.Җәлил гаммәви матбугат бурычлары турында чыгыш ясый, шигырьләрен укый. Тәнәфестә эшчеләр белән әңгәмә кора, аларның хезмәте, тормышы, яллары белән кызыксына. Шагыйрь киңәшмәдән соң шәһәр предприятиеләренә, Каквинск күмер яндыру мичләре эшчеләре янына да бара, аларның клубында була. Металлургия заводында исә ул шәһәргә килгән көнне үк булырга өлгерә, танылган металлург татарлар белән очраша, домна цехы эшчеләре белән аралаша. Җәлил тәкъдиме белән Металлург сараенда Надеждинскида яшәүче төрле милләтләр катнашында кичә оештырыла, үзара аралашулар җылы уза, бергәләп төрле телләрдә халык җырларын башкаралар. Шагыйрь шулай ук «Эшче» татар газетасы редакциясенә дә бара, аларга булышлык күрсәтә, шәһәрнең алтынчы татар мәктәбе белән таныша. Җәлил Серов шәһәрендә XX гасыр ахырында агачтан төзелгән, шомартылган такта белән тышланган һәм бизәкләнгән, бүгенге көнгә кадәр сакланып калган ике катлы бинада яши. Йорт башта хезмәткәрләр өчен файдаланылган, кунакханә дә булып торган, кайчандыр анда «Эшче» татар газетасы редакциясе дә урнашкан. 1983 елда Агломератчиклар урамындагы йортның алгы өлешенә Советлар Союзы Каһарманы, танылган татар шагыйре М.Җәлил яшәве турында истәлек тактасын эләләр. Аңа шагыйрьнең туган һәм вафат булган көннәрендә чәчәкләр куюны гадәт иткәннәр. Хәзерге вакытта ташландык хәлгә килгән. Узган ел үзәк шәһәр балалар китапханәсе мәйданында тантаналы рәвештә Җәлилгә бюст ачу тантанасы булган. Бюстның авторы – Санкт-Петербург шәһәре скульпторы Винера Абдуллина.

Серовта дистә еллар дәвамында шәһәр балалар китапханәсе базасында «Җәлил укулары» үткәрелү дә яшьләрнең шагыйрьне, аның каһарманлыгын белеп үсүенә булыша. Бәйге, гадәттә, китапханәнең директоры урынбасары Елена Листратенконың Җәлилнең батырлыгын, аның Серовта булуы турындагы чыгышы белән ачыла. Конкурста балалар да, яшь егет-кызлар да, өлкәнрәкләр дә катнаша. Шагыйрьнең шигырьләре рус һәм татар телләрендә яңгырый. Соңгы елларда конкурсның чикләре киңәйгән, башка татар шагыйрьләренең, хәтта азәрбайҗан әдипләренең дә әсәрләрен укыйлар. Китапханәдә балалар өчен Г.Тукай, М.Җәлил һәм бүгенге заман язучыларының татар телендәге китаплары да бар. Аларны, гадәттә, килгән кунаклар һәм Бөтендөнья татар конгрессы бүләк итә. Биредә шулай ук «Туган тел» дигән проект эшләтеп җибәргәннәр. Аның дәресләрендә татар язучыларының һәм шагыйрьләренең әсәрләре файдаланыла.

«Урал ягы татарлары: тарих һәм заман» конференциясендә катнашучылар Җәлил бюсты янында да булды һәм аңа чәчәкләр салды. Аннары китапханәдә «Күренекле татар эшлеклеләре һәм зыялылар. Урал төбәгендәге шәһәр һәм авылларда шәхесләрнең татар мәдәниятен үстерүгә керткән өлешләре» дигән темага түгәрәк өстәл утырышы узды.

Надеждинск–Серов турында сөйләгәндә, репрессияләр турында искә алмый мөмкин түгел. 1930 елларда, ягъни Җәлил бу якларга килгәндә, репрессияләр совет тоталитар системасының аерылгысыз өлеше була. Башта кулакларны, аннары сәяси репрессиягә дучар ителгәннәрне яшәгән җирләреннән Себергә, Урал якларына завод төзелешләренә, урманнар кисәргә сөрәләр. Халык аз яшәгән, табигый байлыкларга мул булган Надеждинск районы сөргенгә озатылганнар өчен бик уңайлы урын дип табылган. Әйтик, 1930-1931 еллар ахырларында Надеждинск районына Кырым, Төньяк Кавказ һәм Азов-Кара диңгез, Украина якларыннан һәм Татар автономияле республикасыннан 30 меңнән артык кеше репрессияләнеп китерелгән. Алардан үзләре белән алып килгән бар нәрсә дә тартып алынган, еш кына салкын Урал төбәгендә юка кием белән калганнар. Читтән китерелгән бу кешеләрне аз санда яшәгән җирле халык арасында урнаштырып бетерү дә мөмкин булмаган.

Махсус күчереп утыртылганнар иң авыр хезмәтләрдә – урман кисүдә, сал агызуда, заводларда, кара эшче, забойщик булып, төзелештә һәм күмер яндыруда эшләгәннәр, авыл хуҗалыгы хезмәтләренә дә җәлеп ителгән. Надеждинск районында сөргенлекнең беренче елларында азык-төлек мәсьәләсе дә бик начар тора. Кулак дип танылып, яисә сәяси репрессия шаукымы белән бергә сөрелгәннәр арасында да татарлар шактый булган.

Сөргенгә сөрелүчеләр төрле авырлардан, салкын һәм ачлыктан күпләп кырылган, сабыйларын балалар йортларына урнаштырганнар. Алар балалар йортлары өчен җиһазланмаган баракларда интеккән. Йокы бүлмәләре урын-җир, җәймәләр белән тәэмин ителмәгән, балаларга аяк киемнәре, пальтолар җитмәгән.

Моннан тыш 1920-1930 елларда авылларда игеннәр уңмау, ачлык сәбәпле дә бик күпләр Надеждинскига эш эзләп килгән. Металлургия заводында хезмәт иткәннәр. Шушы шәһәрдә туып үскән Серов педогогика көллиятендә тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы Рәмзия Газетдинова да шәһәрдә татарларның шактый күп икәнлеген искәртте. Аның да бабасы Әхәт Лотфуллин үз заманында да шәһәргә эш эзләп килгән. Ул биредә зур металлургия заводында эшләгән. «Мин гомер иткән вокзал яны районында да татарлар күп яши. Анда да күмер яндыру мичләре булган. Ул елларда үзара гел татарча гына аралашканнар. Биредә татар телендә «Эшче» газетасы да нәшер ителгән», – ди Р.Газетдинова. Рәмзия ханымның әнисе татар теленә генә сөйләшә, мәчеткә дә йөри. Ул-кызларының да туган телләреннән аерылмавын таләп итә. Рәмзия ханым татарча аралаша ала. «Без гаиләдә өчәү үстек. Барыбыз да туган телебездә сөйләшәбез. Әмма балаларыбыз инде татар телен әйбәт белми», – ди ул. Шәһәрне җәмигъ мәчет манарасы нурлый. Аны шактый еллар төзегәннәр, нигезен салуда Рәмзия ханымның бабасы да катнашкан. Ә икенче Аллаһ йорты –– мәчет итеп үзгәртелгән йорт.

Шәһәрдә татар йорты бар. Биредә шулай ук 30 ел дәвамында «Чулпан» татар-башкорт мәдәният үзәге эшли. Аны Розалия Синцова җитәкли. Үзәккә милләттәшләребез җыела, концертлар куялар. «Кич утыру»ларда җеп эрләргә, бәйләргә өйрәнәләр. Якшәмбе мәктәбендә татар теле дәресләре дә үтә. Шулай ук «Чулпан үзәге»ндә төрле милли бәйрәмнәр дә гөрли. Җыен, Корбан, Мәүлид, Нәүрүз бәйрәмнәре халыкны берләштерә. Серовта шулай ук Арбат дигән шәһәр көне үткәрелә. «Татар кызы», «Татар әбисе» конкурслары да монда гомер иткән татарларга милли гореф-гадәтләребезне кайтарырга ярдәм итә. Калфак тегү буенча осталык дәресләрендә дә яратып катнашалар. Шәһәрдә соңгы елларда татар милли ашлары бик танылган. «Чулпан»да милли ядкәрләребез дә күп. Аларны еш кына Серовта гомер кичерep, инде өлкән яшькә җиткәннәр китерә. Кызганыч ки, әбекәйләребез арабыздан китә, ә шәһәрдә телебез, гореф-гадәтләребез дә югала бара.

Мәдәният сарае фойесында шәһәр архивы һәм Тарих музееннан китерелгән документ-ядкәрләрдән күргәзмә дә эшләнгән иде. Алар арасында фотоларның берничәсе табиб-стамотолог Ольга Лучнина гаиләсенә карый. Ул лаеклы ялга чыккач, әби-бабалары белән кызыксына, документлар туплый башлаган һәм шәһәрнең Энгельс урамындагы бер йортның бабасы Сөләйман Әхмәтовныкы булуын ачыклаган. Укытучы булып эшләгән бабасы репрессияләнеп китерелгән булган. Әлбәттә, ядкярләрне караганда, иң элек татар киемнәренә – чүәк, читекләргә, калфакларга һ.б. истәлекләргә күз төшә. Серов тарих музее хезмәткәре Елена Колядина белән сөйләшкәндә, татарларга кагылышлы экспонатларның фондларда гына саклануы һәм күчмә күргәзмәләрдә генә йөртелүе ачыкланды. Шәһәрдә саны буенча икенче милләт булган, завод төзелешләрендә эшләп төбәкнең икътисадын күтәргән татарларның ядкярләре нигәдер даими экспозициядә бөтенләй урын тапмавы аңлашылмый.

Төбәк тарихын өйрәнүчеләр Бөек Ватан сугышы елларында Серов шәһәрендә оештырылган госпитальләргә дәваланырга җибәрелгән, әмма яралары авыр булу сәбәпле, бакый дөньяга күчкәннәр җирләнгән зиратта да булды. Анда зур мемориаль комплекс куелган, 94 сугышчының исеме язылган. Араларында татар исем-фамилияләре дә хәтсез.

Сөембикә КАШАПОВА.

Җанисәп хикмәтләре яки Башкортстанда татарлар ник кими?

1979-2010 елларда Башкортстанның татар районнарында татарлар саны шаккаткыч кимегән. Төгәл саннар Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты оештырган конференциядә мәгълүм булды.

Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты оештырган чираттагы фәнни конференциядә шактый кызыклы мәгълүматлар яңгырады. Уфаның Раил Кузеев исемендәге Этнологик тикшеренүләр институты аспиранты Комил Сиражетдинов Башкортстанның татар районнары буенча 1979-2010 еллардагы җанисәп материалларына нигезләнеп язылган доклад укыды. Укыды, дим, чөнки аны аспирантның фәнни җитәкчесе, телгә алынган институт профессоры, тарих фәннәре докторы Фаил Сафин әзерләгән. Галим үзе конференциягә килүне кирәк санамаган (яки аңлы рәвештә качкан). Докладта 4 җанисәп кампаниясе барышындагы рәсми саннарның «могҗизалы рәвештә сикереп уйнаганы» күренә. Аны тыңлаганда, Американың күренекле язучысы Марк Твенның «Ялганның өч төре бар – ялган, оятсыз ялган һәм статистика» дигән канатлы сүзләре искә төште.

Галимнең анализы көчле. Ул Башкортстанда барган татарларны башкортлаштыру сәясәтен берничә район мисалында ачып сала. Бу хакта күп сөйләсәләр дә, рәсми саннар белән китерелгән дәлилләрне моңарчы күргән юк иде. К.Сиражетдинов автор исеменнән докладны дөньяга чыгармауны сорады, тик конференциягә журналист буларак чакырылгач, кызыклы мәгълүматны халыктан яшереп кала алмадык. Җитмәсә, «Россия авылының тарихи-мәдәни мирасын саклау һәм үстерү» дип аталган илкүләм конференциядә төрле төбәкләрдән тарихчы галимнәр, археологлар, этнографлар һ.б. белгечләр катнашты бит.

Игътибарыгызга рус телендә яңгыраган докладның татар теленә тәрҗемәсен тәкъдим итәбез.

Бакалы районы

2002 елда Бакалы районында башкортлар саны 1989 ел белән чагыштырганда 3560 кешегә арткан, ә татарлар саны 3383 кешегә кимегән. 2010 елгы җанисәптә, киресенчә, инде башкортлар санының 1312 кешегә кимүе ачыкланган (халыкның 17,3 процентын тәшкил иткән), ә татарларның өлеше пропорциональ рәвештә арткан.

Бакалы районында «башкорт» дип язылучыларның туган телләре милләт теленә тәңгәл килми. Бакалы районында 1979 елда «башкорт» дип язылган 6829 кешенең бары тик 415е генә, ягъни 6,1 проценты, туган телен «башкорт теле» дип билгеләгән. 1989 елгы җанисәп мәгълүматларына караганда, «башкорт» дип язылган 2716 кешенең 244е генә (8,9 процент) туган телен «башкорт теле» дип, ә 2441 кеше (89,9 процент) «татар теле» дип таныган.

2002 елда 6276 «башкорт» дип язылучыларның 629 ы (10 процент) туган телен «башкорт теле» дип күрсәткән, ә 5516 кеше татар телен билгеләгән. Икенче төрле әйткәндә, 2002 елда Бакалы районында «башкорт» дип язылучыларның 87,9 проценты татар телле булган.

1989 елда Бакалы районы татарлары арасында туган телен «татар теле» дип күрсәтүчеләр 1979 ел белән чагыштырганда 0,4 процентка арткан. Дөрес, 2002 елда бу күрсәткеч 2,6 процентка кимегән. Ул елларда татарлар арасында татар теленең рус теле файдасына кысылуы, Бакалы районында гына түгел, ә бөтен республика буенча күзәтелә. 2002 елда татарларның 94,9 проценты туган теле буларак татар телен сайлаган.

2010 елгы җанисәптә Бакалы районында «башкорт» дип язылган 4964 кешенең 73 проценты туган теле итеп татар телен билгеләгән. Ягъни, милли тәңгәллек буенча төрле манипуляцияләр булуына карамастан, Бакалы районында татар телле халык саны тотрыклы булып кала бирә.

Балтач районы

Республиканың шулай ук төньяк-көнбатышында урнашкан Балтач районында 2002 елда башкортлар саны 1989 ел белән чагыштырганда 11797 кешегә, ягъни 3,1 тапкыр арттырылган, ә татарлар саны 11092 кешегә – 4 тапкырга киметелгән. 1989 елда Балтач районында татарларның өлеше 59,2 процент тәшкил иткән булса, 2002 елда нибары 14,7 процентка калган.

2010 елгы җанисәп татарларның саны 6700гә, ягъни 2 тапкырга артуын күрсәтә. Рәсми саннар буенча, ул елда татарлар халыкның 31,2 процентын тәшкил иткән.

2010 елда «башкорт» дип язылган 10962 кешенең 7819 ы, ягъни 71,3 проценты туган теле итеп татар телен таныган. Татар булып язылган 6701 кешенең 6613е, ягъни 98,7 проценты, туган теле дип татар телен атаган. «Татар» дип язылганнар арасыннан бары тик 4 кеше генә туган теле буларак башкорт телен, ә 54 кеше – рус телен таныган. Шулай итеп, Балтач районының абсолют күпчелеге татар телле булып тора.

Борай районы

Борай районында 2002 елда башкортлар саны 11307 кешегә, ягъни 2 тапкырга арткан. Татарлар 12413 кешегә – 5,6 тапкырга – кимегән. 1989 елда Борай районы халкы структурасында татарларның өлеше 50,8 процент булса, 2002 елда ул 9,5 процентка кадәр киметелгән. 2010 елда башкортларның 5 меңгә кимүе, ә татарларның 2 тапкырга артуы күзәтелә (автор искәрмәсе: алдагы җанисәптә татарларның 5,6 тапкырга киметелүен исәпкә алсак, 2010 елда татарлар саны элеккеге күрсәткечкә кайта алмаган). Башкорт булып язылган 17401 кешенең 15695 е, ягъни 90,2 проценты, туган телен «татар теле» дип күрсәткән.

Кушнаренко һәм Благовар районнары

Кушнаренко районында 2002 елда башкортлар санының шаккаткыч артуы күзәтелә. Башкорт булып язылучылар саны 11121 кешегә – 8 тапкырга арткан. Благовар районында 1989 елда башкортлар саны 1899 булса, 2002 елда 12472 кешегә җиткән – 6,6 тапкырга арткан. Татарлар саны Кушнаренко районында 10591 кешегә, ә Благовар районында 8565 кешегә кимегән. 2010 елда кире тенденция – татарларның артуы һәм башкортларның берникадәр кимүе күзәтелә.

Туймазы, Чакмагыш, Шаран, Ярмәкәй, Илеш районнары

2002 елда башкортларның Туймазы районында – 8927 кешегә, Чакмагыш районында – 5338, Шаран районында – 6089, Ярмәкәй районында – 6371, Илеш районында – 6271 кешегә артуы күзәтелә.

Шул ук вакытта татарлар саны Туймазы районында – 8871 кешегә, Чакмагышта – 5685, Шаранда – 5485, Ярмәкәйдә – 6078, Илештә – 6049 кешегә кимегән (автор искәрмәсе: санап үтелгән районнарда башкортлар саны никадәр арткан булса, татарлар саны якынча шулкадәр кимегән). 2010 елда аларда кире тенденция – татарларның артуы, башкортларның кимүе күзәтелә.

Илеш районында 1989 елда башкорт булып язылганнарның 96,4 проценты туган телен «татар теле» дип күрсәткән, ә 2002 елда – 91,3 проценты. Башкорт булып язылганнарның 3,3 проценты гына башкорт телен сайлаган.

Рафаил Сафин белән Р.Г.Сибгатов тарафыннан үткәрелгән тикшеренүләр бу төбәктә яшәүче җирле халыкның сөйләм теле башкорт теленә күчүен күрсәтми. Бу районнарда яшәүчеләр 30 ел элек тә, 90 ел элек тә ничек сөйләшкән булса, шулай сөйләшүен дәвам итә. Моның шулай икәне 1926 елгы җанисәптә һәм 30 нчы елларда шушы районнарда үткәрелгән лингвистик тикшеренүләрдә теркәлгән. Кайбер галимнәр тарафыннан әлеге төбәк халкының телен төньяк-көнбатыш диалекты дип тану акланмаган.

Танылган башкорт лингвистлары Юлдашев һәм Бикбаев фикеренчә, әлеге сөйләшүне башкорт теле системасына кертеп булмый. Башкортстанның көнбатышында һәм төньяк-көнбатышында яшәүче халыкның телен тарихи яктан да, юридик яктан да башкорт теле буларак карау мөмкин түгел. Кайбер теоретиклар фикеренчә, этнос һәм аның теле бер үк вакытта формалаша.

Танылган башкорт тарихчысы, милли мөнәсәбәтләр буенча теоретик Юлдашбаев: «Башкортларның милләт булып берләшү процессында башкорт теле ике диалекттан – юрматы һәм кувакан диалектларыннан үсеш алган», – дип раслый. Шул ук вакытта ул «көнбатыш һәм төньяк-көнбатыш Башкортстан халкының теле башкорт теле түгел, ә татар теле» дип күптән ассызыклаган.

Аскын районында да 1979 елдан 2002 елга кадәр туган телен «башкорт теле» дип танучылар санының гаҗәеп артуы күзәтелә. 1979 елгы җанисәптә «башкорт» булып язылучыларның 5,1 проценты гына башкорт телен туган тел дип таныган булса, 1989 елда бу күрсәткеч – 41 процентка кадәр, ә 2002 елда – 83,9 процентка кадәр арткан. Мондый үзгәреш Аскын районы белән беррәттән Тәтешле районында гына күзәтелә. Бу парадоксаль күренешне фәнни яктан нигезләп тә, аңлатып та булмый.

Аскын районында 1979 елда башкорт булып язылган 17489 кешенең 16541 е, яки 94,6 проценты, туган тел буларак башкорт телен түгел, ә татар телен күрсәткән. 1989 елда барлык «башкорт»ларның 58 проценты, ягъни 8696 кеше, туган тел буларак татар телен таныган.

Шулай итеп, халык санын алу барышында булган административ манипуляцияләргә карамастан, Башкортстанда татарларның үзбилгеләнеше тотрыклы булып кала бирә.

Рифат КАЮМОВ.

Сиңа бәхет теләгәнгә Бәхетсезлек теләмә...

Илзирә ВӘЛИУЛЛИНА

БЕР МОҢ!

Мин бу моңны туганда ук –
Бик күптәннән ишеттем.
Күңелемә күптән уйдым,
Кечкенәдән иш иттем.

Аның белән уяндым мин,
Һәркөн йокларга яттым.
Шул моң аша күңелемә
Чиксез рәхәтлек таптым.

Бу МОҢ – ӘНИЕМНЕҢ моңы, –
Әнинең моңлануы!
Газиземнең, моңга чумып,
Фикерләү, уйлануы...

Бүгенгедәй ишетелә...
Саклыйм ул моңны җанда.
Калебемдә йөртәм аны,
Тамырымда ул, канда...

Ихатаны ямьләндереп,
Җыр көйләгән мәлләре...
Әниемнең моңланудан
Җиңеләйде хәлләре...

Үземнең дә, моңга чумып,
Яшәп яткан мәлләрем.
Әни шикелле моңланып,
Җиңеләйтәм хәлләрем.

Бу мирасны әниемнән
Алмаган идем сорап!
Яшим, моң дигән байлыкны
Килер бәхеткә юрап!

* * *

Еллар ага... Сулар ага...
Агымсудай гомер ага...
Йөрәкләргә сабыр гына
Вакыт кага...

Вакыт кага...
Үтә диеп.
Чираттагы ялган...
Чираттагы шатлык...
Бәхет... хафа...
Чәчәк кебек сафлык...

Вакыт кага...
Котә диеп
Яңалыклар... әмер...
Котә диеп яңа фәрман,
Шәфкатьлелек... җәбер...

Вакыт кага...
Әрвахларны
Искә ал да, шөкер ит, ди!
Туар таңны, килер көнне
Сабыр гына көт, ди,
Көт, ди...

Йөрәкләргә вакыт кага...

* * *

Синең янда бертөрле ул,
Яныңнан киткәч, бүтән.
Кешеләрне аңлый алмый
Кайчак аптырап бетәм...

Син юкта уе гел хурлау,
Бергә вакытта мактый.
Нигә икән кешеләрнең
Шундыйлары да шактый!

Гайбәт сатып башланадыр
Кемсәләрнең юл башы.
Юкса болай да җитәрлек
Кешелекнең гөнаһы.

Болай да бит вакытлар тар
Саваплы эш эшләргә.
Шулай булгач, нигә кирәк
Гаепсезне «тешләргә»?

... Күңел – дәрья... чиксезлек ул!
Күңел – серле биләмә!
Сиңа бәхет теләгәнгә
Бәхетсезлек теләмә –
Хәсрәт белән түләнә!

КИЧЛӘР ҖИТӘ...

Кичләр җитә... Серле кичләр,
Ямь өстәп күңелләргә.
Тагын бер кич,
Ямьле бер кич
Өстәлә гомерләргә!
Кичләр... Кичләр...
Урамнарда
Утлар яндырган кичләр!
Кичләр... Кичләр...
Күңелләрдә
Сөю калдырган кичләр! –
Икеләнү,
Шикләнүне
Юк иткән серле кичләр!
Иртәгесе көнгә өмет
Уята алган кичләр!
... Безгә әле күп кичләрнең
Ямьнәрен татыйсы бар...
Әле безнең гомер буйлап
Сөенеп атлыйсы бар!
Кичнең тыныч, йолдызлысы
Җанга иң кадерлесе!
Якты көндә теләп йөрим
Тусын иде бүген дә дип
Кичнең иң хәерлесе!

* * *

Хәтердә ат арбасында
Кырдан печән ташулар.
Халык белән тулы булган,
Гөрләп торган басулар!
Бастырык куелган печән
Эшкә бераз нәтиҗә –
Күңелдә рәхәтлек хисе:
«Мактап җибәр, әти, җә!»
Ә юлда печән ишелсә,
Туктап, янә төйисең.
Өстә торган шелтә ала:
«Дөрес өя белмисең!»
Кайта шулай урам иңләп,
Йөкне тартып эш аты...
Печәннең хуш исе белән
Янә тула каралты!
Шул печәнне ташый-ташый
Сөялләнде куллар да...
Бүгенге яктырткыч түгел,
Ай яктыртты юлларга...
Насыйп булды бик күп тапкыр
Очлау печән өемен.
Һич онытмыйм, әниемнең,
«Булдырасыз», – диюен.
Авылларда печән өсте
Хәзер инде үзгәрдер.
Печән чаптым дию әре
Үткән көндә, сүздәдер...
Тимер атлар чаба хәзер
Төйи, хәттә өя дә.
Сәнәк тотып печән аткан
Кеше сирәк түбәгә.
Чалгы тотып, печән чабу
Гамәл түгел, сүздәдер
Әткәм-әнкәм печән чапкан
Болыннар да үзгәдер.

* * *

Көзге кичне
Аклык, сафлыкка төреп,
Күңелләрнең аклыкларга
Сусавын аңлап, күреп,
Ява карлар...
Көзге кичне
Матурлап, сафландырып...
Сагыштан китек күңелне
Дәвалап, шатландырып...
Кичке карлар...
Ап-ак карлар...
Өзелеп көткән карлар...
Җитәкләшеп үтә яннан
Шат елмаешкан парлар...

Аклыклардан һичкем туймас,
Сафлыкларны күпсенмәс.
Иңгәндә күктән көпшәк кар
Җан боекмас, көрсенмәс...

Кичке карлар...
Ап-ак карлар...
Көзем, кышларга тоташ.
Йөрәк әйтә: «Әкрен генә
Көзләрең белән хушлаш!»

Юк! Хушлашмыйм мәңгелеккә,
Хуш диям, вакытлыча.
... Көзләргә гашыйк җанымны
Ак карлар килеп коча...

СИНСЕЗ...

Күктән төшеп җиргә бәрелгән күк,
Син юк... дигән сүзне ишеткәч.
Йөрәк тибүеннән туктагандай,
Авыр хәбәр җанны өшеткәч...

Галәм киңлегендә берьялгызым
Калдым хәзер...
Калдым мин синсез...
Күз яшьләрем тама салкын җиргә
Басып торам, өнсез... берсүзсез...

Яшь аралаш сиңа пышылдыйм мын:
Нигә китт-е-ең?... Нигә ташлады-ы-ың?
Мин бит сине язмыш җилләреннән
Үз бәхетем диеп сакладым...

Сине күреп елмаясы идем,
Син юклыкка җаным моңая...
Урамнарның һәрбер почмагыннан
Гүя сагыш усал елмая,
Усал итеп сагыш елмая...

КҮҢЕЛ БАКЧАМ

Күңел бакчам шау чәчәктә әле,
Матурлыгы җитә һәркемгә.
Чәчкәләрен өзәргә юл куймам,
Рөхсәт итмәм ләкин беркемгә.
Кемдер үтә күңел бакчам аша,
Җылы сүзләр генә калдырып.
Кемдер үтә чая сүзе белән
Күңелемне чагып, яндырып...

Кемдер юлчы, ә кемнәрдер анда
Бөтенләйгә кала тукталып.
Кем булсагыз да, күңел бакчамнан
Үтмәгез авырлык, шом салып.

Аклыкларга гашыйк күңелкәем
Калсын сездән, калсын көч алып...

МӘГЪНӘ ЭЗЛИМ

Галәм кочкан күзләремдә,
Әйтелгән сүзләремдә,
Көзге яңгырлар чылаткан
Сукмагым, эзләремдә
Бармы мәгънә?.. Юкмы ул?..
Булса, төпле, ныкмы ул?..
Мәгънә эзлим яшәвемнән,
Сөйләшү... Дәшмәвемнән,
Сабырсыздан... түземнән...
Билгеле, үз-үземнән! –
Эш бармаса, сәбәбеннән,
Кылынган гамәлемнән,
Яшәеш, галәмемнән...
Мәгънә эзлим... Табылырмы?
Табылса,
Бер аклык булып,
Җаныма сарылырмы?

Әллә миңа дөньясында
Эзләнергә кулаймы?
... Мин генәме эзләнүдә,
Әллә инде...
Бүтәннәр дә шулаймы?

ЙӨРӘК ҮЗЕ САЙЛЫЙ

Кемдер шулай, ни буласын
Алдан ук сизеп яши.
Күңелсез хәлләргә тарса,
Ничектер түзеп яши.

Кайберәүләр елак булмый,
Горур атлый тормышта.
Андыйларга батыр холык
Бирелгәндер тумыштан.

Берәүгә кара төс ошый,
Берәү ярата акны.
Дөрес, бар да хуп күрәдер
Бәхет елмайган чакны.

Уңышларга һәр күңел шат,
Монда да бар уртаклык.
Максатка атлаган чакта
Чигенүчән куркаклык.

Һәр йөрәкнең үз тибеше,
Үз тәртибе, кануны.
Шуңа һәркем үзе сайлый
Кайсы юлдан баруны,
Кайларга юл алуны...

РЕДАКЦИЯДӘН. Бүген шагыйрә Илзирә Вәлиуллинага 50 яшь тула. Без каләмдәшебезне күркәм гомер бәйрәме белән котлыйбыз, аңа исәнлек-саулык һәм яңадан-яңа иҗат куанычлары теләп калабыз.

ДӨНЬЯНЫ

Тарихында үз Ватаныннан китеп, дөньякүләм зур уңыш казанган шәхесләр бик санаулы. Рудольф Нуриев (1938-1993) 1961 елда Франциядә бөтенләйгә яшәп калгач та, киләчәктә аны чиксез популярлык, зур гонорарлар көтә дип уйланмагандыр. Тик бер нәрсәгә ышанган: ул дөньяның иң зур сәхнәләрендә чыгыш ясый алачак. Ул 23 яшендә үк классик балет реформаторы буларак, тарихка XX гасырның даhи биючесе булып кереп кала.

Рудольф Нуриев әнисе Фәридә белән.



Яшь биюченең Парижны ошатуы табигый, күп иҗатчылар бу кала энергетикасы белән илһамлана. Әмма «Париж синдромы» да бар. Гадәттә, аның белән японнар чирли. Парижга ашкынып барып, аны күргәч, тирән канәгатьсезлек хисе кичерәләр, шәһәр аларның өметен акламый... Тик безнең герой – япон туристы түгел. Ул – талантлы татар. Тик 1961 елда Франциядәге гастроль вакытында балет труппасын махсус күзәтеп йөрүчеләр чиксез уңыш казанган Р.Нуриевнең Париж белән якыннан танышырга теләвен, чит ил биючеләре белән дуслашуын бер генә дә өнәми. Йә ул биредәге бай кыз Клара Сент йортында кичке аш ашый, йә инглиз рәссамы белән Луврга китә... Йә француз дусларын Ленинградка, балет карарга чакыра. Труппа гастроле Бөекбританиядә дәвам итәргә тиеш була. Әмма аңа: «Син инде Лондонга бармыйсың, сине Мәскәүдә хөкүмәт җитәкчеләре алдында чыгыш көтә», «Әниең дә авырып киткән», – диләр, биюче боларның барысы да ялган булуын аңлый. Рудольфка ашыгыч карар кабул итәргә туры килә. Димәк, ул гомергә әнисез, әтисез, кыз туганнарсыз, Ватансыз калачак...

«Ле Фигаро» газетасы аннан: «Сез Парижда калу турында алдан ук карар кылган идегезме», – дип сораячак. «Юк», – дип җавап бирәчәк талантлы биюче. – Мин бу карарга килүгә берүзем җөрьәт итмә алмас идем. Миңа батырлык һәрчак җитмәде. 1961 елның июнендә мин Изге Магдалина чиркәвенә кердем һәм: «Көнбатышта калуым өчен ни дә булса эшлә, берәр хәбәр бир», дип дога кылдым». Биюченең ул көнне бик нык каушавын француз биючесе Пьер Лакотт та раслый: «Рудольф кем беләндер сөйләшеп алгач, агарынып катты. Минем янга килеп: «Беттем, мине Себергә олактырачаклар, булышлык итегез. Минем биисем килә! Бу билетка кара, ул Мәскәүгә кадәр, Лондонга кадәр түгел!» – дип елады. Минем тыныч басып торганымны күргәч: «Әгәр дә син миңа булышлык итмәсәң, син кичә бүләк иткән хәнҗәр белән үз-үземә кадыйм», – диде. Аның йөзе күз яшенә батып беткән иде. Мин рус кешесе белән сөйләштем, әмма ул: «Лакотт әфәнде, биюченең әнисе бик чирләп киткән, ул кире кайтырга тиеш, дип җавап бирде». Ул чыннан да биючегә кәгазь кисү өчен көмеш пычак бүләк иткән була. Ә труппа балериналары, хәтта аны өнәмәүчеләр дә аның белән елап хушлаша башлый. Алар Рудольфның башын диварга бәреп елаганын да яхшы хәтерли. Әмма биюче гомере ахырында Бөекбритания телевидениесе төшергән документаль фильмда, үзенә булышкан Клара Сентны искә алмыйча гына, бу көнне бик кыскача тасвирлый: «Син бик акрын гына алты адым атларга һәм: «Мин бу илдә калырга телим», – дип әйтергә тиеш». Мин нәкъ шулай эшләдем дә. Мин шул ике комиссар янына таба киттем... Бернинди сикерү дә, чабыш та, кычкырып елау да, истерика да булмады. Мин тыныч кына: «Мин сезнең илдә калырга телим», – дидем».

Чик контроле начальнигы Ле Бурже Грегори Алексинскийның тумышы буенча рус булуын Рудольф белми. Ул үзен яңадан совет хезмәткәрләре кулына тапшырачакларыннан курка. Әмма биюче хакындагы китапларның берсендә әлеге начальник элекке Думаның Ленинны тәнкыйть иткән өчен төрмәгә ташланган депутат-социалисты улы була, диелгән. Бу депутатның гаиләсе Россиядән 1919 елда качкан. Алексинскийның дусты да балет артисты икән, һәм ул аңа: «Россия мәшһүр артистын югалтты», – диячәк. Отис Стюарт «Рудольф Нуриев» китабында шул хакта да өстәгән: «Рудольфны урлауда гаепләмәсеннәр өчен, француз чиновниклары аңа күрше бүлмәдә берничә минут тыныч кына утырып торырга һәм ялгыз калып үз карары хакында уйларга тәкъдим итте. Анда ике ишек дияделәр аңа. Берсе Мәскәүгә китүчеләр залына илтә, икенчесе – бер инспекторның шәхси кабинетына. Ләкин Рудольф торып басуга ук, аның белән сөйләшүне таләп итеп, кабинетка совет илчелегенең мәдәният буенча атташесы Михаил Клейменов атылып керде. Алексинский рөхсәт итте. Бар янауларга да Рудольф «юк» дип җавап бирде. Ниһаять, Клейменов: «Сез үзегезнең бөек ватаныгызга кайтудан баш тартасызмы?» – диде. Рудольф: «Әйе, баш тартам», – диде. Клейменов кинәт аның йөзенә сукты, шул чак французлар килеп җитте. «Монда йодрык болгый торган урын түгел дидек» – ди Алексинский. «Сез коточкыч нәрсә эшләдегез», – дип ысылдады Клейменов Кларaның колагына. – Бу егеткә биредә сезнең белән бик начар булачак».

Рудольф соңрак: «Әгәр дә мине Россиягә кайтарып, анда биюдән мәхрүм итсәләр, мин акылдан язар идем», – диячәк. Вацлав Нежинский кебек. «Дягилев Нежинскийны «Рус театры»ннан куып чыгара, ә бит Вацлав үзен биюче итеп кенә күзаллый һәм акылдан яза. Россиядә сиңа биергә рөхсәт ителсә дә, син барыбер бик тар халәттә. Ә мин барысын да өйрәнеп, шуларны биеп карамасам, тормышымның бушка узачагын тойдым. Ләкин мәҗбүр итмәсәләр, мондый адым ясарга минем батырчылыгым җитмәс иде», – дип аңлата биюче. «Мин ятьмәгә эләккән һәм аңа бутала барган кошка тиң идем... Мине хөкем иттеләр. Тормыш программамны – җавапсызлык, ә тигезләүгә каршы торуымны һәм буйсынмавымны куркыныч индивидуализм дип атадылар» (Ватанга хыянәт дигән карар буенча биючегә 7 ел төрмә тиеш дигән хөкем карары чыгарыла).

1962 елда язган «Автобиография»сендә артист үз балачагындагы ачлыкны, мохтаҗлыкны тасвирлый. Әнисе Фәридә – гади ханым, дүрт бала анасы. Ул аның хакында: «Әнием борынгы Казанда туган» дип язса да, чынлыкта Фәридә Идрисова 1907 елда Казан губернасының Татар Түгелбае авылында (хәзерге Әлки районы) туган. 7 яшендә аны абыйсы Вәлиулла янына Казанга җибәрәләр. Әти-әнисе 1921 елда тифтан үлә. Казанда Фәридә мәдрәсәгә йөри, гарәпчә укый-яза башлый. Педагогика курсларында укырга тели, яхшы җырлый, бии. Хәмит Нуриев белән гаилә кора, ә ул – Кызыл Армия сафларында. Хәмит Нуриев 1903 елда Уфа өязенең Шәрип волосте Әсән авылындагы гаиләдә бишенче бала булып туган. Әйе, әнисе, апалары Роза, Розида һәм Лилия Рудольфның биюен ошаталар. Ә менә әтисе моның белән беркайчан да килешми. Читтә калган улыннан тулысынча ваз кичә. Улының Франциядә калуы турында хәбәр алгач, ябыгып, шундук картаеп китә. Гади халык аңа каныкмый, хәленә керә. Хәмит Нуриев үлгәнче улы турында бер сүз дә сөйләми. Ә бит ул аның тууын бик көтеп алган була. Чөнки Фәридә ханым бер-бер артлы гел кыз бала таба. Лилия тугач, ул ерактагы иренә телеграмма суга: «Улың туды». Хәмит җитез генә кайтып та төшә. Бактың исә, тагын кыз бала туган... Ләкин ата дошмы, янә хезмәт урынына китеп бара.

Ир бала 1938 елның 17 мартында Себергә юнәлгән поезд вагонында туа. Үсә төшкәч, Рудольф Уфадагы балалар бию ансамблендә халык биюләрен биергә өйрәнә башлый. Мәктәптән кайткач та, йокларга яткачны бии һәм җырлый. 1944 елның декабрендә аларның гаиләсе беренче тапкыр Уфадагы балет тамашасын карый. Малай өчен бу искиткеч вакыйга була. Чиксез бәхет, чөнки матур сәхнә аны ярлы, ач тормыштан еракка алып китә. Биюләрне карагач, ул,



Р. Нуриев һәм Марго Фонтейн.

ШАУЛАТКАН ТАТАР

әйтерсең, ниндидер «чакыру» ишетә. «Мин бию өчен туган» дип үз-үзен ышандыра. Энесенең сәхнә хакында хыялланун күргән апасы Роза аңа һәрчак булыша, биюләр турында сөйли, лекцияләргә алып бара, сәхнә киемнәрен күрсәтә. «Бу малай бию өчен туган. Ул Ленинградта укырга тиеш», – ди Нуриевләргә гаилә дуслары. 11 яше тулгач, малайны Уфадагы Галимнәр йортына алып барып, кайчандыр Дягилов балеты артисткасы булган Анна Удальцова белән таныштыралар. Ханым малайны атнага ике тапкыр биергә өйрәтә. Ленинградта укырга тиешсең, ди. А.Удальцова яшүсмерне Киров театрының элекке артисткасы Елена Войтович белән таныштыргач, биюләр сыйфаты тагын да яхшыра. Пианистка Ирина Воронина аны фортепианода гади көйләр уйнарга өйрәтә. Балалар сайлап алу көне килеп җитсә дә, Рудольф комиссия алдында биеп күрсәтергә җитешми, аны Ленинградка җибәрү өчен әтисенең ике йөз сум акчасы да табылмый. Хәмит Нуриев улының хәрби, табиб яисә инженер булуын тели. Чиктән тыш катгый ата булмый ул, ләкин үзе дә аңламастан улының хыялларын чәлпәрәмә китерергә тырыша. Рудольфка – нибары 14 яшь, әмма ул инде үз эчендә йомылганнан-йомыла бара. Аның бар тормышы бию белән бәйле. Өйдә биергә рөхсәт итмиләр, ул әтисеннән кача-поса гына бии. Укуда да уңышлары юк. Укытучылар аның әтисенә бу хакта гел искәртеп торуда: «Нуриев укырга соңга калып килә, тәртибе начар, бака кебек сикерә, шуны гына белә... ул хәтта баскычта да бии...» Роза инде Ленинградта, ә яшүсмергә көннән-көн күңелсезрәк. Ул Уфа балет театрында сүзсез рольләрдә дә катнаша, әмма аңа аз түлиләр. Егет эшелонәр «труппа»ларына барып, «Уфа театры артисты» буларак, аена ике йөз сумга биергә өйрәтә алам, дип белдерә. Шулай итеп акча эшли. Тугызынчы сыйныфта укыганда, аңа балет тамашаларында кечкенә генә роль биергә тәкъдим итәләр. Чын сәхнәдә биегән көнне ул төне буе йокламый. Киләсе елда егетне инде кордебалетка ук алалар, ул биючеләр белән бергә күнекмәләр ясый. Акылдан язган кешедәй, гаять тырышып бии. Ленинградта укыганда стипендия бирелачәге хакында белгеч ник сөенә. Аны труппа штатына биюче итеп кабул итәләр.

● Р. Нуриев һәм Марго Фонтейн.

1955 елда Мәскәүдә Башкортстан мәдәнияте декадасы алдыннан гына төп рольне башкарачак артист кинәт чирләп китә һәм Рудольф балетмейстерга бу рольне башкара алачагы хакында әйтә. Биеп тә күрсәтә. Мәскәүдә репетиция барганда аягын тайдыра, аягы шешеп чыга... Әмма бер атнадан савыга, бии. Биегән өчен алган акчага ул Ленинград балет училищесына укырга юнәлә... 17 яшендә. Ә анда 9-10 яшьтән үк укый башлыйлар... Үзен училищеда рәнҗеткән яшүсмерләрне ул бик яхшы хәтерли. Үзе язган «Автобиография» китабын ачсак, китапта мондый юллар бар: «Кулымны йөрәккә куеп әйтә алам, якынча сигез яшемнән мин балетка бирелдем. Бер төр дәрт белән чолганган адәм ничек бар башкага карата сукыр һәм чукракка әйләнә, мин дә үземдә бары тик биюгә карата катгый таләпчәнлек, шашкынлык сиздем. Биюдән тыш – яисә шуның белән берлектә – мин бик тә фортепианода уйнарга теләдем... Кызганыч, әтине фортепиано алырга күндереп булмады. 1960 елда ГДРдагы гастрольләрдә эшләп алган акчага матур инструмент алдым һәм аны пароход белән Ленинградка юлладым...» Балет мәктәбендә укучыларны ул болай дип тә искә ала: «Бервакыт алар мине безнең сыйныф бүлмәсенең буйдан-буйга беркетелгән зур көзгесе янына алып килделәр, һәм минем хакта нәрсә уйлауларын әйтеп салдылар: «Үзеңә кара әле, Нуриев... Син беркайчан да бии алмаячаксың – бу мөмкин түгел. Син моның өчен тумаган. Синең бернәрсәң дә юк – мәктәбең дә, техникаң да. Безнең белән сигезенче сыйныфта шөгыльләнү өчен кыюлык каян гына киләдер сиңа?!»

Алар хаклы: минем бернәрсәм дә юк иде. Ул отличниклар, техник яктан искиткеч ныгыган һәм үзләренең традицион стильләре белән горурланучылар өчен, мин күз көеге идем. Алар мине берничек тә кабул итә алмады. Шул ук вакытта, аларга озаграк караган саен, үз урынымны хаклы алып торуыма шулкадәр инана бардым. Моны үзем белән канәгать булу димәс идем, мин шуны анык белдем: биергә хакым бар, нәкъ шуның өчен туганмын, барысы да бу фактны кабул иткәнче миңа көрәшергә туры киләчәк». Дөньясын онытып күнекмәләр ясаучы татар егетен балет мәктәбе укучылары беркайчан аңламый. «Кара, аңа сәгать ярымлык күнекмәләр аз, туктап торганы да юк», – диешәләр.

Нуриевнең буе – 173 см. Аның аяклары да озын түгел, күнегүләр аңа җиңел бирелә дип булмый. Аннары холкы да кызып китүчән. Бергә укыган Минея болай искә ала: «Ул һәрчак ашыкты. Бер көн без класста икәүләп күнекмәләр ясый идек, шулчак безнең класска өлкәнрәк малайлар керде. «Күрмисезмени, монда без шөгыльләнәбез!» – дип кычкырды да, аларга урындык тотып атты. Тегеләр тизрәк качты... Аның холкы яшьтән шундый иде...» Әйе, һәрвакыт үз сүзле, тиз кызып китүчән, кире егет тәүлекләр буе диярлек биергә өйрәнергә әзер була. Тәмам арганчы. Кичләрен ул балет тамашаларын карарга чыгып китә. Буш сәгатьләрендә музейларга йөри. Ленинград зыялыларын йотлыгып тыңлый.

Тик бу балалар да, үзен аңламаган әтисе дә, башкалар да бик ерак хатирәләрдә генә калачак. Аңа инглиз телен өйрәткән Ленинград укытучысы да, егеткә булышлык күрсәткән балет остазы А.Пушкин да КГБга күп тапкыр чакыртылачак. А.Пушкин 1970 елда урамда йөрәк өянәгеннән вафат булачак.

Р. Нуриевнең әтисе, улын күрмичә, 1968 елның февралендә үпкәдәге яман чирдән үлеп китә. Фәридә ханым 1961 елда инде лаеклы ялда була, ул улының чит илдә калуы турында хәбәрне ишеткәч: «Улымның акчасы бармы икән?» – дип кенә кабатлый. Р.Нуриевне Франциянең мәдәният министрлыгы вәкиле Рош-Оливье Местр һәм русча белүче импрессарио Жанин Ренги белән берлектә, 1987 елда гына 72 сәгатьлек виза белән Россиягә кертәчәкләр. Үлем хәлендәге әнисе белән бәхилләшү өчен. Тик әнисенең улын танырлык, аның белән сөйләшеп, хушлашырлык хәле генә булмаячак. Аны Уфа театрына, иң беренче балет тамашасын карарга алып барган ананың... 1961 елдан соң янә үз Ватанын күрүгә ирешкән Нуриев Россиядә үзен чит ил кешесе итеп сизә. Мондагы рухи салкынлык аның җанына үтә. «Мин канәгать калмадым, өмет юкка чыкты. Берни дә үзгәрмәгән. Тик мин башка инде, – ди ул әйләнеп кайткач. – Әнием яртылаш сукыр. Мин аның күз алдымда үлеп баруын күрдем...» Өч ай да үтми, Рудольфның әнисе 80 яшендә вафат була.

Ә бит биюче егетнең совет тормышы уңай башлана. Рудольф инде башкалардан шулкадәр аерылып тора. «Биюгә үз карашы булган, үз техникасына ия әзер артист, сирәк кош!» – диләр татар егете хакында.

● Р. Нуриев һәм М. Фонтейн. «Аккош күле».

(Дәвамы киләсе санда).

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

Казан Кирмәнендә күргәзмә

Казан Кремленең Кабулханә (Присутственные места) залларының берсендә Татарстанның халык рәссамы Мөдәррис Минһаҗевның 50 еллык иҗатына багышланган шәхси күргәзмәсе ачылды.

«Күргәзмәне иҗатымның 50 еллыгына һәм әтинең 110 еллыгына багышладым. Мин әтинең һәр юбилеена күргәзмә ясыйм. Быел котмәгәндә шушы зур залда үткәрергә туры килде. Күргәзмәләрне еш оештырсам да, бу – Казан Кремлендә беренчесе. Күптәнге хыял иде ул. Аллаһ рәхмәте белән, хыялым тормышка ашты. Шушы урында борынгы бабаларыбыз Казан ханлыгын яклап соңгы тамчы канына кадәр сугышкан. Шуңа күрә Кремльдә күргәзмә ясау тормышымда аеруча истәлекле», – диде Мөдәррис Минһаҗев.

Күргәзмәдә рәссамның илле еллык иҗатыннан илле картина урын алган. Биредә иҗатчының еллар узган саен, камилләшә баруы, гомеренең төрле этабында нинди жанрларга игътибар биргәне күренә.

Татарстан Мәдәният министрлыгының матбугат хезмәте җитәкчесе Айрат Фәйзрахманов Кабулханәдә рәссамнар арасында шәхси күргәзмә М.Минһаҗевныкыннан башланып китүен билгеләде. Төзекләндерелгән бина узган ел азагында кулланышка тапшырылды.

Күргәзмә ачу тантанасына рәссамның иҗатташлары, якташлары, дуслары Татарстанның төрле почмакларыннан җыелган иде. Саба районы Тимершык авылыннан килгән якташы Минислам Кәримов Саба районы халкы М. Минһаҗев белән ихлас горурлануын белдерде. «Аның рәсемнәрендә без Саба урманнары чалымнарын, безнең як орнаментларын күрәбез», – диде ул.

Нәкышчы, Г.Тукай бүләге иясе Нәҗип Нәккаш яңа иҗат иткән хезмәтләрен югары бәяләде. «Татарның халыктан чыккан бизәкләрен үз күңеле аша үткәреп, милли әсәрләр иҗат иткән. Гадәттә, без орнаментны графикага кертәбез, ә ул аны рәсем сәнгатенә керткән. Бу аның иҗатын баета», – диде Нәҗип Нәккаш.

Күргәзмә ике ай эшләячәк.

Рифат КАЮМОВ.

Көзнең гадәти бер көне

(Ахыры.Башы 40 нчы санда).

Нуриәхмәт Зиннурович Риза Сафичка борылды.

– Синең ишеләрне йолкып чыгарырга ыргаклы колга табылмас дисеңме? – дип ысылдады ул. – Ә застой каян килеп чыктымы? Синдәй һава бозучылар күбәйгәнгә ясалды ул. Яхшы чакта үкчәңне ялтырату ягын кара. Без перестройка ямышы белән шаяра алмыйбыз! Балалар безнең киләчәгебез һәм киләчәгебезне бозарга юл куймабыз. Не позволим!..

Эшләпәләләр чыгу ягына атлады. Өч-дүрт адым киткәч, Нуриәхмәт Зиннурович, Гыйниятовка ияргән Мәрзия ханымның уңайсызланып елмайган йөзен күреп, янә туктады.

– Кайту белән шалтыратсын, – диде ул, директор ишегенә ымлап. – Давай, үзегезгә бирелгән участокны до ума доводить итеп бетерегез. Аңладыңмы?

– Аңладым. Җиткерермен, Нуриәхмәт Зиннурович... Карагыз әле, Нуриәхмәт Зиннурович, беләсезме...

– Тагын нәрсәләр бар?

– Карт өчен, зинһар, гафу итегез инде... Шариклары да бушый башлады, хи-хи-хи, картайды. – Бүлмәдә чукраклар юк иде. Тавышын әкренәйтсә дә, һәркемгә ишетелерлек итеп сөйләде Мәрзия ханым... – Яшьлегенә кайтырга ярата, сугышта йөргәннәре белән кизәнгәли... Ничек диләр әле... Эт картайса, койрыгын сөйрәр, кеше картайса, үткәнен сөйләр, диләрме? Хи-хи-хи...

– Зарар юк. – Нуриәхмәт Зиннурович, укытучы халкын сискәндерерлек итеп, тамак кырып куйды. – Бугаз киерүчеләрне чат саен очратып торабыз. Теләсә кайсы коридорда хәзер шундый үпкәчеләр мыжгый.

Нуриәхмәт Зиннурович кәлемсерәп куйды, галстугын төзәтте, бүлмәдәгеләргә күз кысты һәм чыгу ягына атлады. Аңа Басыйр Гыйниятович иярде. Мәрзия ханым да бөгелә-сыгыла эшләпәләләр артыннан кузгалды. Шып туктап калуына борыны төбендә дөбердәп ябылган ишек сәбәпче булды. Ул, аптырап, як-ягына каранды, бер урында таптанып калды, тирән итеп бер көрсенде һәм мәченекедәй тавышсыз адымнары белән үз өстәленә таба юыртты.

– Басыйр Гыйниятовичны нишләп йөри икән? – дип куйды физика укытучысы Гөлзар ханым, идәндә ярылып яткан пычрак эзләрне сагышлы күзәтеп. – Бер сүз эндәшмәде.

– Кем белгән аларныкын. Безгә караңгы, – дип куйды тарихчы.

– Ә мин беләм, – диде Һашим.

– Әйт белгәч.

– Басыйр Гыйниятович бәләкәй кеше түгел. Шуңа Нуриәхмәт Зиннуровичка тагылган да. – Һашим Мәрзия ханымга шомланып кына күз төшереп алды һәм кулларын җәеп җибәрде:

– Бәләкәй койрык тагып йөри алмый ич инде ул.

Пырхылдап көлеп җибәрделәр. Бүлмә эче ничектер яктырып киткәндәй булды.

– Ә нигә соң ул койрык? – дип кызыксынды Алсу исемле яшь укытучы кыз.

– Болгап йөрергә. Әйтик, патшаларга яраннары ияреп йөргән. Хәзерге түрәләргә актив ияр. Магазин төбеннән китмәүче, киң профильле сәрхуш Әхмүшнең дә койрыгы бар. Үзеннән дә аламарак иярченнәр табып тора.

– Ә бәлки койрыкка омтылыш табигыйдер, ансыз булмыйдыр бу дөньяда?

– Кем белә, – диде Һашим, теш төбен суырып, – кешене кеше эксплуатацияләү бездә бетте, диләр. Ә менә берәүнең икенче берәүне койрык итеп тагуына каршы бернинди чикләү дә, чара да юк.

Кыңгырау шылтырап, әңгәмәне өздә. Укытучылар, уртак киштәдән класс журналларын алып, классларга ашыкты. Риза Сафич та, урыныннан торып, протезларын шыгырдата-шыгырдата тәрәзәгә таба китте. Хәзер аның буш дәресе. Буш дәрес булуы әйбәт әле, чөнки кинәт кенә башы шаулый башлады, зиһене таралыбрак тора, нәрсә дә булса уйлап китү өчен фикер җебенең очы табылмый... Туктале... Нәрсә дә булса уйларга кирәк бит инде. Нәрсә турында булса да эзлекле фикер йөртергә...

Ә бәлки Һашимның эт, койрык, дип чагыштыруы уңышсыздыр, дигән уй кабынып узды аның миен көйдереп. Риза Сафич, шушы фикергә тотынып, аны эзлекле дәвам итеп карамакчы булды. Кем инде ул Гыйниятов олы койрык саналыргa?.. Гап-гади йолкынып беткән төзелеш оешмасының сүгенеп сөйләшә торган бер башлыгы.

Тәрәзәдән кыеклап яңгыр яуганы күренә. «УАЗ» машинасы бата-чума кап-кара басу уртасыннан каядыр шуыша.

– Хикмәт, – дип көрсенеп уйланды Риза Сафич, – урманда җәнлек, авылда кеше кими. Кеше җитми... Беркайда һәм беркайчан да җитми... Кеше һәм җәнлек... Ә бит кешеләрдән барлык төр җәнлек сыйфатларын табарга мөмкин. Кемдә попугайлык көчле, кемдә төлкелек, сарыклык, куянлык, еланлык, ишәклек, бөркетлек... Саный китсәң... Шулай булмаса, аны табигатьнең тажы, димәсләр иде. Ә шулай да кешегә иң якыны – эт.

...Этләр, этләр... Зурлар, бәләкәйләр... Менә зур эт. Ул әллә нигә бер генә өрә. Кирәк санаса, умыра, санамаса, сине күрми ары китә. Ә бәләкәе чиный, тузан туздыра. Кусаң, чигенә-чигенә өрә. Китеп барсаң, өрә-өрә ияра. Әйтик, мәктәпкә олырак урыннан зыялырак берәү килә, мәхәбәтлек саклап сөйләшә һәм итагатьле генә саубуллашып кайтып китә. Шундый вәкаләт йөкләп җибәрсәләр, кемне дә булса эшеннән бушатуы да мөмкин. Ләкин шау-шусыз гына, ипләп. Менә берзаман ронодан бер сары томшыклы, яисә министрлыктан бер сырты саргайганы рәхим итә. Болар йә бөтенләй укытмаган, бу эшкә сәләтсез кешеләр яки, укыту эшеннән качып, җылы оя табучылардан. Укыта белмәсәләр дә, өйрәтергә кодрәтләреннән килә. Аптырап тормасыннар өчен, аларга бер иш калып тоттырып җибәргәннәр. Шул калыпка салып әлеге Мокытдисәме, Мөкәтдисәме, яки сылу җегет Мостафа, арт чүмеченә бозау аягы, синең хезмәтеңне үлчи. Сыйган өлешен мактый, сыймаганы турын хурлый. Педсовет җыйдыра, шау-шу кубара. Макаренко, Сухомлинскийдан өзекләр китерә-китерә үгет-нәсихәт укый, тәнкыйть чәчә. Асылда, берни үзгәрми, ә күпмегәдер зиһен чуала, чәч агара...

Әле узган ел шундый бер тикшерүче мәктәпкә килеп кергәндә, җыештыручы Шәргыяне очрата һәм сүз куша:

– Сез мәктәптә эшлисезме? – дип кызыксына ул.

– Әһе, – дип җавап бирә Шәргыя.

– Берәр телдән керәсезме?

– Керәм, – ди Шәргыя, – себерке теленнән.

Әһ-һәй! Тикшерүчеләребезнең күпчелеге педагогика хакында түгел, ә чисталык турында озаклап сүз боткасы куертырга ярата. Чөнки бу хакта әңгәмә кору өчен белем дәрәҗәң, эш тәҗрибәң «себерке теленнән» керүче Шәргыянекенә тигез булса да бик җитә. Һей! Теләсә кем югары үрмәли хәзер һәм бу бик зур бәла. Күтәрелү өчен әллә ни белем дә, зыялылык та кирәкми. Укымышлы кешеләрдән дә үрнәк алу кирәкмәс. Үрнәк алу өчен әнә Акбай да җитә. Югарылар каршында арт тәпиләренә басып, койрык болгарга, түбәндәгеләргә селәгәенә тончыга-тончыга сүгенергә өйрәнсәң, күпкә ирешергә мөмкин... «УАЗ» машинасы һаман күренә, сул күз әйбәт әле, шөкер... Пычрактан бик барып булмый шул. Белоруссия урманнарында саз ерып ничә чакрым үтелде икән? Колак төбендә ядрәләр сызгырганы, якында гына этләр өргән чаклар... Нәселле, хуҗаларның төп сыйфатларын яхшы үзләштергән, зур этләр...

Кинәт Риза Сафичның тыны кысылды, күкрәге чәнчеште һәм ул, өстәлләргә тотына-тотына чигенеп, артлы урындыкка ишелеп төште.

– Журнал буталган икән, – дип кабаланып ишектән Һашим килеп керде. – Кара әле, монда да юк. Риза Сафич, өченче «Б» журналын күрмәдегезме?

Җавап булмагач, ул бүлмә уртасында туктап калды. Шунда гына Риза Сафичның сәер кыяфәттә урындыкка чүмәшкәнен күреп алды. Ул, иелеп, карт остазының йөзенә карады, кулын тотты. Сөякчел, ябык куллар сап-салкын иде...

Ростәм ЗАРИПОВ

2022 ел тарихи даталарга бик бай. Күренекле галимнәребез Резеда Кадыйр кызы Ганиеваның (25 октябрьдә туа, 13 ноябрьдә рәсми теркәлә) 1932 - 21.03.2020), Азат Гыйльмулла углы Әхмәдуллин (13.10.1932 - 08.12.2021), Рифат Хәсән углы Сверигин (01.08.1932), Гомәр Фәйз углы Саттаровларның (02.07.1932 - 26.08.2020) 90 еллыклары. Аларның дүртесе дә бер үк елда туган, бер үк Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укыган, бер үк вакытларда диярлек гыйльми-педагогик эшкә керешкән, саллы-саллы хезмәтләр язганнар, меңәрләгән шәкерт-студентларга белем-тәрбия биреп, остаз-профессор дәрәҗәсенә ирешкәннәр. Ни кызганыч, инде әлеге затларның өчесе арабыздан китеп барган. Рифат әфәндебез исә, әдәбияттан тыш спортны да ярата. Унынчы дистәсен дә хәзерге кебек йөгереп, исән-сау уздырсын иде. Бүген исә үземнең укытучым, ярты гасыр буена бергә эшләгән хезмәттәшем Резеда Ганиева хакында күзәтүләребезне җиткерергә җөрьәт итәм.

КҮПКЫРЛЫ ГАЛИМӘ

(Профессор Резеда Ганиеваның тууына 90 ел)

Резеда Кадыйр кызының озын һәм катлаулы гомер юлы хәзерге Яшел Үзән районы Кече Шырдан авылыннан — Каюм Насыйриның туган төбәгеннән башлана. Бөек мәгърифәтченең якташы булу аңа әхлакый җаваплылык та өсти. Үзенең күпкырлы, нәтиҗәле эш-гамәлләре белән ул чын мәгънәсендә «Каюм бабай»ның лаеклы дәвамчысы дәрәҗәсенә күтәрелде.

Булачак галимә гадәти игенче-крестьян гаиләсендә беренче бала булып дөньяга килә. Күп кенә чордашлары кебек, тормышның кыенлыкларын күреп үсә. Әтисе сугышның беренче көннәреннән үк фронтка җибәрелә һәм 1941 елның 16 сентябрендә үк һәлак тә була. Ленинградта җирләнә. Атасыз, ятим калган дүрт баланы тәрбияләү энисе Хәбирә апа (1911-2002) җилкәсенә төшә. Өлкән кызы исә аның төп таянычы, терәге була.

Кадыйр кызы иң әүвәл туган ягындагы җидееллык мәктәптә белем ала. 1947-1951 елларда Казан педагогия училищесында укып, «башлангыч мәктәп мөгаллимәсе» белгечлеген ала. 7 ел буе Кече Шырдан, Мүлмә (Биектау районы), Казан мәктәпләрендә укытучы булып эшли. Читтән торып, 1958 елда Казан университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлый. Аның И. Нуруллин җитәкчелегендә «Г.Тукай шигырьләренең ритмикасы» темасына язылган диплом эше югары бәяләнә, дәүләт комиссиясе аны аспирантурага тәкъдим итә. Шунысы гыйбрәтле: Р. Ганиева гомере буе Тукайга тугры калды. Диплом эшеннән, кандидатлык диссертациясеннән тыш, аның бөек шагыйрьгә мөнәсәбәтле күпләгән мәкалә-хезмәтләре бар. «Тукай энциклопедиясе» өчен генә дә ул, мөгаен, йөздән артык мәкалә язгандыр. Ире, фән докторы Зөфәр Рәмиевнен шактый гына хезмәтләре, дипломчы-аспирантларының да күп кенә язмалары теге яки бу дәрәҗәдә Тукай тематикасы белән бәйле.

Р. Ганиева 1958 елның октябрендә Мәскәү дәүләт университетының СССР халыклары әдәбиятлары кафедрасы каршындагы аспирантурага кабул ителә. Фәнни җитәкчесе – Мәдинә Богданова. Башкала тормышы, андагы дәрәҗәле уку йортында белем алу яшь галимәнең фәнни-теоретик һәм гыйльми үсешенә зур йогынты ясый. Казан кызы биредә илнең күп кенә олуг галимнәре, әдипләре белән таныша, алар белән бәйләнешен өзми.

1962 елның сентябрендә Казан университетының татар әдәбияты кафедрасында ассистент булып эшли башлый. 1967 елдан – өлкән укытучы. 1964 елда «Тукай иҗатында сатира» темасына кандидатлык диссертациясе яклый. Рәсми оппонентлары М. Гайнуллин, Й. Нигъмәтуллина, гыйльми совет әгъзалары аның хезмәтен югары бәяли. Филология фәннәре кандидаты булгач, Резеда Кадыйр кызы тагын да канатланып фәнни-педагогик эшчәнлеген дәвам иттерә. 1970 елда доцентлык дәрәҗәсен ала, 1967 елның августында М.Гайнуллин, Х.Госман белән берлектә Хельсинки университетында да лекцияләр укый, чыгышлар ясый.

1968 елда кияүгә чыга. Тиз арада улы Булат һәм кызы Халидә туа. Ни кызганыч, йөкле хәлендәге кызлары 2006 елның 7 октябрендә автомобиль бәрелешендә һәлак булды. Бу фаҗигане Резеда апабыз бик авыр кичерде һәм бала кайгысыннан сәламәтлеге дә шактый какшады.

Р.Ганиева 1992 елда Казан университетында «Восточный Ренессанс и его традиции в тюркских литературах» темасына докторлык диссертация яклады. Рәсми оппонентлары - күренекле галимнәр М.Хәсәнов, А.Хайнтиметов (Ташкент), А.Гаджиев (Баку). Бу гыйльми чара Татарстанда гына түгел, ә төрки дөньяда, шәрыкшенаслык (ориенталистика) фәнендә мөһим бер вакыйга рәвешендә кабул ителде. Аңа мөнәсәбәтле күпләгән язмалар дөнья күрде. Бер ел эчендә галимәгә филология фәннәре докторы һәм профессорлык дәрәҗәләре дә бирелде. 1994 елда ул «Татарстанның атказанган фән эшлеклесе» дигән мактаулы исемгә дә лаек булды.

Р.Ганиева 2011 елның августында Казан университетында эшләвеннән туктады. Әмма ул бу уку йорты белән бәйләнешләрен өзмәде, аралашып торды. Өлкән яшьтә булуына да карамастан, галимәбез үзенең фәнни-тәнкыйди эшчәнлеген дәвам иттерде: мәкалә-хезмәтләр язды, конференцияләрдә катнашты, Татарстан Фәннәр академиясе белән хезмәттәшлек итте. 2017 елда аның 85 яше киң күләмдә билгеләп үтелде. Бу уңай белән Резеда Кадыйр кызы Татарстан Республикасының «Фидакяр хезмәт өчен», Бөтендөнья татар Конгрессының «Татар милләтенә күрсәткән олы хезмәтләр өчен» медальләре белән бүләкләнде. Аның үлеме гыйльми-мәгърифәти-мәдәни җәмәгатьчелек тарафыннан зур югалту рәвешендә кабул ителде. Мәрхүмә Казанның Самосырово бистәсендәге мөселман зиратында җирләнде.

Р.Ганиеваның эшчәнлеге күпкырлы, барыннан да элек ул – укытучы-педагог. Педучилищеда, югары уку йортында алган бу төп белгечлегенә гомере буе тугры калды. Дистә елга якын мәктәпләрдә балалар укытты, 50 ел буена университетта лекцияләр сөйләде, студентларга белем-тәрбия бирде. Ораторлык сәләтенә ия булган таләпчән бу мөгаллимәнең тирән эчтәлекле лекция-дәресләре аудитория тарафыннан кызыксынып тыңлана иде. Университетта төрле курслар алып барды. Татар әдәбиятыннан тыш, озак еллар буе «Шәрык әдәбиятлары тарихы»ннан лекцияләр сөйләде. Тукай, иҗат методлары буенча махсус курслар алып барды. 90 нчы еллардан башлап галимә Г.Исхакый мирасын халыкка кайтару юнәлешендә дә нәтиҗәле эш-гамәлләр кылды, әдип хакында махсус курс та алып барды. Р.Ганиева университетның татар филологларына гына түгел, ә урыс, журналистика бүлеге студентларына да лекцияләр сөйләде.

Чын мәгънәсендә университет укытучысы булу өчен, үз предметыңны тирәнтен өйрәнгән галим булу да зарури. Бу яктан Р.Ганиева күпләргә үрнәк иде. Ул студент, аспирант елларыннан алып гомеренең ахырына кадәр фәнни-тикшеренү эшләре алып барды, күпләгән китап, монографияләр, төрле телләрдә (татар, урыс, төрек, украин, үзбәк, азәрбайҗан...) йөзәрләгән-йөзәрләгән мәкаләләр бастырды. Дистәләгән энциклопедияләрдә, белешмә-сүзлекләрдә аның язмалары урын алды. Аның халыкара конференцияләрдә сөйләгән доклад-чыгышлары да йөздән артып китә. Галимәнең «Сатирическое творчество Г. Тукая» (К., 1961), «Восточный Ренессанс и поэт Кул Гали» (К., 1988), «Традиции Восточного Ренессанса в тюркских литературах Средневековья и Нового времени» (К., 2014) һ.б. монографик хезмәтләре билгеле.

Резеда Кадыйр кызының гыйльми-тикшеренү дөньясы шактый киң, масштаблы. Үзәктә, әлбәттә, татар әдәбияты, аның тарихы, электән алып хәзергәчә булган күп кенә вәкилләре. Болар арасында төп урынны Кол Гали, К. Насыйри, Ф. Әмирхан, Н. Думави, Г. Ибраһимов, аеруча Г.Тукай һәм Г.Исхакыйлар алып тора. Шунысы үзенчәлекле: галимә татар сүз сәнгатен еш кына әдәби бәйләнешләр яссылыгында, чагыштырма аспектта карый. Аның Әл-Мәгарри, Җ. Руми, Нәсими, Нәваи, Физули һ.б. Шәрык классиклары хакында да язмалары бар. Профессорның дистәләгән хезмәте Шәрык Ренессанс-Яңарыш хәрәкәтен, аның халкыбызның рухи тормышындагы ролен яктыртуга багышланган. Р. Ганиева иҗат методлары (бигрәк тә романтизм, реализм), жанрларны, башка күп кенә әдәби-эстетик мәсьәләләрне ачыклауга да үзеннән зур өлеш кертте. Аның хезмәтләре өчен, гомумән, теоретик-методологик тирәнлек хас.

Мәгълүм ки, соңгы дәвер татар әдәбиятының күпчелек язучылары Казан университетында белем алган. Укытучы буларак аларның иҗади үсешендә Р. Ганиеваның да шактый өлеше бар. Ул еш кына әдәби тәнкыйтьче буларак та чыгышлар ясый, иҗат көчләренә үзенең төпле, гадел хәер-фатихаларын бирә.

Элегрәк аспирантурада уку өчен урыннар чагыштырмача аз бирелә иде. Шуңа карамастан, Р. Ганиева ике дистәдән артык аспирант белән җитәкчелек итте, мөһим темалар буенча диссертацияләр яздырды. Болар арасында Р. Харрасова, Р.Мусабекова, А.Шамсутова, Д.Абдуллина һ.б. әдәбиятчылар бар.

Профессор Р. Ганиева — татар дөньясында гына түгел, ә Идел-Урал буе җөмһүриятләрендә, хәзер мөстәкыйль дәүләт булып яшәүче төрки халыклар арасында да билгеле. Аны үзбәк, чуваш, азәрбайҗан, казах, кыргыз һәм башка кавем әдәбиятчылары таный, хөрмәт итә.

Кыскасы, Резеда Кадыйр кызы Ганиева үзенең күпьеллык гыйльми-педагогик, мәгърифәти эшчәнлеге белән безнең рухи тормышыбызга зур өлеш кертте. Аның хезмәтләре, мирасы бүгенге көнебез өчен дә файдалы, аваздаш. Остазы Резеда апасына багышлап язылган бер әсәрен (2003) шагыйрә Эльмира Шәрифуллина мондый юллар белән тәгәлли:

...Акыл белән сөйләү осталыгын,
Шигъри сүзнең тәмен, кыскалыгын,
Фәнни телнең могҗизалы көчен,
Рәхмәт Сиңа, күрсәткәнең өчен!

Авторның бу изге теләкләренә без дә рәхәтләнеп кушылабыз.

Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ,
филология фәннәре докторы, КФУ профессоры,



Рәссам, гамәли сәнгать остасы Рәшид Әсәдуллинның (1958-2020) иҗаты – күпләрнең хәтерендә.

СӘНГАТЬКӘ

«Рәшид Абдулла улының әсәрләре – илебез һәм чит дәүләтләр тупланмаларында. Аның металлдан ясалган әсәрләре хәтерләребездә саклана. Ул гел катлаулы сәнгати тел эзләүдә булды, – дип искә алган иде аның бертуганы Фәрит Әсәдуллин «Татар дөньясы» газетасында. Фәрит Әсәдуллин әйтүенчә, аның иҗатчы туганы һәрдаим үз темасын эзләүдә булган: «1990 елларда ул татар шәмаилләре дә язып караган иде. Аларның барысы да туганнарыбызда саклана.

Безнең әниебез Рәшиднең бар ният-максатларын һәрчак алга әйдәүчеләрдән булды. «Рәшиднең куллары алтын», – дип еш кабатлады ул. Стилизацияләр дә, майлы буяулар белән язылган картиналар да, балчыктан ясалган эшләнмәләре дә күп иде аның остаханәсендә. Соңгы елларда металл буенча эшләде. Аның «Казан песие» – үзе генә дә ни тора!

Әтиебез шаянлык, юмор хисе белән үрнәк булды. Рәшид тә бу сыйфатын эшкә җикте. Аның сатирик рәсемнәре, карикатуралары Төркиядә узган Халыкара бәйгеләрдә дә, башка илләрдә дә җиңеп чыкты. Ул китаплар өчен иллюстрацияләр дә иҗат итте. Әтиемнең китапларын да, минем «Москва мусульманская» китабымны да бизәде.

Иҗади кумиры – Н.И.Фешин булгандыр. Ул әлеге рәссамның иҗатына соклана иде. Аның холкына – турылык, кирәк-кирәкмәгән белән ризалашмау бик хас иде. Классик эшсөяр! Башкалар өчен – юмарт, үзенә карата – аскет. Мин-минлексез һәм дуслары белән сөйләшкәндә, иҗатта тотып торган урынын югарыга чөймәүче иде. Аның вакытсыз дөнья куюы – безнең барыбыз өчен дә чиксез югалту.

Рәшид иҗат иткән әсәрләр күп кулларга таралды. Хәзер туганымның бар хезмәтләрен җыю, бер системага салу мөһим. Татарстан Рәссамнар берлеге һәм Сынлы сәнгать фонды да бу эшләрдән читтә калмас, дип өметләнәм».

Рәшид Әсәдуллин 1958 елда Казан зыялылары гаиләсендә туган. Аның әтисе Абдулла Шаһи улы Әсәдуллин (1926-2004) – профессор, педагогика фәннәре докторы, дистәләрчә уку китабы авторы. Татарстан Фәннәр академиясенең тарих институтында, милли мәгариф тарихы һәм теориясе үзәгендә хезмәт куйган.

Рәссамның бертуган абыйсы Фәрит Абдулла улы – Россиякүләм мәгълүм дин һәм җәмәгать эшлеклесе, галим. Ислам һәм гарәп теле белгече.

Булачак рәссам Рәшид Әсәдуллин 1971 елда Казанның 2 нче балалар сынлы сәнгать мәктәбендә укый башлаган. 1975-1979 елларда Казан сынлы сәнгать училищесында белем алган.

Ул – Татарстан Рәссамнар берлегенә дә, «Россия Рәссамнар берлеге» иҗади-җәмәгать оешмасының «Татарстан рәссамнары берлеге» бүлегенә дә кабул ителгән иҗатчы. 2020 елның көзендә якты дөньядан китеп барганга кадәр, бары тик сәнгать өлкәсендә генә хезмәт куйган шәхес. Якын дуслары аны әле дә сагынып искә ала. Әйтик, металлдан әсәрләр иҗат итү остасы, галим, тәрҗемәче Рәшид Төхфәтуллин аның турында болай дип сөйләде: «Рәшид үзенчәлекле рәссам иде. Андый рәссам башка юктыр да. Югары профессионализм тамгасы сугарлык металл сын-

нар, композицияләр ясау остасы иде ул. Аның әсәрләре искиткеч фантазия, югары зәвык һәм бик төгәл итеп башкарылган булулары белән аерылып тора иде. Алар соклану хисе тудырмый калырга мөмкин дә түгел. Рәшид иҗат эшендә тутыкмас корыч, җиз, бакыр, алюминий белән генә чикләнеп калмады, башка төр материалларны – агач, пыяла һәм хәтта пластикның кайбер төрләрен дә кулланды. Әсәрләренең барысы да бик камил килеп чыга иде. Сәнгатьнең башка төрләре һәм жанрлары да аңа буйсынды, мәсәлән, рәссамның шелкография техникасындагы абстракцияле графикасы күпләргә таныш.

Рәшиднең хезмәтләрен күргәзмәләрдә дә күреп соклана идем, әмма аның белән якыннан танышуым соңрак булды. Рәшит Әсәдуллин, мәрхүм, гадел һәм әдәпле кеше иде. Үз принципларына тугры шәхес. Үзенең хаклы икәнен аңласа, бернинди килешүләргә бармады, кайчак кискен эш йөртте, ләкин һәрвакыт чын зыялы булып кала иде!

Иҗатында да һәм тормышында да аңа перфекционизм хас булды. Шул ук вакытта ул кеше хәленә керүчән, авыр хәлгә калган дустына яисә аңа берәр үтенеч белән мөрәҗәгать итүчегә ярдәм итәргә әзер иде. Әнисе авырып киткәч, озак вакытлар әнисен дә карады...»

Менә рәссамның тагын бер дусты, Татарстанның декоратив-гамәли сәнгать остасы Ринат Әхмәтов та әңгәмә вакытында аны мактап искә алды: «Без Рәшид белән остаханәләрдә танышып дуслаштык. Аның да Сынлы сәнгать фонды бинасында үз остаханәсе бар иде. Ул һәрбер теманы шулкадәр җанлы, кызыклы итеп сөйли белгәнгә күрә, бирегә дуслары күп булды. Ләкин соңрак Рәшид үзгәрде. Бәлкем, кул бармаклары белән килеп чыккан кайгы дә үзгәрткәндер аны... Чөнки ул биредәге остаханәдә сул кулының ике

ТУГРЫ РӘШИД

бармагын өздерде... Мондый кайгы һәркемне үзгәртә, ә рәссам, гамәли сәнгать остасын аеруча... Ләкин ул бу кайгыны да җиңеп чыга алды.

Тагын шунысы да бар: Рәшид Әсәдуллин – ул рәссам да һәм шул ук вакытта оста һөнәрче дә иде. Ә мондый дәрәҗәгә һәркем күтәрелә алмый! Йә рәссам, йә бары тик һөнәрче, оста гына булып кына калучылар шактый безнең даирәдә...

Аның үз әсәрләрен беркайчан да эскизга карап ясамавына бик гаҗәпләнә идем! Күп эскизлар ясап утыру – аңа хас нәрсә түгел иде. Барысын да тиз генә, үтеп барышлый гына дигәндәй, иҗат итте ул. Ә инде озаклап, яңадан төзәткәләп, нидер өстәп ясавы – монысы икенче мәсьәлә. Ләкин бу төзәтмәләр аның әсәрләрен тагын да тирәнрәк мәгънәле һәм кызыклырак итте.

Аны күпләр үз итте. Бик акыллы иде, шуңа күрә дә башкалар аның белән еш киңәшләште. Минем өчен исә ул осталык өлгесе булды. Аның эшләренә карагач: «Ничек шулай мөмкин икән!» – дип соклана идем. Ул бит сыгылмалы җиз, бакыр гына түгел, ә авыр металл, тутыкмаучы тимер белән дә җиңел эшләде. Әсәрләренә ювелирларга гына хас нәфислек, төгәллек тә бирә, эшләнмә җөйләрен дә күрсәтмәслек итеп ялгый белде. Берәр хезмәткә алынырга теләсәм, аннан киңәш сорыйм, ә ул һәрчак бик гади генә итеп: «Ал да, ясап кара! Курыкма! Ясап карагач, үзең аңларсың!» – ди иде.

Аның җете төстәге, динамика кертелгән, кызыклы рәсемнәрен дә хәтерлим. Рәшид кебек декоратив-гамәли сәнгать остасын башка белмим дә... Аны металлны сәнгати эшкәртүче остага саный идем».

Хатирәләре белән бүлешүен үтенеп, таштан үю осталарыбызның берсе, озак еллар дәвамында Р.Әсәдуллин белән бергәләп төрле иҗади проектлар башкарган Вадим Ануфриевка да мөрәҗәгать иттем. «Рәшид хакында сәгатьләр буе сөйләргә мөмкин», – диде Вадим Ануфриев. Остазы турында җылы фикерләрен җиткерде ул: «Рәшид белән бергә эшләү бәхете тигән кешеләрнең берсе мин. Ул тирән, бик кызыклы шәхес, зур оста иде бит! Безнең холыкларыбыз да бер-берсенә охшаш булып чыкты. Икебез дә тыйнак. Сынлы сәнгать фонды остаханәсендә таныштык та бергәләп җитди эшләр иҗат итә башладык. Мәсәлән, Казанның «Ланцелот» рестораны өчен үзенчәлекле, бик матур әсәрләр ясадык. Нәтиҗәдә, әлеге бина интерьеры инде берни белән дә шаккатырып булмый торган шәхесләрне дә хәйран калдырды. Ул искиткеч эш сөючән иде! Мин дә шундый. Менә инде 40 елдан артык таштан уям. Рәшид белән бергәләп иҗат итү дәверендә иҗатның башка аспектына – металл белән эшләү нечкәлекләренә төшендем. Металл пластикасын тудырырга өйрәндем. Ул бит бары рәссамлыкка гына укыган, ә нинди осталыкка ирешә! Һәрчак хезмәттә булды.

Остаханәсенә кергән һәркем белән иҗат эшеннән аерылмыйча гына сөйләште. Аның шушы сыйфатын барысы да ихтирам итте. Беркайчан да буш сүзләр сөйләшеп утырмады. Аңа дан да кирәкмәде, шөһрәт тә... Дустымның сүзләре дә күңелем түрендә, аның шундый тезисы бар иде: «Мин булдыра алган кадәр эшләргә тиеш, булдыра алган кадәрдән начаррак иҗат итсәм, гөнаһ булыр. Аллаһ Тәгалә сиңа насыйп иткән талант югарылыгында гына иҗат итәргә кирәк!» Кайчак заказчылар үзләре үк аңа ул кадәр тырышма, диләр иде, әмма Рәшид барыбер да иҗади эшләрен җиренә җиткерде. Һәрчак нәрсәдер уйлап таба, ни дә булса өсти иде. Һәм аларны һәрчак ничектер җиңел итеп, сөйләшә-сөйләшә генә башкарды... Аның техник процесста кулланган үз алымнары булды, үз тәҗрибәсе... Дустымның иҗатын яхшы беләм. Аннан күпкә өйрәндем. Шуның белән үземне бәхетле дип саныйм».

Рәшид Абдулла улы иҗатындагы керамик плитәләргә майлы һәм акрил буяулар белән ясалган рәсемнәр агач кысаларга беркетелгән һәм бу кысаларның һәммәсендә оста тарафыннан кабатланмас бизәкләр дә уелган. Күпләр балык символын ошата. Әлеге рәссам да балык сурәтләренә битараф булмаган. Мәсәлән, «Чуртан» эше агачтан уелган, ә «Космоста йөзеп йөрүче балык» исә корычтан ясалган.

Останың иң үзенчәлекле эшләре – корычтан, җиздән, агачтан, башка төр материаллардан эшләнгән, кечерәк күләмле сыннар. Алар арасында иң сокландырганы – металлдан иҗат ителгән «Баст». XXI гасыры сыны дип атасак арттыру булмас, мөгаен. Бүгенге көндә ул Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендә саклана. Аның эшләре төрле дәрәҗәдәге даирәләрдә һәм дә иң югары дәүләт эшлекләренең шәхси тупланмаларында калды. «Алтын үгез», «Корыч балык», «Хан сандыгы»... Болары да инде төрле тупланмаларда. Останың һәрбер әсәренең техник эшләнеше катлаулы. Әйтик, ул иҗат иткән, ике метр чамасы озынлыктагы гитара да гадәти генә түгел, аңа килешле итеп төрле өстәмә бизәкләр дә беркетелгән. «Майя календаре» хезмәте дә агач, җиз һәм бакырдан.

Талантлы шәхесебезнең гомере тәмамланса да, алдагы елларда сәнгать белгечләре тарафыннан аның иҗатын колачлаган тулы бер каталог төзелми калмас, дип тә өметләник.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

Курчак театрының примасы

«Бала чагымда уйнау эләкмәде, миңа 10 яшь чагымда әнием сеңлемне алып кайтты. Үзе фермада сыер савучы булып эшли иде. Сөтлебикәләр янына көненә өч бара, өч кайта. Сеңлемне карау да, өй эшләре дә минем кулга калды. Авыр хезмәтен күреп, әниемне бик кызгана торган идем, кайчак аны алмаштырып, 25 сыерны кул белән савып кайттым. Җырчы булырга теләп, Казан музыка училищесына барсам да, курчак театрында эшләргә насыйп әйләде. Шуннан бирле һаман курчак уйнауда. 43 ел гомер сизелми дә үтеп киткән. Аллаһ бала чагымны озынайтырга, уйналмый калган елларны кайтарырга теләп, мине курчак театры артисты иткән, күрәсең...» Татарстанның халык артисты, «Тантана» театраль премиясе иясе, курчак театрының примасы Рәмзия Фәйзуллина 28 октябрьдә «Әкият» театрында иҗатташ дусларын җыеп матур гомер бәйрәмен билгеләп үтә.

Актриса Р.Фәйзуллина кебекләрне «асылташ» диләр. Курчак театрына бөтенләй уйламаган җирдән килеп, прима, йолдыз дәрәҗәсенә күтәрелү бөтен артистларга да язмаган. Җырга сәләте Рәмзия Мәхмүт кызын шулай югары үрләргә ирештерә. Р.Фәйзуллина спектакльләрдә һәрвакыт героиняларны уйный. Җырчы булмаса да, Хәснул Вәлиуллин, Луиза Батыр-Болгари, Шамил Шәрифуллин, Мәсгудә Шәмсетдинова һ.б. олы талантлы композиторларыбыз иҗат иткән җырларны башкара. Спектакльдә җыр, музыка юк икән, үзе сорап яздыра. Сеңлесен әнисе урынына карап үстергән кеше буларак, балаларга ни кирәген яхшы аңлый.

Әмма һәр җырлый белгән кеше йолдыз булмаска мөмкин. Һәр уңыш төбендә зур хезмәт ята. Курчак уйнау, дип әйтүе генә җиңел. Чынлыкта исә беренче елларда театр тормышы җиң сызганып эшләп үскән авыл кызына да җиңел бирелми. Курчаклар авыр, аларны спектакль буе күтәреп торып куллар арый, күзләрдән яшь бөртекләре тәгәри. Авырлыкка чыдамыйча, актриса курчакларны төшереп җибәрә. Янәшәдә олырак коллегалары баш өстендә йодрыклар болгый. Спектакльне өзәсең, янәсе. Ул елларда җырларны яздыру гадәте юк. Бер үк вакытта баянда уйныйлар, җырлыйлар. 45 көнлек гастрольләргә чыдау өчен дә көчле, нык ихтыярлы шәхес булу кирәк.

Көчле хатын-кызларның күбесенә тормыш буйлап ялгыз атларга язган. Р.Фәйзуллинаның яхшылыгы үзенә үк әйләнеп кайта. Әнисе Зәкия апа белән алар икәүләп күз карасыдай саклап-кадерләп, улы Вилданны үстерәләр. Бүген Вилдан – баһадир егет. Аның янәшәсендә әнисе назлы, иркә гөл кебек.

Йолдыз сүзе күпләрнең тешенә тия. Әмма бу без биргән бәя түгел. Күренекле театр белгече Рәүф Игъламов Р.Фәйзуллинаны шулай бәяләгән. «Театрда иҗат мөмкинлекләре чикләнмәгән ике актриса пәйда була, – дип язган ул «Курчаклы уйнау – җитди эш» исемле китабында. – 1980 елларда труппага җырчы Рәмзия килеп кушыла һәм беренче рольләре белән үк тамашачыны олы таланты белән шаккатыра. 1990 елларда ул бердәнбер актриса буларак төрле жанрларда һәм төрле стильдәге пьесаларда осталыгын раслый. 1990 еллар башында театр училищесын тәмамлап труппага Наталья Егорова килә һәм Р.Фәйзуллина кебек ул да нәфис иңнәренә бөтен театр репертуарын күтәрә. Шундый зур актрисаларның пәйда булуы репертуарга да йогынты ясамыйча калмый», – дип фикерен дәвам иткән галимебез.

Чыннан да, Р.Фәйзуллинаның кайсы ролен алып карасаң да, бөтенесе «Әкият» курчак театры тарихына алтын хәрефләр белән язылган. «Спектакльләрдә уйнау миңа һәрвакыт җиңел бирелде», – ди актриса. Шуңа күрә, мөгаен, беренче рольләре белән үк ул уңыш казана. Беренчеләрдән булып уйнаган «Диләфрүзгә дүрт кияү» музыкаль спектаклендә Диләфрүз ролен башкарганнан соң, Р.Игъламов Рәмзиягә «кабынып баручы йолдыз» дип бәясен бирә. Композитор Хәснул Вәлиуллин, М.Җәлил исемендәге опера һәм балет театрының хәзерге балет җитәкчесе В.Яковлев, режиссер И.Зиннуров кебек осталар иҗат иткән бу водевильдә корифейлар Азат Хәснетдинов, Миңнехан Әпсәләмов, Фәйзуллинадан ике ел алда гына труппага килгән Ришат Гыйздәтуллин һәм Рәмзия бик матур иҗади квартет тәшкил итә.

Нәби Дәүлинең Крылов әсәренә нигезләнеп иҗат ителгән җилбәзәк чикерткә һәм эшчән кырмыска турында «Җырлап узган җәй» спектакле дә бик озын гомерле була. Чәчәктән чәчәккә сикереп җырлап гомерен уздырган чикерткә, әлбәттә, Р.Фәйзуллина. Театр белгече Р.Игъламовның сүзләре белән әйтсәк, бу спектакльдә артистлар мәсәлдәге акыл сатуны бик күңелле җырлы-биюле музыкаль шоуга әйләндерә. «Җырлап узган җәй» спектаклен карап берничә буын милләт балалары үсте.

Шул ук вакытта актриса көчле драматик рольләрне дә тетрәндерерлек башкара. Ч.Айтматов әсәре, шагыйрь Зөлфәт инсценировкасы буенча куелган «Гасырдан озын бер көн» спектаклендәге Найман Ана шундыйлардан. «Бу рольне башкарганда күзләремнән яшь тәгәри, тәнем калтырана иде», – дип искә ала Р.Фәйзуллина. Найман Ананың маңкортка әйләндерелгән улы белән очрашуы – спектакльнең үзәктә торган иң мөһим урыны. Бөтен уңыш яки уңышсызлык шушы күренештән тора. Бу тамаша халык теленә кергән икән, Найман Ананың хәсрәтен тасвирлый белгән Р.Фәйзуллинаның өлеше зур.

Шагыйрь Зөлфәт әсәре буенча куелган «Таңга – Чулпан, Айга – Зөһрә» спектакле турында да легендалар йөри. Аны Оренбургта «Гостиный двор» фестивалендә дә югары бәяләгәннәр. Бу спектакльдә дә Р.Фәйзуллина нәфис иңнәренә бөтен авырлыкны ала, чөнки Р.Игъламов язганча, башка персонажлар һәркайсы аерым бер яссылыкта гына ачыла. Зөһрә кыз исә бик күп төрле хис төсмерләрен – мәхәббәтне, ялганны сөймәү хисен, гаделлеккә омтылуны чагылдыра. Спектакльдә үсеш-үзгәреш нәкъ менә Зөһрә образы белән бәйле, дигән галим. Актриса автор язганча гына уйнамый, һәрвакыт үзеннән ниндидер яңалык кертә. «Зөһрә образын сурәтләгәндә, Р.Фәйзуллина матур легенда һәм заманча пьеса арасында уртаклык таба, – дигән нәтиҗәгә килгән Р.Игъламов. – Ул моңлы йөрәккә үтә торган тавышы, салмак хәрәкәтләре ярдәмендә Зөһрәне аксөяк итеп түгел, хатын-кыз итеп сурәтли. Героиканы киметә төшә, чөнки героика башлыча традицион Европа романтик драмасы өчен хас», – дип үз бәясен биргән галим.

Бүген дә Р.Фәйзуллинаның төрле пландагы рольләре байтак. Танылган җырчы Әлфия Авзалова турында спектакльдә ул иң катлаулысын – героиняның гомер азагын тасвирлый. Ә икенче бер көнне «Кәҗә белән Сарык» әкиятендә бик сөйкемле Кәҗәне уйный. «Әкият» театрының примасы Р.Фәйзуллинаны Франция, Төркия, Азәрбайҗан, Казахстан тамашачысы алкышлады, Уфа, Оренбург, Улан-Удэ һ.б. күп кенә шәһәрләрдә тамашачылар кул чапты һәм бүген дә чәчкә бәйләмнәренә күмә. «Әкият»кә һич уйламаганда килеп керсә дә, бүген курчак театрын Рәмзия Фәйзуллинадан башка күзалдына китерүе бик кыен.

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

ҖЫЛЫ ИҖАТ

(Ахыры. Башы 40 нче санда).

Ю.Сафиуллин яшәешкә төрле караштa булган, төрле характерлы өч егетне очраштыра һәм хатын-кызга мөнәсәбәттә аларны сыный. Кыргый хайваннарны кулга ияләштерүче 40 яшьлек Картлач-берейтор 28 яшьлек Касыймны үзенә буйсынырга мәҗбүр итә. 24 яшьлек Рафаэль исә рухи һәм физик көчкә ия булуын күрсәтә. Картлач-берейтор авылдан килгән 17 яшьлек Сөембикәне үзенеке итәргә теләсә дә, җитди каршылыкка очрап, качып китә. Пьеса төрле характерлы ирләрне ачу ягыннан кызыклы эзләнүләр башлангычы булып тора. Кеше характерының катлаулылыгын аңлауда үз омтылышларының мәгънәсезлеген тоеп яшәүче Касыйм образы игътибарга лаек.

Милли яшәеш кыйммәтләре сагында торган әдипнең глобализация, урбанизация шартларында татар авылын саклау, димәк, милли үзенчәлекләрне билгеләгән әхлакны, гореф-гадәтләрне бер буыннан икенчесенә җиткерү турында тирән борчылулары “Нигез туздыручылар” драмасында чагылыш таба. Татар әдәбиятында йорт нигезе һәрвакыт изгелек, гаилә, нәсел җирлеге символы буларак сурәтләнә. Шуңа мөнәсәбәттә катнашучылар арасында җитди конфликт барлыкка килә. Бер якта, борынгы осталар тарафыннан салынган йортка бәйле әхлакый һәм милли кыйммәтләрне саклау ягына басучылар торса, икенче якта, күп бүлмәле квартира алу өчен теләсә кемне таптап үтәргә, һәртөр түбәнлеккә төшәргә әзер бәндәләр тора. Каршы якларның туганлык мөнәсәбәтен ачып, автор конфликтның тагын да тирәнәюенә ирешә.

Хөкүмәт исеме белән халыкны алдалап йөрүчеләр милләтнең яшәү рәвешенә, буыннан буынга күчерелергә тиешле язылмаган кануннарына каршы чыгучылар буларак бирелә. Белорус карты Харитон әйткәнчә, “Ятлар туздырганда бер хәл... Үзеңнекеләр туздырганда, бу инде чыннан да куркыныч”. Соңгы вакытта милли басмаларда милләтнең исән калуы яисә юкка чыгуы аның үзеннән генә тора, дигән фикер еш очрый. Ю.Сафиуллин әлеге җитди мәсьәләне күп еллар алдан тойган, аңлаган һәм шул турында укучы-тамашачыны кисәткән. Ахырда Мәрьямбану әбинең үлеме белән тагын да көчәйгән сызлану хисе җитди уйлануга, нәтиҗәләр ясауга китерә.

Драматургның мәхәббәт, гаилә мөнәсәбәтләрен төрле буыннар бәйләнеше, милли яшәеш үзенчәлекләре белән бәйләп сурәтләгән пьесаларының берсе – “Пар канат”. Үткән гасырның сиксәненче еллары уртасында башланып киткән үзгәрешләр йогынтысында язылган пьесада җәмгыятьнең гаять актуаль мәсьәләләре чагылыш таба. Драматургиядәге яңа эзләнүләр билгесе буларак, автор төрле жанр сыйфатларын синтезына, бертөрле генә бәяләп булмый торган геройларга мөрәҗәгать итә: авыл ташландык хәлдә, ул бетеп бара, һәркайда эчүчелек киң җәелгән, никахсыз бала табу да гадәти күренешкә әйләнеп бара. Институт тәмамлап кайткан яшь белгеч Рафис, тиздән баласы туарга тиешлеген белгән хәлдә, “Миңа башка юл калмады. Бөкрене кабер генә төзәтә”, – дип, упкынга сикерә. Бу күренеш яшәп килгән системага протест, аны кире кагу булып яңгырый. Пьесада бер генә дә бәхетле, үз тормышыннан канәгать булган кеше юк. Туганнар да, бер-берсен яратам диюче яшьләр дә уртак тел таба алмыйча интегә. Гомумән, сызлану фәлсәфәсенә, модернистик алымнарга нигезләнгән әсәр Ю.Сафиуллин иҗатында яңа бер этап башлануын белдерә. Шул эзләнүләрнең дәвамы буларак “Идегәй” трагедиясе языла.

Драматургның иҗат биеклеген билгеләгән әсәрләрнең берсе булган “Идегәй” татарлар арасында күпләп таралган халык дастанына, аның Н.Исәнбәт тарафыннан тупланып, бөтенлекле хәлгә китерелгән текстына нигезләнә. Автор пьесаны язуга җитди әзерлек белән килә. Драматургия һәм татар театры тарихын яхшы белүе, тарихи эчтәлекле спектакльләрдә уйнавы да моңа таяныч була. Аның әдәби әсәрләргә нигезләнгән инсценировкалар язу тәҗрибәсе дә бар. Ш.Бикчурин әсәре буенча “Каты токым” (1971), Ә.Еникигә нигезләнгән “Гөләндәм туташ хатирәсе” (1975) үз вакытында уңай бәя ала. “Идегәй” тарихи трагедиясе 1994 елда Камал театры сәхнәсендә куела һәм театр белгечләре, киң җәмәгатьчелек тарафыннан югары бәя ала. Спектакльнең Россия шәһәрләренә гастрольләр вакытында кат-кат уйналуы да шуның бер чагылышы. Ю.Сафиуллин заман рухына туры килә торган һәм милли эчтәлек белән сугарылган пьеса иҗат итә. XIV– XV гасырларда булган вакыйгаларга яңача карап, Алтын Урдадагы хәл-күренешләрне, ил башлыкларының эш-гамәлләрен тарих һәм заман биеклегеннән торып бәяләү омтылышы ясый. Тарихилыкны шартлылык алымнары белән үреп барып, әдип күп вакыйгалы, киң яңгырашлы, төрлечә укылышлы трагедияне мәйданга чыгара. Фаҗигалелек пафосы иңләп үткән әсәрдә ил-халык һәм шәхси мәнфәгать мәсьәләсе алгы планда тора, төп конфликт та шуның белән бәйле булып, аны мәхәббәт һәм нәфрәт, тугрылык һәм хыянәт, яхшылык һәм явызлык, ата һәм ул каршылыклары тагын да көчәйтә, тулыландыра. Ә инде төп геройлар буларак бирелгән Идегәй һәм Туктамыш тартышында мәсьәлә бөтен каршылыгында һәм фаҗигесендә ачылып, шул чорны тирәнрәк ачу-аңлату белән бергә, аның һәр заманга хас булуын тоемларга, нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирә. Трагедиядә вакыйгалар төп геройларның үлеме, илнең таркалуы белән тәмамлана. Моның сәбәпләре турында уйланып, драматург 195 яшьлек аксакал Субра карттан мондый сүзләр әйттерә: “Алдыйм дип алданмагыз! / Батырлар да башын сала, / Ялган дәүләтне дә ала, / Ялганга ялганмагыз!” Һәркемгә аталган әлеге юллар тарихтан сабак, гыйбрәт алырга, милләт язмышы өчен җаваплылык тоеп яшәргә чакыра.

Ю.Сафиуллин трагедия жанрына бәйле эзләнүләрен дәвам итеп, үз чорының фаҗигаләрен сурәтләүгә килә. Чечен сугышының татарлар яшәгән төбәккә килеп, канлы тән һәм җан ярасы буларак дәвам итүен “Йөзек һәм хәнҗәр” (1996) фаҗигасендә чагылдыра. Әсәр трагедия жанрының аерым сыйфатларын билгеләргә дә ярдәм итә. Классик трагедиягә хас принциплар сакланып бетмәсә дә (каршы якларның үлеме котылгысыз булу), аерым кеше язмышларының җәмгыятьтәге каршылыклар белән бәрелеше дә гаять җитди фаҗигаләргә китерүе ачыла. Ә инде аның сәбәпләренә бәйле сурәтләрдә кешелек кыйммәтләре яклана. Бу очракта сугышка һәм аны башлаучыларга нәфрәт пьесаның төп идеясе буларак яңгыраш ала. Трагедия драматургиядә аерым традицияләр яңаруы һәм баетылуы белән дә игътибарга лаек. Автор тарафыннан уңышлы кулланылган Йөзек һәм Хәнҗәр образ-символ дәрәҗәсенә күтәрелә. Төп вакыйгалар тынычлык символы булган Йөзекне эзләү фонында бара. Аның тиз генә табылмавы чечен җиреннән кайткан канлы Хәнҗәрнең ике кеше гомерен алуына китерә. Йосыф исемле малайның Йөзекне табуы да символик мәгънәгә ия – яшь буын сугышны кире кагып, тыныч тормыш, мәхәббәт символын сайлый.

Драматургның классик әсәрләргә инсценировкалар аша яңа сулыш өрү, аларны яшь буынга сәхнә теле аша җиткерү омтылышы буларак, М.Галәү романнары буенча “Ирдәүкә” (1996), Г.Исхакый әсәрен өйрәнеп “Зөләйха” (2000) киносценариесе, Кол Гали әсәренә нигезләнгән “Йосыф һәм Зөләйха” музыкаль риваяте һәм атаклы мәгърифәтче шагыйрьнең тормышына, әсәрләренә бәйле “Акмулла” драмасы языла. Ю.Сафиуллин татар халкының фаҗигаләр белән тулы тарихының төрле чорларына мөрәҗәгать итә. Иң авыр вакытларда милләт сагына баскан татар хатын-кызына мәдхия укый. Татар хатынының иман ныклыгына, рухи көченә сокланып иҗат ителгән әсәрләр бүгенгебезгә аваздаш булуы белән дә киң яңгыраш ала. “Йосыф-Зөләйха”да татар әдәбиятының башлангычында торган әсәрнең әдәби-эстетик һәм дини-фәлсәфи эчтәлеге заманча алым-чаралар ярдәмендә укучы-тамашачыга җиткерелә. Идеаллаштырылган Йосыф образының көче иманлы булуда һәм Аллаһыны, туганнарын, барча адәмне яратуда, изгелек эшләүдән күңел шатлыгы, рухи канәгатьлек кичерүендә булуы ачыла. Соңгы инсценировкада мәгърифәтче шагыйрьнең фаҗигаләр белән тулы тормыш һәм иҗат юлы сурәтләнә. Татар, башкорт һәм казах халыкларының уртак әдибе булган Акмулланы автор үз язмышын халык язмышы белән бәйләгән олы гуманист, аң-белем таратып, халыкның киләчәген кайгыртып яшәүче әдип, сүз остасы – чичән рухлы кыю шәхес итеп ача.

Ю.Сафиуллин иҗатының гаять бай һәм мөһим тармагы театр тарихы, аның атаклы шәхесләре белән бәйле. Студент елларында ук театр тарихы белән кызыксына башлау, аны бу өлкә белән фәнни нигездә кызыксынуга китерә. Вакытсыз арабыздан киткән танылган режиссёр Дамир Сираҗиев тормышын һәм эшчәнлеген чагылдырган “Чәчәкләр һәм күз яшьләре” (1999) һәм “Шәхесләребез” сериясендә чыккан “Дамир Сираҗиев” (2009) китапларында әлеге шәхеснең мөләем образы, кабатланмас таланты ачыла. Истәлек-язмалар, спектакльләргә бәяләмәләр аша Ю.Сафиуллин Д.Сираҗиевның иҗади табышларын, театр сәнгатенә алып килгән яңалыгын, эзләнүләр юнәлешен эчкерсез бер җылылык, ярату, тирән хөрмәт белән укучыга тәкъдим итә. Ә инде “Рәфкать Бикчәнтәев” (2006, 2018) җыентыгы атаклы режиссёр эшчәнлеге аша үткән гасырның 50-60 елларындагы татар театрының гыйбрәтле сәхифәләрен күз алдына бастыра. Китапта Р.Бикчәнтәев татар театрына яңа сулыш өргән, заманча спектакльләре белән тамашачыны театр залларына кайтарган талантлы, эзләнүчән режиссёр буларак ачыла. Күпсанлы истәлекләр аның эш стилен, артистлар белән мөнәсәбәтен аңлау, аерым спектакльләрнең сәхнә тарихын һәм кыйммәтен чорның мәдәни тормышы белән тыгыз бәйләнештә бәяләү мөмкинлеге бирә.

Ю.Сафиуллин тарафыннан җыелып, редакцияләнеп чыгарылган “Газиз Айдарский” (2011) җыентыгы безне XX гасырның 20-30 елларына алып китә.

Театрга җаны-тәне белән бирелгән Газиз Айдарский (Сара Садыйкованың ире) талантлы шәхес буларак ачыла. Татарның талантлы артистлары Ринат Таҗетдинов (“Ринат Таҗетдинов”, 2011) һәм Айдар Хафизов (“Эзләп тапкан бәхет”, 2020) турындагы китапларда Ю.Сафиуллинның йөрәк җылысы урын алган. “Милләтнең алтын баганасы булган театр” аша тамашачы күңелендә әдәп-әхлак һәм эстетик зәвык формалаштыручы, милли үзаңның баетучы остаз-артистларның гаҗәеп матур сәнгати образларын күз алдына бастыруга ирешә төзүче-автор. Ю.Сафиуллин күп материалларны Казан, Мәскәү, Әстерхан, Уфа архивларыннан эзләп таба, замандашларының истәлекләрен бөртекләп җыя, театр музейларыннан ала. Шуңа да әлеге хезмәтләр, татар театры тарихының аерым сәхифәләрен торгызып, бөек шәхесләребезгә рухи һәйкәл төсен ала. Татар театрының күренекле шәхесләре Г.Айдарский, Р.Бикчәнтәев, М.Сәлимҗанов, Р.Шәрәфиев, А.Хафизов, Д.Нурлы, Н.Дунаев, Ф.Мәмәш, Ә.Хисмәтов һ.б. турындагы вакытлы матбугатта (“Казан утлары”, “Идел”, “Ватаным Татарстан”, “Мәдәни җомга”, “Шәһри Казан”) басылган мәкаләләре тирән эчтәлеге, фактик байлыгы, шәхесләрнең төрле яклап ачылуы белән аерылып тора. Автор фәнни һәм публицистик стильне уңышлы үреп, татар театрының аерым сәхифәләрен барлый, үткән белән бүгенгенең тыгыз бәйләнешен, традицияләр дәвамчанлыгын ачуга ирешә.

Әлфәт ЗАКИРҖАНОВ.

Атнаның сәяси мизгелләре

ФАКТЛАР ТЕЛЕ ШӘРЕХСЕЗ ДӘ АҢЛАШЫЛА

БМО Генераль Ассамблеясе хәрби хәрәкәтләр барган 4 төбәктә үткәрелгән референдумнарны танымау турында, Россияне гаепләгән резолюцияне кабул иткән (элегрәк ул, Россия БМО КШ утырышында вето хокукын куллану сәбәпле, анда кире кагылган иде). Оешмада әгъза булып торган 193 илдән әлеге документны хуплап 143е тавыш биргән, 35 ил (алар рәтендә Кытай, Һиндстан, Казахстан һәм Әрмәнстан да бар) тавыш бирүдән тыелып калган, ә 5 ил (Беларусь, Никарагуа, Сүрия, Төньяк Корея һәм Россия) каршы тавыш биргән. Икенче көнне (13 октябрьдә) Европа Шурасы Парламент ассамблеясе (ПАСЕ) инде Россиянең сәяси партияләрен дә террорчылыкка ярдәм күрсәтүдә гаепләгән резолюция проектын бертавыштан кабул иткән. Хактыр ки, дөнья җәмәгатьчелегенең бүгенге хәтәр хәлләргә мөнәсәбәте әлеге фактлардан инде бернинди шәрехләүләрсез дә аңлашыла.

Узган атнада Астанада (Казахстан) БДБ илләре катнашында рәттән өч очрашу үтте: Азиядә бергәләп эш итү һәм ышаныч чаралары буенча киңәшмә; БДБ илләре башлыклары шурасы утырышы; шулай ук, «Россия – Үзәк Азия» форматындагы очрашу. Әлеге чараларда Россия Президенты В.Путин үзе катнашты һәм андагы мәйданчыкны сәяси белдерүләр ясау, шулай ук ике яклы сөйләшүләр үткәрү өчен кулланды. Әлбәттә, геосәяси яктан Мәскәүнең БДБ илләрен туплау нияте яхшы аңлашыла. Тик фактлар теле монда да үзсүзле булып кала. Астанада үткән чараларның соңгысында уртак фикерне Таҗикстан лидеры Э.Рахмон белдергән: Мәскәүне ул Үзәк Азия илләренә карата сәясәтне элеккеге СССРдагы кебек итеп кормаска чакырган.

Башка вакыйгалардан игътибарны Россия кораллы көчләренең Украинадагы мөһим (энергетика һ.б.) объектларны атна дәвамында диярлек югары төгәллекле корал утына тотуы, Киевнең дә Россиягә (аның чиктәш өлкәләренә) шуның белән үк җавап кайтаруы җәлеп итә. Һөҗүм утына кайчакта көнкүреш объектлары, торак йортлар һ.б. эләгүе дә мәгълүм. Хәтәр хәбәрләрдән инде бу атнада Литвада НАТО илләре катнашында башланган «Тимер бүре 2022-II» дигән хәрби өйрәнүләрне, шулай ук НАТО илләре хәрби-һава көчләренең атом-төш коралын тыеп калу буенча һәр елны үткәрә торган Steadfast Noon («Тотрыклы көн уртасы») дигән өйрәнүләрен китерергә була. Соңгысында катнашу өчен АКШ Европага хәтта үзенең B-52H стратегик бомбардировщиклары төркемен дә китергән. Әлбәттә, бүгенге хәтәр хәлләр тудырган фаҗигале вакыйгалар турында да әйтмичә булмый. Узган шимбәдә Белгород өлкәсендәге хәрби полигонда әзерлек узучы «ирекле»ләр арасында килеп чыккан низаг таҗик милләтеннән булган 3 хәрбинең башкаларга ут ачуына китергән. Ә бу атнада Краснодар краенда Су-34 бомбардировщигының, аэродромнан күтәрелгәндә ут кабып, Ейск каласындагы күп катлы йортка килеп төшүе 15 кешенең үлеменә һәм 43 кешенең зыян күрүенә китергән.

Фоат УРАЗАЙ.

Ирекнең дә

Соңгы ярты ел эчендә Башкортстанда танылган драматург Наил Гәетбайның байтак пьесаларының премьерасы зур уңыш белән үтте. Яшьләр театрында “Гашыйклар көне” комедиясе куелды, Сибай театрында ике драмасы күрсәтелде: “Урал бөркете” һәм “Тау артында ниләр бар?”. Стәрлетамакта – “Ничек кияүгә чыгарга?” комедиясе һәм Уфаның “Нур” театрында – “Ирекнең дә чиге бар” драмасы.

“Нур” татар театры куйган спектакль темасы бүген күпләрне борчый. “Ирекнең дә чиге бар” драмасында вакыйгалар урындагы газетада республикада гына түгел, бөтен Рәсәйдә алдынгылар рәтендә йөргән заводның директорын фаш итүче мәкалә бастырудан башлана. Моңа кадәр өлге булган җитәкчене аның кул астында эшләүчеләрне чамасыз кысуда, хәтта тупаслыкта, хөкүмәт кесәсенә кул тыгуда гаеплиләр. Билгесез журналистның мәкаләсе максатына ирешә. Завод җыелышы директорны урыныннан алырга, яңа директор сайларга хәл итә. Ягъни, үткән гасырның туксанынчы елларында тезгеннән ычкынган демократия, үзгәртеп кору, йөгәнсез ирек үз эшен эшли. Бу үзгәрешләрнең мәкерлелеге, алдан уйлап оештырылган булуы әсәрнең финалында гына ачыклана.

Киң катлам тамашачы Наил Гаетбайны күбрәк комедия остасы дип белә. Аның дистәләгән тамашалары Башкортстанның һәм күрше республика, өлкә театрларының сәхнәсендә бара. Аның комедияләре бик үзенчәлекле. Күптән түгел бер таныш хатын (югары белемле филолог) Н.Гаетбайның комедияләр җыентыгын укырга алды да, бер атнадан китерде. “Шушы комедияләрне укыганда күз яшьләре түктем. Бу әсәрләрдә көлкеле урыны күп, әмма алар һич тә комедия түгел, ә чын мәгънәсендә драма, алар кешеләрнең трагедиясе хакында, котыла алмаслык, җинеп чыкмаслык авыр хәлгә эләккәннәр турында”.

Наил Гаетбай үзенең яңа әсәрендә җитди темага тотынган. Бүгенге тормыш хакында, СССР таркалганнан соң кая килеп терәлүебез турында үз уйлары, борчулары белән бүлешә. Яхшымы, әллә начармы ул безгә демократия биргән тормыш? Ирек – нәрсә? Ул йөгәнсез булырга тиешме? Хәзер адәм баласы ничек теләсә, шулай кылана аламы? Әллә аның чиге бармы? Киңрәк караганда, безнең ил белән ни булды, ни өчен бүгенгәчә кая таба баруыбыз, киләчәкгә нинди җәмгыять төзергә теләвебез һаман да билгесез.

Шушы сорауларга драматург белән режиссер Илдар Вәлиев “Нур” татар театры артистлары белән бергәләп җавап эзли һәм тамашачыны уйланырга мәҗбүр итә.

Илебездә башланган үзгәртеп кору төрле кешеләрне алгы планга этеп чыгарды, аларның бөтенесе дә уңай шәхесләр булып чыкмады, киресенчә, күбесе нигезсез кычкырырга, тамак ярырга һәвәс адәмнәрдән иде. Шундый хәлдә заводны ил буенча алдынгылар рәтенә чыгарган директорны яклап алып калу өчен җыелышка килгән министр, кала җитәкчеләре бугаз ертучыларга каршы тора алмый. Ялкаулар, эчкечеләр, директор тарафыннан күп тапкыр тиешле җәзасын алганнар өстенлек ала. Сәләхне эшеннән бушаталар.

Авторның ни өчен директорны эшеннән куылган хәлдә күрсәтүе хакында тамашачыга уйланырга мөмкинчелек күп булачак, чөнки спектакль шушы вакыйганы тикшерү рәвешендә корылган. Сәхнә кануннары буенча персонажлар күренми, әмма алар илдә барган үзгәрешләрнең чагылышы булып тора, ул вакыйгаларны геройларның сүзләре аша беләбез. Ни өчен директорны пычракка буяган, ахырда вазифасыннан алып ташлауга җиткергән мәкалә басылып чыккан? Киңрәк алсак, нинди сәбәпләр аркасында илебез шундый хәлгә калды? Бу сорауларга җавап эзләү спектакльнең төп сюжет сызыгын тәшкил итә.

Вакыйгалар чылбыры завод директоры Сәләх белән кала башлыгы урынбасары, эшкуар Хәкимәне алгы планга чыгара. Вакыйгалар үсешенә башка персонажларның холыкларына шушы икәү төп сәбәпче булып тора. Ситуацияләрне бу төп геройларга бәйләү, әсәрне үзенчәлекле итеп корырга мөмкинлек бирә. Драматург Н.Гаетбай үзенең комедияләрен нигездә лирика һәм юмор теле белән иҗат итсә, яңа проблемалар һәм геройлар авторны күбрәк публицистика стиленә мөрәҗәгать итүгә этәргән. Элеккеге директор Сәләхнең теле публицистик пафос белән сугарылган, аның кискен ситуацияләргә, илебез тарихына мөнәсәбәте һәм фикере тамашасы өчен аңлаешлы. Тамашачы автор һәм Сәләх белән дә килешә, шуңа да спектакль бер тында карала, адым саен бүгенге көн проблемаларына кагылган репликалар алкышлар белән озатыла.

Сәләхнең карашы авторның фикере кебек кабул ителә, ягъни төп герой язучының рупоры ролен үти. Әмма Сәләхнең кешеләрне, нигездә, ике төркемгә бүлеп каравы дөресме? Берәүләр тумыштан җитәкче булу өчен дөньяга килә, ди Сәләх, ә икенчеләре – буйсыну өчен яратыла. Тәүгеләр бар халыкның 5-6 процентын гына тәшкил итсә, 95 процент кешеләр түрә-кара кушканны

●Наил Гаетбай.

үтәү өчен туа. Ягъни аларның үзләреннән бер кайчан да олы җитәкче килеп чыкмый. Димәк, бичәсен тыңлата алмаган, аның сүзеннән чыкмаган адәм, бик әйбәт кеше булса да, җитәкче булып китә алмый, ди Сәләх. Хәкимәнең үзе басып алган, йомшак холыклы ирен завод директоры итеп куюына каршы чыгып. Пьесада шундый урыннар күп һәм шулар әсәрнең актуальлеген, публицистикага тартым икәнлеген күрсәтә.

Г.В. Плеханов әйткән сүзләр исә төшә: “Публицистиканың әдәбиятнең эченә ерып кереп, аның төп көченә әверелгән заманалар була”. 1950 елларда “авыл прозасы” дигән юнәлеш җәмгыятьне дә, ил җитәкчеләрен дә сугыштан соң бөлгенлеккә төшкән колхозларга йөз белән борылырга мәҗбүр итүен искә алыйк. Ә 80-90-нчы елларда илебездә җитәкчеләр арасында туган-тумачалык, ясалмалык, ялган саннар белән күз буяулар чәчкә атканда әдәбиятебез шушы күренешләрне фаш итүне алгы планга чыгарды: И.Дворецкийның “Читтән килгән кеше”сен, А.Гельманның “Премия”сен, А.Абдуллинның “Унөченче председателе”н.

Наил Гаетбай комедияләре белән тормыш-көнкүрешнең кире якларыннан тамашачыны күз яшьләре аша көлдереп алгач, ул заманаңның җитди проблемаларын тикшерүгә тотынган һәм шундый сорауга җавап эзли: ни өчен төрле яктан күккә күтәрелгән демократия илебезне ошбу хәлгә төшерде?

Уңайлыктан файдаланып җитәкчелек ролен халыктан үз кулларына алырга омтылган кире көчләрнең вәкиле рәвешендә без кала хакимияте башлыгы урынбасары Хәкимәне күрәбез. Демократия сылтавы белән, илебезне таркатучы, аның яңа хуҗасы булу өчен бар көчен салган җимерүче кара кодрәт – ул Хәкимә. Заманга кулайлашкан төрле лозунглар белән файдаланып, ул үзенең планнарын тормышка ашырырга ашкына. Моның өчен иң алда – әлеге җитәкчене директорлыктан алып ташлап, аның урынына үз кешесен – ире Бәхтине утыртыру! Шул максат белән заводны алдынгылар рәтенә күтәрүенә карамыйча, Сәләхне карага буярга кирәк, ягъни, чынбарлыкны кире якка борып җибәрү мотлак. Сәләх эш дип янып яши – димәк “бюрократ”, һәр хезмәткәрнең бурычын җиренә җиткереп үтәүне таләп итә – “халыкны кыса”, акча буленмәсә дә, җаен табып тикшерүче комиссияләрне сыйлый – “казна акчасын үз кесәсенә сала”, эчкечеләргә, ялкауларга җәза бирә – “демократиягә каршы”.

Ә Хәкимә нинди ысуллар куллана? Иң әүвәл газетаны файдаланып директор хакында ялган фикер тудыра. Демократларның төп көче саналган, тамак ярырга яраткан ялкауларны алга чыгара. Халык белән властьның бердәмлеген күрсәтү өчен хакимият һәм министрлык вәкилләрен эшкә җәлеп итә. Шулай итеп Хәкимә “демократик оппозиция” оештыра. Аларга таянып, “демократик ысул белән”

чиге бар



директорлыкка кандидатлар исемлегеннән Сәләхне сыздырып ташлый: чөнки аны кабат сайлап куюлары бар, ә бу Хәкимәнең бар ниятен юкка чыгара.

Бер интервьюсында Н.Гаетбай әдәби әсәрдә, бигрәк тә драматургиядә перонажның әйткән сүзләре чын уйлары һәм холыклары белән һәрчак туры килми, дигән иде. Чынлап та язучылар үз иҗатында еш кына бу ысулны куллана, ягъни персонаж бер нәрсә әйтә, икенче төрле уйлый, ә өченче төрле эшли.

Бу сүзләр тулысынча Хәкимәгә туры килә. Ул Рушанның әйткәнен тыңламыйча, укуын ташлап бизнеска тотынганын белгәч, һәр яшь кешенең армиягә барып үз илен сакларга тиешлеге хакында фикер йөртә башлый. Шул ук вакытта Хәкимә үзе Рушанны армиядән алып калырга тырыша, ә СССРны һәрчак кире яктан сурәтли иде. Ярдәм итүдән туктау белән янап, армиягә озату белән куркытып, Рушанны Хәкимә үзенчә яшәтергә омтыла. Директор булудан баш тарткан ирен, усаллык, көч белән күндерә алмавын тойгач, "ә" дигәнче йомшара, җылы сүз, хәйлә белән Бәхтине үз ихтыярына буйсындырырга, аны яңа, демократик планнарын тормышка ашыру өчен файдаланырга өметләнә.

Сәләх Хәкимәнең һәр адымын тәнкыйтьләп, аларның "демократия" дигән төшенчәгә якын да килмәвен, шул исем астында яшерен кара эшләр башкаруын фаш итә.

Автор "демократия" сүзен төрле интонация белән кабатлатып – аның артына яшеренгән кире сыйфатларны мыскыл итеп, хурлап, юкка чыгарып, спектакльне зур игътибар белән караган тамашачының аңына әсәрнең төп идеясен сеңдерә. Әйтерсең лә, Сәләх ачык дәрес үткәрә – ул тамашачыга ничек итеп уңышлы эшләп килгән заводны "демократия" дигән чаршау артында юкка чыгаруларын фаш итә, шундый заводлар белән бергә тоташ илнең ничек таркалуын күрсәтә. Хәкимә кебекләрнең "демократия" дигән исем астына яшереп, ил байлыкларын үз кулына төшерү өчен төрле акцияләр үткәрелүен әйтә. Хәкимә һәм аның кебекләрнең үз кесәләрен калынайту осталыгын күрсәтеп, бөтен ысуллар белән баерга теләү инстинктының нинди куркыныч көчкә ия икәнлеген ачып сала автор.

Спектакльдә шундый көчләрнең бер генә вәкиле хәрәкәт итә – Хәкимә. Ләкин ул мәкерле, хәйләкәр, энергиясе ташып тора. Ирексездән М.Горькийның Васса Железновасын хәтерләтә. Ул үз максатына ирешү өчен ирен агулауга, улын корбан итүгә, киленен илдән кууга барып җитә.

Кала-авылларда, бөтен илдә "демократия" исеме астындагы аферлар ярдәмендә завод, колхоз-совхозларны талауның, илне юкка чыгаруның ничек эшләнгәнен күрсәтеп, Н.Гаетбай билгеле "прихватизатор"ларның берсенең дә исемен атамый. Чөнки иң мөһиме ниләр урланылу, кемнәрнең урлавы түгел, ә бу бәлане барлыкка китергән "демократия" дигән күренеш тә бит. Ничек килеп чыкты ул? Нигә аңа каршы тора алмадык без?

Сәләх тә илебезне таркатучыларның барысына бер атама бирә: "Илне талаучы бүреләр!" Ә аларның кушканын үтәүчеләрне, шул исәптән үзе урынына директор булырга теләүчеләрне ул бер сүз белән атый: "Чүпрәк!"

Сәләх үзенең директорлыктан китүе өчен борчылмый, завод белән шул "чүпрәкләр" җитәкчелек итә башлаячакларына, аны юкка чыгарачакларына кайгыра.

Сәләх фикеренчә, бизнеста да кешеләр аны оештыруга сәләтлеләр һәм кушылганны эшләүчеләргә бүленә. Бу бүлүне кемнәрнедер кимсетү дип кабул итәргә ярамый. Әйбәт кеше – профессия була алмый, ул шәхеснең бер сыйфаты гына. Яхшы кеше булып та, әгәр директорлыкка яки бизнесменга кирәкле сыйфатларың юк икән, көчле, уңышлы җитәкче дәрәҗәсенә ирешү мөмкин түгел. Сәләхнең спектакль барышында төрле урында әйтелгән фикерләреннән, директор булу өчен нинди сыйфатлар кирәклеген белергә мөмкин.

Беренчедән, югары белем. Билл Гейтс кебек генийлар гына бернинди белемсез дә бизнеста уңышка ирешә ала. Ә ярлы кешегә карьера ясау өчен, бигрәк тә бизнеска тотынса, белемнең булуы мәҗбүри. Икенчедән, производствоның иң түбән баскычыннан башлау ярлы эшчедән бригадир, мастер кебек вазифаларны үтәргә, йөзәр тапкыр тукмалырга, чыныгырга кирәк. Тагын тәҗрибә тупларга, өлкәннәрдән өйрәнергә һәм характерың көчле булырга тиеш, бигрәк тә түрә-карадан курыкмаска бурычлысың. Нахаллык артып торсын синдә, хак икәнеңне белсәң, үз сүзеңдә нык тор. Эшеңдә максатка ирешү өчен бернигә карамыйча алга омтыл. Һәм иң мөһиме – коллективың тикшерү белән килгән комиссия, ревизия әгъзалары белән уртак тел таба бел.

Сәләхнең бөтен спектакльгә сибелгән бу фикерләре гаҗәпләнерлек түгел, алар һәркемгә билгеле. Фәкать җәмгыятьтә кешене эше өчен бәяләү онытыла төшсә, адәм баласын икенче сыйфатлары өчен – хәбәр йөртү, әшнәлек, хәйләләшү, юхалану, тәлинкә тоту – өскә чыкса гына, бу фикерләр мөһимгә әверелә.

Сәләхнең ни өчен заводны юкка чыгаручыларның мәкерен алдан сизмәде икән, дип гаҗәпләнергә мөмкин, әмма без бит үзебез дә – миллионлаган Рәсәй халкы – капылт баеп китү өчен ваучерлар сатып алырга, завод-фабрикаларга, колхоз-совхозларга хуҗа булырга өметләнеп, "демократия", "ирек" кебек елтыр сүзләргә ышанып, ярык тагарак алдында торып калдык, чәчкә аткан илебезне югалттык. Гадел, әмма беркатлы Сәләх тә безнең беребез инде. Юкка гына автор, режиссер, алар белән бергә Сәләх образын башкаручы артистлар һаман саен: нәрсә ул ирек? Кайда аның чиге, кайсы урынны үтеп китсәң, сине төзүчедән җимерүчегә әйләнү көтә? Төрле митингларда халык исеменнән тамак яручылар хаклымы? "Демократик" сайлаулар вакытында бер ярты аракыга, әчмуха чәйгә, срогы чыккан даруларга сатылырга әзер сайлаучылар ирекләре?

Күргебезчә, әхлакый традицияләребезне, хезмәт кешесенә һәм илебезнең үткәненә, үз-үзебезгә хөрмәт итүне тергезү өчен Сәләхне, үзенең рухташлары белән алда авыр көрәш көтә. Чөнки Хәкимә кебекләр демократ битлеге артына яшеренеп яулаган позицияләрен җиңел генә бирергә җыенмый. Әсәрнең финалы ачык көе кала: кем җиңүче булыр, һәм нинди киләчәк көтә безне? Спектакль шул хакта.

Рәиф ӘМИРОВ.

Айга кырын карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

22 октябрь (шимбә). ***Рабигул әүвәл аеның 26 нчы көне. 27 нче Ай тәүлеге. Ай Кыз йолдызлыгында, 1.59 сәгатьтә калка, 15.58 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 9.58 сәгать.***

Бу көннәрдә организм хәлсез, шунлыктан күбрәк йоклау файдалы. Нерв системасы, сизү әгъзалары зәгыйфь. Кан һәм лимфа авырулары кискенләшергә мөмкин. Кан басымын контрольдә тоту сорала.

Томаудан 1 көндә котылу

Кәстрүл яки термоска 1 валидол төймәсе (яки 1 чәй кашыгы сода һәм вак туралган 1 бүлем сарымсак) салып, өстенә кайнар су агызалар, болгаталар һәм зур сөлгегә уралып шул парны сулыйлар. Мондый ингаляцияне берничә минут кына ясасаң да, икенче көнне борын сулый башлый, томау үтә.

23 октябрь (якшәмбе). ***Рабигул әүвәл аеның 27 нче көне. 28 нче Ай тәүлеге. Ай Үлчәү йолдызлыгында, 3.21 сәгатьтә калка, 16.05 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 9.54 сәгать.***

Айның иң яхшы көннәреннән берсе. Энергетикасы бик уңай. Көтелмәгән очрашулар берсеннән-берсе кызыклырак булачак. Хисләр тернәкләнә, аралашу теләге уяна. Сизү әгъзалары, аеруча күзләр зәгыйфь. Кан басымын контрольдә тоту зарур. Яңа Ай туарга ике генә көн калып бара, караңгы, Айсыз төннәр күңелгә шом сала. Организмны чистарту, ач тору уңай нәтиҗә бирә.

Сарымсаклы май

Үпкә ялкынсынганда, бронхит яки каты ютәл интектергәндә, болай дәвалану булыша. 5 бүлем сарымсакны изеп, 100 г атланмайга (яки каз маена) кушалар, әйбәтләп болгаталар. Иртән ач карынга 1 чәй кашыгы кабып, артыннан кайнар сөт эчәләр. Кич сарымсаклы майны күкрәк һәм муенга сөртәләр, җылы итеп төренәләр һәм, тагын 1 чәй кашыгы май кабып кайнар сөт эчкәч, юрган астына кереп чумалар.

24 октябрь (дүшәмбе). ***Рабигул әүвәл аеның 28 нче көне. 29 нчы Ай тәүлеге. Ай Үлчәү йолдызлыгында, 4.44 сәгатьтә калка, 16.13 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 9.50 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Бернинди вәгъдәләргә дә ышанырга ярамый. Бизләр системасы, кан тамырлары, эчәклек зәгыйфь. Үзеңне үпкәләткән кешеләрне кичерү зарур.

Шәм – дару

Салкын тиюдән тиз арада менә болай савыгып була. Шәм кабызырга һәм мөмкин кадәр озаграк шуның янында утырырга кирәк. Әледән-әле шәмне борынга якынрак китереп алалар. 2-3 тапкыр шәм янында утыргач ук, томау үтә, күздән яшь агу туктый, тамак авыртуы басыла.

25 октябрь (сишәмбе). ***Рабигул әүвәл аеның 29 нчы көне. 30 нчы, 1 нче Ай тәүлекләре. Ай Чаян йолдызлыгында, 6.10 сәгатьтә калка, 16.21 сәгатьтә***

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга кырын карама

бата. 13 сәгать 48 минуттан яңа Ай. Көн озынлыгы 9.45 сәгать.

Тәүбә итү, гармониягә ирешү көне. Иҗат белән шөгыльләнү, айлык план төзү яхшы. Әйләнә-тирәне дә, үз хисләреңне дә кабул итү кискенләшә, тәэсирләнүчәнлек, интуиция арта. Баш һәм йөрәк зәгыйфь. Арып-талганчы эшләргә, артык кайнар ризык ашарга ярамый. Төрле исләргә аллергия килеп чыгарга мөмкин.

Артыш сихәт бирә

Псориаз, хроник дерматоз интектергәндә, 1,5 стакан артыш җиләген 1,5 литр суда 6-7 минут кайнатып, сөзәләр дә, ваннадагы суга кушып, шунда кереп яталар.

26 октябрь (чәршәмбе). ***Рабигул ахир аеның 1 нче көне. 2 нче Ай тәүлеге. Ай Чаян йолдызлыгында, 7.41 сәгатьтә калка, 16.32 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 9.41 сәгать.***

Яңа туган Ай Җир белән Кояш арасында, үзенең караңгы ягы белән Җиргә караган. Ай идарә итә торган һәрнәрсә – хисләр, кәеф, хәтер, кан басымы зәгыйфь. Кан басымы болай да түбән булган гипотониклар өчен бигрәк тә авыр вакыт. Бу чорда укуда уңышлар, тиз савыгу, югары эшчәнлеккә өметләнергә ярамый. Ашаганда талымлы булу хәерле. Аралашуны чикләү зарур.

Серкәле чөгендер

Кызыл чөгендерне вак угычта кырып, 1 стакан согын сыгалар, шуңа 1 аш кашыгы 9 процентлы серкә кушалар. Ангинадан котылу өчен, шуның белән көненә 5 тапкыр тамакны чайкыйлар.

27 октябрь (пәнҗешәмбе). ***Рабигул ахир аеның 2 нче көне. 3 нче Ай тәүлеге. Ай Укчы йолдызлыгында, 9.16 сәгатьтә калка, 16.48 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 9.37 сәгать.***

Бик актив көн, хәвеф-хәтәр инстинкты, агрессия белән бәйле. Бүген чирләп китү ихтыяр көченең җитәрлек булмавын күрсәтә. Күзне арытмаска кирәк.

Суганлы сөт

1 баш сарымсак, 3 баш суганны вак кына турап, сөткә салып, йомшарганчы пешерәләр, изеп, 2 аш кашыгы бал өстиләр. Һәр 2 сәгать саен 1 әр аш кашыгы эчәләр. Бронхит булганда, каты ютәлләгәндә, мондый чара бик шәп булыша.

28 октябрь (җомга). ***Рабигул ахир аеның 3 нче көне. 4 нче Ай тәүлеге. Ай Укчы йолдызлыгында,10.52 сәгатьтә калка, 17.14 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 9.33 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Теләсә нинди элемтә, танышулар, күмәк эш бүген кыен кичерелә. Озаграк йоклау хәерле. Тәмлерәк һәм күбрәк ашау теләге зур булса да, чаманы югалтмаска кирәк. Ач торырга ярамый.

Кәбестә салаты

2,5 кг кәбестәне турыйлар, 2-3 зур кишерне угычта кыралар, 4 бүлем сарымсакны изәләр. Өстенә кайнар маринад салып 1 тәүлек тоткач, банкларга бүлеп, суыткычта саклыйлар. Маринад: 1 литр суга ярты стакан үсемлек мае, 1 стакан шикәр, 2 аш кашыгы тоз салып, кайнатып чыгаралар, сүндереп, ярты стакан 9 процентлы серкә өстиләр.

Гамәл төрләре

Ислам дине буенча кешеләрнең гамәлләре сигез төргә бүленә: фарыз, ваҗиб, сөннәт, мөстәхәб, мөбах, хәрам, мәкрүһ һәм мөстәкрәһ.

Фарыз – шундый гамәл, аны кылган кеше саваплы, ә кылмаганы гөнаһлы була. Аның фарызлыгына (тиешле булганына) ышанмаган кеше – кяфер (имансыз). Фарыз гамәлләр: ислам диненең хаклыгына ышану, һәр көн биш вакыт намаз уку, рамазан аенда һәркөн ураза тоту, ел саен малның зәкятен бирү һ. б.

Ваҗиб – шундый гамәл, аны кылган кеше саваплы, ә кылмаганы гөнаһлы була. Аның ваҗиблыгына (тиешле булганына) ышанмаган кеше дә гөнаһлы. Ваҗиб гамәлләр: витр намазын уку, гает (ураза һәм корбан бәйрәме) намазларын уку, фитыр сәдакасын бирү, корбан чалу, Коръәннең сәҗдә аятьләренең берсен укыган кешегә дә, ишеткән кешегә дә сәҗдәи тиләвәт кылу һ.б.

Сөннәт гамәлне кылган кеше саваплы була, әмма кылмаганы гөнаһлы саналмаса да, Мөхәммәд галәйһиссәламнең шәфәгатенә (яклавына) лаек булмый. Сөннәт гамәлләр: яхшы эшләрне «Бисмилләһ» белән башлау, Коръән укыр алдыннан «Әгузү» әйтү, төчкергәч «Әлхәмдүлилләһ» дип әйтү, иманлы кешеләргә сәлам бирү, мисвәк (теш чистарткыч) белән авызны пакьләү һ.б.

Мөстәхәб гамәлне кылган кеше савап ала, әмма кылмаганы гөнаһлы булмый, кыямәт көнендә дә аңа шелтә тиеш түгел. Мөстәхәб гамәлләр: нәфел (өстәмә) намазлар уку, нәфел уразалар тоту, нәфел сәдакалар бирү, тәһарәт белән йөрү, буш вакытта Коръән уку һ.б.

Мөбах гамәлне кылган яки кылмаган кеше – саваплы да, гөнаһлы да булмый. Мөбах гамәлләр: хәләл ризыкларны туйганчы ашау яки эчү, утыру, басып тору, зарарсыз сүзләр сөйләү һ.б.

Хәрам гамәлне кылган кеше зур гөнаһлы була, хәрам гамәлләрне эшләргә ярый (хәләл) дигән кеше кяфер санала. Хәрам гамәлләр: кешене яисә хайванны җәберләү, гайбәт сөйләү, урлашу, исерткеч эчемлекләр эчү, зина кылу һ.б.

Мәкруһ гамәлне кылган яки дөрес дигән кеше дә гөнаһлы була. Мәкруһ гамәлләр: отыш уеннар уйнау, әдәпсез җырлар җырлау, кеше алдында әдәпсез кылану һ.б.

Мөстәкрәһ гамәлне кылган кеше гөнаһлы булмаса да, әдәпсезлек кылган санала. Мөстәкрәһ гамәлләр: зур-зур кабып ашау, базарда яисә урамда ашау, авызны капламыйча иснәү, кычкырып кикерү, бармак шартлату һ.б.

Гайбәт сатып йөрмә

Аллаһ Тәгалә Коръәндә «Хуҗурат» сүрәсенең 12 нче аятендә әйтә: «Кеше турында төрлечә фаразлап, начар уйлаудан сакланыгыз һәм бер-берегезне тикшермәгез, кешеләрнең гаебен эзләмәгез, кайберләрегез кайберләрегезне гайбәт кылмасын…».

Гайбәт сөйләүнең гөнаһы Аллаһ каршында бик зур, чөнки ул кешенең исемен пычрата, дәрәҗәсен киметә.

Бервакыт Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһү галәйһи вә сәлләм каты итеп, хәтта пәрдә артында утыра торган хатыннар да ишетерлек итеп хөтбә сөйли һәм ул бу хөтбәдә болай ди: «Әй, телләре белән иман китереп тә, иманнары йөрәкләренә үтеп керә алмаган бәндәләр! Мөэминнәрне кыерсытмагыз, аларның кимчелекләрендә казынып, чокынып ятмагыз! Кем дә кем мөселманнарның кимчелекләрен тикшереп гомерен уздырса, Аллаһ Тәгалә аның үзенең кимчелеген тикшерер. Аллаһы Тәгалә кемнең кимчелеген тикшерсә, ул кешене хурлыкка төшерер һәм үзенең өендә бикләнеп качып ятса да моннан качып котыла алмастыр».

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһү галәйһи вә сәлләм шулай ук: «Башка кешене, ул үзе теләмәгән яктан искә алуың гайбәт була. Әгәр чыннан да аңарда булган сыйфатын искә алсаң, гайбәтен сөйләгән буласың, әгәр булмаган нәрсәне искә алсаң – яла яккан булырсың», – дигән.

Кешедә нәфес дигән әйбер бар. Менә шушы нәфес һәрвакыт үзен генә ярата, үзен генә кайгырта, үзенең проблемаларын гына күрә, башка кешене тыңламый, башка кешенең проблемасы аңа кирәкми дә. Нәфесле кеше беркайчан үз гаебен күрми, аны төзәтү өстендә эшләргә яратмый. Кеше гаебен күрә, кеше гаебен тикшерү белән ләззәт ала. Үзен яхшы, ә башкаларны начар итеп күрсәтүдән рәхәт таба. Андый кеше үзен бөек, даһи, гөнаһсыз фәрештә дип саный. Кеше күзендәге чүпне күрә – ә үз күзендәге бүкәнне күрми.

Коръәндә Аллаһ безгә: «Бер-берегезнең артында гайбәт сөйләмәгез. Әллә сез үлгән кардәшегезнең итен ашар идегезме? Юк, җирәнер идегез!» – дип әйтә. Аллаһ Тәгалә безне гайбәт сөйләүдән менә шушы дәрәҗәдә җирәнергә чакыра.

Сүз йөртүче, гайбәт сатучыга гына түгел, моны тыңлаучыга да шундый ук күләмдә гөнаһ языла. Чөнки аларның берсе теле белән гөнаһка керсә, икенчесе – колагы белән гөнаһ кыла. Без телне генә түгел, колакны да гайбәттән сакларга тиешбез. Чөнки тыңлаучысы булмаса, сөйләүчесе дә булмаячак.

Бервакыт Мөхәммәд салләллаһү галәйһи вә сәлләм каберләр яныннан үзганда, аның дөясе куркуыннан сискәнеп куя һәм ул әйтә: «Бу ике кабердә яткан кешеләр газаптадыр, аларның берсе нәмимә белән шөгыльләнгән», – ди. Нәмимә – ике адәмнең арасын бозу, аларны дошманлаштыру өчен сүз йөртү. Моның өчен кабердә ятканда ук аерым бер җәза, бер газап булыр диелә.

Шулай ук кыямәт көнендә кем кемгә нинди генә зыян салса да, моның өчен түләячәк. Сират күперен кичүдән элек, Аллаһы Тәгалә һәркемгә кемнән нәрсә аласы бар – шуны алдыра, яки кемнең кемгә нәрсә бирәсе бар – шуны бирдерә. Мисал өчен, берәү икенче бер кешенең әйберен урлаган ди. Ә урланган әйберне инде кире кайтарып булмый һәм кыямәт көнне ул кирәкми дә. Димәк, ул аның өчен үзенең кылган изге гамәлләрен бүлеп бирәчәк. Никадәр кыйммәтлерәк әйберен урлаган булса, шуның бәясенә торырлык саваплары зыян күрүчегә күчәчәк. Мәсәлән, кешеләргә зыян салучыдан (монда шул ук сүз йөртү, гайбәт тә керә) – ул кемнәрне рәнҗеткән, кемгә зыян салган булса, барысы аңа килеп аның савапларын алып бетерәчәкләр. Шул рәвешле бу кешенең гамәл дәфтәрендәге изгелекләре бетәр диелә. Ә ул рәнҗеткән кешеләр һаман килә торыр һәм инде бирер өчен яхшылыклары калмагач, ул аларның гөнаһларын үз өстенә ала башлаячак. Һәм муеныннан гөнаһка батырылып җәһәннәмгә керәчәк диелә.

Бу дөньяда яшәгән вакытта әле кемдер судан коры чыгарга мөмкин. Төрле танышлыклары аркылы законнан да, прокурордан да качу юлын табарга мөмкин, әмма Аллаһтан качып булмаячак. Кыямәт көне җәзасыннан качып котылырга мөмкин түгел. Дөньяда кемнәрнең гайбәтен сөйләп йөрсәң, шуларга үзеңнең савапларыңны бүлеп бирәчәксең.

Аллаһ Тәгалә безнең күп гөнаһларыбызны инде болай гына да гафу итә. Ләкин кеше белән кеше арасына гына керми. Кылган начар гамәлләребез кеше хакы белән бәйләнгән икән, алар өчен бәхиллек алу, гафу сорау кирәк. Кеше сүгеп, кешегә начарлык эшләсәң, ә үзең башыңны бәрә-бәрә намаз укысаң да гөнаһысыннан котылып булмый. Инде үлем фәрештәсе якабыздан килеп тотканчы, кешеләр белән araларны төзәтергә ашыгыйк.

Әрвахларга дога кылу тәртибе

«Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

И, Раббым! Үзеңнең ризалыгың өчен укылган ошбу Коръән аятьләрен укудагы хата-кимчелекләребезне гафу итеп, Үзеңнең киң рәхмәтең белән кабул ит. Хасил булган әҗер-савапларын – иң элек барча галәмгә рәхмәт өчен җибәрелгән Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең һәм аның гаиләсенең рух шәрифләренә ирештерсәң иде. Атабыз Адәм белән анабыз Хәваның рух шәрифләренә ирештерсәң иде. Шулай ук, атабыз Адәм галәйһис-сәламнән алып, Мөхәммәд галәйһис-сәламгә кадәр Җир йөзенә килеп киткән барча пәйгамбәрләрнең, габидләрнең, заһидләрнең, остазларыбызның, мөэмин-мөэминә булып үткән барча әти-әни, әби-бабаларыбызның рух шәрифләренә ирештерсәң иде.

Газиз әнкәемнең, газиз әткәемнең, кадерле кайнанам белән кайнатамның рух шәрифләренә ирештерсәң иде. Кадерле кыз туганнарым һәм ир туганнарымның рух шәрифләренә ирештерсәң иде. Өсләребездә хаклары булган, гайбәтләренә төшкән әрвахларның рух шәрифләренә ирештерсәң иде.

Раббым аларның рухларын шат кылып, гөнаһларын ярлыкасаң иде. Әмин.

Раббым, Үзеңнең рәхмәтең белән гөнаһларыбызны ярлыка, дөньяда һәм ахирәттә изге максатларыбызга ирешергә насыйп ит. Раббым, дөньяда яшәгән вакытыбызда бәндәләргә мохтаҗ кылма. Тәннәребезгә сәламәтлек, җаннарыбызга тынычлык бир. Калеб һәм маңгай күзләребезне ач. Башларыбызга зирәк зиһен, үткен фикер, камил гакыл, күркәм холык, йомшак фигыль, тулы иман бир. Дөньяда яшәгәндә гамәл-гыйбадәт, хәер-ихсан белән яшәп, үлем вакытларыбызда ансат үлем бир. Әманәт җаннарыбызны биргәндә, җәннәтеңне күреп, ансат кына тапшырырга насыйп ит.

Кабергә барып кергәндә, рәхмәт фәрештәләрең каршылап, сорау-җавапларыбызны да җиңел бирергә һәм җәннәтләреңә дә керергә насыйп ит.

Раббәнә әтинә фид-д дүнйә хәсәнәтәү-үә фил-әхыйрати хәсәнәтәү-үә кыйнә газәбән-нәр.

Әмин».

Төркиядәге татар генералы

Пензада яшәүче милләттәшебез Фирдәвес Тумеркина (Дашкина) үзенең ерак бабасы Шакир Яваев турында «Шакир паша эзләреннән» («По следам Шакир-паши») дигән китап нәшер итте. Шакир паша – Төркиядә татар милләтеннән булган беренче генерал (Мөхәммәдшакир Мөхәммәдшәриф улы Яваев).

Мөхәммәдшакир Мөхәммәдшәриф улы Яваев 1855 елда Пенза өлкәсе Качкару (русча – Кутеевка) авылында мулла гаиләсендә туа. Унбер яшендә әтисе аны Урта Азиягә мәдрәсәдә укырга җибәрә, соңыннан булачак генерал 1874-1878 елларда Төркиядә укый һәм бирегә яшәп кала. Киләчәктә талантлы гаскәри Госманлы империясе генералы дәрәҗәсенә ирешкән беренче татар генералы булып таныла.

«Шакир паша – әбиемнең бабасы була. Ул 1855 елда туа. Ул 1874 елда Төркиягә укырга китәргә ниятли, әмма әтисе ризалыгын бирми. Шакир теләгенә ирешү өчен, әтисенең ризалыгыннан башка юлга чыгып китәргә ният кыла, шуңа да әтисе белән алар сүзгә киләләр. Әтисенең абруена зарар китермәсен өчен Мөхәммәдшәриф улын искә алып сөйләргә дә тыя», – диде китап авторы.

Фирдәвес Тумеркина китапны язуын Мөхәммәдшәриф имамның сүзеннән чыгу булды дип исәпли. «147 елдан соң мин аның сүзеннән чыктым, шуның өчен, имам мине кичерсен дип, Закир мулла мәчетендә ифтар уздырдым. Шакир паша әтисе Мөхәммәдшәриф үлгәч, туган ягы – авылына кайтырга теләге була. Әмма курка һәм кайтмыйча кала», – диде ул.

1874 елда Шакир паша Төркиягә киткәндә авырлы хатыны аны туктатып калмакчы булган. Әмма Шакир паша китәргә мәҗбүр була. «Яныма килерсез», – дип хатынын ышандыра. Әтисе Мөхәммәдшәриф Шакир пашаның хатынына да, улына да Төркиягә китәргә рөхсәт бирми. «Улымнан ваз кичтем, әмма оныгымны асрармын», – дигән.

«1875 елда Шакир паша киткәннән соң Хәсән бабам туа. Ул үзенең чын әтисен – Шакир пашаны беркайчан да күрмәгән. Хәсән бабам үзенең әтисенең барлыгын белсә дә, аңа Шакир пашаның ни өчен Төркиядә калганын әйтмәгәннәр. Бабай үлгәч, әби аңа барысын да сөйләгән. «Хәсән бабам Ленинград блокадасында үлеп кала», – диде ул.

Төркиягә килгәч, Шакир паша мәчеткә килеп намаз укый башлый. Чын күңелдән намаз кылганына хәйран калган мәчетнең имамы аның кем икәнлеген сораша. Мулла аңа ярдәм итә, үзенең малае дип саный башлый, укырга кирәргә булыша. Шакир паша төрек хәрби-диңгез мәктәбендә укый. Авылы белән һәрвакыт элемтәдә тора, әнисе белән язышa, малае туганын әнисе хат аша язып җибәрә.

Укуы тәмамланмыйча, Шакир паша 1877-1878 елда барган сугышка эләгә. Шәкертләрдән җыелган корабльдә төрле милләт кешеләре була. Шакир җиде тел белгән, шуңа күрә командир янында булган, аның боерыкларын солдатларга аңлатып торган. Сугышта аларның кораблен шартлаталар, судан Төркиянең патруль көймәсе аларны коткара һәм төрмәгә озата. Шакир паша төшләр юрый торган була. Төрмәдәге солдатлар Шакир пашаның белемле булуы турында төрек маршалы Осман пашага җиткерә. Осман пашаның да төшен юрагач, маршал аның белән кызыксына башлый. Шулай итеп, Шакир хезмәтен дәвам итәргә рөхсәт ала. Ул зур полктагы командованиедә булган карар чыгаруда, сөйләшүләр алып баруда, тәрҗемә эшендә ярдәм итә.

Ф.Тумеркина китабында авыл тарихы, революция, коллективлаштыру вакыйгалары да урын алган, шулай ук Яваевлар турында да мәгълүмат бар.

Бөтендөнья татар конгрессының башкарма комитеты җитәкчесе Данис Шакиров әйтүенчә, «паша» сүзе генерал дигәнне аңлатуын искәртте. «Шакир паша Госманлы дәүләтендә беренче татар генералы һәм талантлы гаскәри була. Сезгә китап кына чыгарып калмыйча, Шакир паша турында тулырак мәгълүматны Википедиягә урнаштырырга тәкъдим итәм. Истанбулда кабер ташында татар кешесе дигән язу булырга тиеш», – диде ул.

Зилә МӨБӘРӘКШИНА.
Салават КАМАЛЕТДИНОВ фотосы.



Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

21 октябрь – Шәрык клубында 17.00 – «Яңа шимбәчеләр» клубында түгәрәк өстәл янында актер Фәнис Җиһанша белән очрашу. 19.00 – «Килә ява, килә ява...» (З.Хәким).
22 октябрь – Зур залда – «Сәфәр» (А.Шакиров), кече залда – «Көл» (К.Митани).
23 октябрь – «Гөргөри кияүләре» (Т.Миңнуллин),
25 октябрь – «Җәйнең бер көнендә» (Й.Фоссе).
26 октябрь – «Сүнгән йолдызлар» (К.Тинчурин).
27 октябрь – Зур залда – «Җанкисәккәем» (Т.Миңнуллин). Кече залда – «Хуш, авылым! Хыял» (А.Җаббаров).
28 октябрь – Зур залда – «Өйләнәм.tat» (И.Зәйниев), кече залда – «Килмешәк» (С.Гаффарова).

М.ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ҺӘМ БАЛЕТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

28 октябрь – «Мадам Баттерфляй» (Дж.Пуччини).

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ

21 октябрь – «Кияү урлау» (С.Юзеев әсәре, Х.Ибраһим тәрҗемәсе).
22 октябрь – 12.00 – «Асылкош» (Р.Мөхәммәтшин), 17.00 – «Алай түгел, болай ул» (Т.Миңнуллин).
23 октябрь – «Кияүләр» (Х.Вахит).
26 октябрь – «Хыялый» (С.Әбүзәров).
27 октябрь – «Беренче театр» (Г.Камал).
28 октябрь – «Ак тәүбә, кара тәүбә. Безнең көннәр» (Т.Миңнуллин).

Г.КАРИЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ЯШЬ ТАМАШАЧЫ ТЕАТРЫ

21 октябрь – «Микулай» (М.Гыйләҗев).
22 октябрь – «Мәхәббәт күгәрченнәре» (В.Гуркин).
23 октябрь – «Тапшырыл...ган хатлар» (Г.Кутуй).

«ӘКИЯТ» ТАТАР ДӘҮЛӘТ КУРЧАК ТЕАТРЫ

21 октябрь – 11.00, 13.00 – «Русалочка» (Г.-Х.Андерсен). 15.30 – Театр буенча сәяхәт.
22 октябрь – Фойеда – «Не хочу, не буду» (П.Геннадьева). Зур залда – «Буратино» (А.Толстой).
23 октябрь – Зур залда – «Волк и семеро козлят» (Э.Гыйлемханова инсценировкасы). Кече залда – «Котбетдин маҗаралары» (Н.Гернет).
26 октябрь – «Страна чудес Алисы» (Л.Кэрролл әсәре буенча).

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕНЕҢ КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

21 октябрь – Татарстан Республикасы филармония джаз дәүләт оркестры концерты.
22 октябрь – «Голоса Градского» дип исемләнгән вокаль-театраль проект кысаларында Шәрип Умханов, Алла Рид, Эмиль Кадыров җырлый.
23 октябрь – Балалар өчен музыка уен кораллары белән танышу концерты.
24 октябрь – «Мой Лермонтов» драма спектакле.
25 октябрь – «Донбасс» дәүләт академия җыр һәм бию ансамбле концерты.
27 октябрь – Алексей Мельников концерты (фортепиано).

С.СӘЙДӘШЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ЗУР КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

21 октябрь – Башкортстан Республикасының Линар Дәүләтбаев җитәкчелегендәге халык музыка уен кораллары дәүләт оркестры концерты.
23 октябрь – 12.00 – Балалар өчен «Остров сокровищ» дип исемләнгән ком анимацияле концерт. 17.00 – Антонио Вивальди музыкасына багышланган концерт.
24 октябрь – Төркиядән «Танити» триосы концерты.
25 октябрь – М.Таминдарова җитәкчелегендәге дәүләт камера хорының «Русский акцент» дип исемләнгән концерт программасы.

Гаҗәеп елгалар

Елга нәрсә белән гаҗәпләндерсен инде, дисезме? Алар барысы да бер-берсенә охшаган һәм бары тик үлчәмнәре, формасы, ярлары, андагы үсемлекләре белән генә аерыла бит. Чынлыкта исә һәр елга уникаль, һәркайсының кабатланмас холкы бар. Араларында Нил кебек озын һәм куәтлеләре дә, Роу сыман кечкенә һәм тынычлары да, Зәңгәр елга төсле саф сулылары да, Хуанхэ яки Цитариум кебек болганчык һәм пычраклары да очрый. Мәсәлән, АКШ тагы Колорадо, Глен каньоны кыялары арасыннан акканда, тигез кырыйлы һәм симметрияле дага сурәте ясап кискен борыла. Россиядәге Лена – Төньяк-Көнчыгыш Себердәге иң зур елга, аның бер як ярындагы 200 метр биеклектәге кыя-баганалар таң калдыра. Португалиядәге Оделейте елгасы югарыдан караганда аждаһаны хәтерләтә, шуңа аны “Зәңгәр аждаһа” дип йөртәләр. Колумбиядәге Канто-Кристалес – дөньяда иң матур елга, аның төбендә үскән кызыл, сары, яшел, күгелҗем төстәге суүсем-мүкләр үтә күренмәле судан бик яхшы күренә, шунлыктан “Биш төсле елга” дип йөртелә. Гренландия 2-3 километр калынлыктагы боз белән капланган, җәен эрегәндә, кар сулары чын елгага әйләнә: карасу аквамарин төсендәге бу елга ап-ак тирәлектә искиткеч сихри күренә. Кытайдагы Шуантай-Хэкоу тыюлыгында ярлары куе кызыл төстәге Ляохэ елгасы ага, әлеге төсне сулык тугаен сентябрь башында тоташ келәм кебек каплап алган диңгез суүсемнәре бирә. Кытайдагы Хуанхэ – Җир шарындагы иң болганчык елга. Аның суының һәр кубометрында якынча 35-40 килограмм тау токымы бар. Көйсез, котырынкы холкы өчен аны “Кытай хәсрәте”, “Мең бәла елгасы”, “Йөрәк үксеткеч елга” дип йөртәләр. Хезмәт сөючән кытайлар анда 14 гидроэлектростанция төзегән һәм рәхәтләнеп пычрата. Дөньяда иң кыска елга АКШның Монтана штатында ага – Роуның озынлыгы нибары 17,7 метр тәшкил итә. Дөньяда иң пычрак елга – Индонезиядәге Цитарум. Аның бассейнында 5 миллион кеше яши, һәм аларның хуҗалык эшчәнлеге елганы көн саен пычрата. Азия үсеш банкы аны чистартуга ярты миллиард доллар сарыф иткән, әмма бик тиз арада елга кире үз хәленә кайткан. Нил – дөньяда иң озын елга: Сахараны кичеп, Урта диңгезгә барып җиткәнче, ул 6700 чакрымга сузыла.

(“AdMe.ru”).

Кайчандыр коммунизм булган

XI гасырдан XVI гасырга кадәр Көньяк Америкада инклар империясе гөрләгән. Ул хәзерге Колумбия, Чили, Боливия, Эквадор, Аргентина, Перу территорияләрен үз эченә алган. Инклар дәүләте акчасыз һәм базарсыз яшәгән. Испан конкистадорлары бөек цивилизацияне ут һәм кылыч белән генә түгел, чәчәк (оспа) бацилласы белән дә һәлак иткән, чөнки инкларда аңа каршы иммунитет булмаган. Биредәге җәмгыять строе марксизм-ленинизм классиклары хыялланган коммунизмны хәтерләткән. Үсеше бик алга киткән илдә сәүдә сыйныфы булмаган. Товар җитештерү, бүлү һәм халыкны тәэмин итүне үзәк хөкүмәт контрольдә тоткан. Дәүләт складларындагы азык-төлек, кием-салым, хезмәт кораллары, төзелеш өчен материаллар теләгән һәркемгә бушлай бирелгән. Беркем дә бернәрсә дә сатып алмаган. Салым урынына халык дәүләткә үзенең хезмәте белән түләгән, шуның өчен тормышка кирәкле бөтен нәрсә белән тәэмин ителгән. Инклар җәмгыятенең фән, сәнгать, архитектурада шундый казанышларга базар икътисадсыз гына ирешә алуына галимнәр һаман таң кала. Ә бит инклар коммунизмы күп гасырлар буе гамәлдә булган һәм испаннар һөҗүме аркасында гына юкка чыккан.

(“Вокруг света”).

Билләре юанайган

Bluebella компаниясе заказы буенча үткәрелгән тикшеренү соңгы 70 елда хатын-кызларның шактый буйга үсүен һәм авырлыгы, шулай ук кереме һәм гомер озынлыгы да артуын күрсәткән. Тикшеренү үткәргәндә 1950 еллардагы һәм безнең көннәрдәге статистика мәгълүматлары файдаланылган. Иң зур үзгәреш гүзәл затларның биленә кагыла – ул 20 сантиметрга диярлек юанайган, бу кием үлчәмен дә үзгәрткән. Илленче елларда 46 нчы үлчәмләләр күпчелекне тәшкил итсә, хәзер 50 нче үлчәмле кием киючеләр күбрәк. Белгечләр гомер озынлыгын һәм хезмәт хакын да чагыштырган. Беренчесенең 10 елга артуы ачыкланган. Хезмәт хакына килгәндә исә, үткән гасыр уртасында атнасына 10 фунт алып эшләсәләр, хәзер түләү атнасына уртача 530 фунтка җиткән. 1950 елда хатын-кызның буе уртача 158 сантиметр, күкрәк әйләнәсе - 89-91, биле - 68 сантиметрга тәңгәл, аягы 36 нчы үлчәмле, гомер озынлыгы 73 ел булса, безнең көннәрдә буе уртача 167, күкрәк әйләнәсе 100-102, биле 86 сантиметрга тәңгәл, аягы 38 нче үлчәмле, гомер озынлыгы 83 ел тәшкил итә. Белгечләр фикеренчә, тән параметрлары үзгәрүнең сәбәбе берничә: торак-санитария шартларының яхшыруы, медицинаның алга китүе буйны үстерсә, шикәр, фастфуд һәм алкоголь куллануның артуы, физик активлыкның кимүе билне юанайткан.

(“Daily Mail”).

Пар бәхет

АКШта ике дус Mega Millions лотереясенә 1,3 миллиард доллар откан. Алар аны Иллинойс штатындагы Дес-Плейнс шәһәрендәге ягулык салу станциясендә сатып алган һәм откан очракта акчаны тигезләп бүлергә килешкән. Берничә айдан соң аларга шатлыклы хәбәр килеп ирешкән. Әлеге отыш АКШ тарихында иң зур өч отышның берсе булып чыккан. Бәхет елмайган дуслар отышны берьюлы алырга булган, салымнарны чигергәннән соң 780 миллион доллар кулларына кергән. Штатның лотерея директоры Гарольд Мэйс әйтүенчә, җиңүчеләр әлегә шатлыктан исереп йөри һәм күктән төшкән байлыкларын ничек тузгыдырасын планлаштыра.

(“Associated Press”)

Смартфон арканы авырттыра

Америка галимнәре смартфон хуҗаларының аркасы һәм муены гаджетлары булмаган кешеләргә караганда иртәрәк авырта башлавын ачыклаган. Хирург-ортопедлар Тодд Ланман һәм Джейсон Куэллар әйтүенчә, аркасы каты авыртудан яки умырткаара диск бүсереннән интеккән яшьләр саны көннән-көн арта икән. Аларның рентген сурәтләрен тикшергәч, табибләр әлеге үсмерләрнең муеннары сәер кәкрәюгә игътибар иткән. Моның сәбәбе – берничәшәр сәгать рәттән смартфонга текәлеп утыру. Галимнәр раславынча, кулдагы смартфонга башны кыегайтып караганда да умырткалыкка басым шактый арта. Мәсәлән, кеше туры басып торганда, аның башының авырлыгы 4,5-5,5 килограмм тәшкил итә, ә башны 60 градуска игәндә, умырткалыкка инде 27 килограммлы басым ясала икән. Умыртка баганасын саклау өчен, текст җыйганда телефонны күз биеклегендә тотарга киңәш итәләр, хәрефләрне ике кул бармаклары белән җыйганда исә ничек тә җайлырак халәтне табарга тырышу зарур.

(“The Spine Journal”).



1400 еллык агач

Искиткеч бу гинкго агачы Тан династиясеннән император Ли Шимин чорында утыртылган, дип фаразлыйлар, ә үсемлекләрнең әлеге төренә 200 миллион ел икән. Мәгърур агачны һәм аның сокландыргыч алтын яфраклары коелуын күзәтү өчен көзен таулы Чжунннань районына Кытайның төрле төбәкләреннән һәм бөтен дөньядан меңләгән кеше агыла.

(“Nation Geographic”).

Газета өчен Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.

Дүшәмбе

24 октябрь
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Татар халык җырлары».
5.50, 7.00, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 16.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
10.00, 23.00 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ». 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
11.30 «Заман көзгесе». 6+
12.00, 22.10 «ФАРЦА». 16+
13.00 «Семь дней». 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество». 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә».
16.30 «Татарлар». 12+
17.00 Хоккей. «Металлург» (Мг) - «Ак Барс». 6+
20.00, 21.00, 0.15 «Таяну ноктасы». 16+
22.00 «Вызов 112». 16+
23.50 «Соотечественники». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

6.00, 13.05 «Манзара». 6+
8.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра». 6+
8.40, 23.05 «Башваткыч». 12+
9.50 «Семь дней». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30 «Туган җир». 12+
12.05 «Йөрәктән-йөрәккә». Нурихан Фәттах турында телеочерк. 6+
15.30 «Заман көзгесе». 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
18.20, 21.25 «КЕШЕЧӘ ЯШИК!» 12+
19.00, 22.05 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ЧУЖОЕ ГНЕЗДО». 12+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ИСЧЕЗНУВШАЯ». 16+
10.30, 21.00 «ВЕРНИ МОЮ ЛЮБОВЬ». 12+
11.30 «СОБЛАЗН». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «РОК-Н-РОЛЛ ПОД КРЕМЛЕМ». 16+
14.35 «Десять месяцев, которые потрясли мир». 12+
15.00 «Химия». 12+
15.30 «Кавказский пленник». 12+
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 23.45 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «ТРИГГЕР». 16+
22.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ХУДОЖНИК». 16+
22.20, 23.45 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+
23.00 «Бесогон ТВ». 16+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.40, 10.00, 15.00, 19.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 Невский ковчег. Теория невозможного. Владимир Балыбердин.
8.00 Черные дыры. Белые пятна.
8.50, 22.10 «МЕСТО ВСТРЕЧИ ИЗМЕНИТЬ НЕЛЬЗЯ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 XX век. «Легенды и быль о Янтарной комнате».
11.55 Спектакль «Ленком Марка Захарова».
15.05 Новости. Подробно. АРТ.
15.20 «Агора».
16.25 «Возрождение дирижабля».
17.10 Симфоническая музыка эпохи романтизма. А. Брукнер. Симфония №7. Валерий Гергиев и Мюнхенский филармонический оркестр.
18.35 «Покахонтас и капитан Джон Смит. Трагическая история любви».
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 «У меня нет времени говорить неправду».
21.30 «Сати. Нескучная классика...»
23.20 Цвет времени. Николай Ге.
23.30 «Почерк эпохи». «Николай Гоголь. «Мертвые души. Том II».

«НТВ»

4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ТВЕРСКАЯ». 16+
22.10, 0.00 «БАЛАБОЛ». 16+

Сишәмбе

25 октябрь
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Татар халык җырлары».
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
10.00, 23.00 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ». 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте». 12+
11.15 «Память сердца». 12+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ФАРЦА». 16+
13.00 «Родная земля». 12+
13.30 «Юлчы». 6+
14.00 «Путь». 12+
14.15 «Не от мира сего...» 12+
15.15 «Төймә».
16.00 «Ватандашлар». 12+
18.00 «Казаннан - казанга». 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Туган авылым». 6+
21.00, 0.15 «Соотечественники». 12+
23.50 «Видеоспорт». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.05 «Манзара». 6+
8.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра». 6+
8.40, 23.05 «Җырлыйк әле!» 6+
9.40 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
10.30, 20.30 «Халкым минем». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 20.00 «Таяну ноктасы». 16+
15.30 «Ватандашлар». 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
18.20, 21.25 «КЕШЕЧӘ ЯШИК!» 12+
19.10, 22.10 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ЧУЖОЕ ГНЕЗДО». 12+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30 «ИСЧЕЗНУВШАЯ». 16+
10.30, 21.00 «ВЕРНИ МОЮ ЛЮБОВЬ». 12+
11.30 «СОБЛАЗН». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «РОК-Н-РОЛЛ ПОД КРЕМЛЕМ». 16+
14.35 «Десять месяцев, которые потрясли мир». 12+
15.00 «Просто физика с Алексеем Иванченко». 12+
15.30 «Кавказский пленник». 12+
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
20.00 «МАНЕКЕНЩИЦА». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20, 23.45 Информационный канал. 16+
16.00 «Холодная война Никиты Хрущева». 16+
21.00 «Время».
21.45 «ТРИГГЕР». 16+
22.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ХУДОЖНИК». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 «Покахонтас и капитан Джон Смит. Трагическая история любви».
8.35 Дороги старых мастеров. «Гончарный круг».
8.45, 22.10 «МЕСТО ВСТРЕЧИ ИЗМЕНИТЬ НЕЛЬЗЯ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 «Дмитрий Шостакович».
12.05 «Первые в мире».
12.20 Спектакль «Ленком Марка Захарова».
14.30 «Запечатленное время».
15.05 Новости. Подробно. Книги.
15.20 «Эрмитаж».
15.50 «Сати. Нескучная классика...»
16.35 «ЮРКИНЫ РАССВЕТЫ».
17.45 Симфоническая музыка эпохи романтизма. Р. Шуман. Симфония №1 «Весенняя». Айвор Болтон и Дрезденский фестивальный оркестр.
18.30 «Колизей - бриллиант в короне Рима».
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 Искусственный отбор.
21.30 «Белая студия».
23.30 «Почерк эпохи». «Сергей Рахманинов. Я русский композитор».

«НТВ»

4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ТВЕРСКАЯ». 16+
22.10, 0.00 «БАЛАБОЛ». 16+

Чәршәмбе

26 октябрь
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Татар халык җырлары».
5.50, 7.00, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 16.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
10.00, 23.00 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ». 16+
11.00, 0.15 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ФАРЦА». 16+
13.00 «Җырлыйк әле!» 6+
14.00 «Здоровая семья: мама, папа и я». 6+
14.15 «Если хочешь быть здоровым...» 12+
15.15 «Бергәләп өйрәник».
17.00 Хоккей. «Салават Юлаев» - «Ак Барс». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+
21.00 Документальный фильм. 12+
22.00 «Вызов 112». 16+
23.50 «Соотечественники». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05, 8.40, 23.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.05 «Манзара». 6+
8.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра». 6+
9.40 «Ачыктан - ачык». 12+
10.40 «Туган авылым». 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 20.00 «Таяну ноктасы». 16+
12.35 «Кыргый океан серләре». 6+
15.30, 0.15 «Яшьләр тукталышы». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
18.20, 21.25 «КЕШЕЧӘ ЯШИК!» 12+
19.05, 22.05 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.30 «Юлчы». 6+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ЧУЖОЕ ГНЕЗДО». 12+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «МАНЕКЕНЩИЦА». 16+
10.30, 21.00 «ВЕРНИ МОЮ ЛЮБОВЬ». 12+
11.30 «СОБЛАЗН». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «БАРБИ И МЕДВЕДЬ». 12+
15.00 «Химия». 12+
15.30 «Кавказский пленник». 12+
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20, 23.45 Информационный канал. 16+
16.00 «Карибский узел». 16+
21.00 «Время».
21.45 «ТРИГГЕР». 16+
22.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ХУДОЖНИК». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 «Колизей - бриллиант в короне Рима».
8.40 Цвет времени. Жан Этьен Лиотар. «Прекрасная шоколадница».
8.50, 22.10 «МЕСТО ВСТРЕЧИ ИЗМЕНИТЬ НЕЛЬЗЯ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 XX век. «Клуб путешественников. В Антарктиду через Мозамбик».
12.20 Спектакль «Ленком Марка Захарова».
14.30 «Запечатленное время».
15.05 Новости. Подробно. Кино.
15.20 «Библейский сюжет».
15.45 «Белая студия».
16.30 «ЮРКИНЫ РАССВЕТЫ».
17.30 Симфоническая музыка эпохи романтизма. А. Дворжак. Симфония №8. Пааво Ярви и Оркестр де Пари.
18.40 «Елизавета I: королева-убийца?»
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 Абсолютный слух.
21.30 Власть факта. «Освальд Шпенглер и его «Закат Европы».
23.20 Цвет времени. Карандаш.
23.30 «Почерк эпохи». «Владимир Татлин. Летатлин...»

«НТВ»

4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ТВЕРСКАЯ». 16+
22.10, 0.00 «БАЛАБОЛ». 16+

Пәнҗешәмбе

27 октябрь
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Татар халык җырлары». 6+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
10.00, 0.00 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ». 16+
11.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 23.10 «БЕРДӘН БЕР». 16+
13.00 «Кәмит Җәвит». 16+
14.00 «Туган авылым». 6+
14.15 «Фолиант в столетнем переплёте». 12+
14.45 «Татар халык җырлары».
15.15 «Шома бас» һәм «Алты хәреф».
16.00 «Казаннан - казанга». 12+
18.00 «Юлчы». 6+
19.00, 20.00 «Точка опоры». 16+
21.00 «Соотечественники». 12+
22.00 «Вызов 112». 16+
22.10 «Безнең Республика - безнең гамәл». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.05 «Манзара». 6+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 6+
8.35, 23.05 «Кәмит Җәвит». 16+
9.40 «Кунак БИТ Шоу». 12+
10.40 «Туган авылым». 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05 «Таяну ноктасы». 16+
12.35 «Кыргый океан серләре». 6+
15.30, 0.15 «Халкым минем». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00 «Татар халык моңнары». 6+
18.20, 21.25 «КЕШЕЧӘ ЯШИК!» 12+
19.00, 22.00 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Йөрәктән-йөрәккә». Рөстәм Вәлиев турында телеочерк. 6+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ЧУЖОЕ ГНЕЗДО». 12+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «МАНЕКЕНЩИЦА». 16+
10.30, 21.00 «ВЕРНИ МОЮ ЛЮБОВЬ». 12+
11.30 «СОБЛАЗН». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «БАРБИ И МЕДВЕДЬ». 12+
14.35 «Десять месяцев, которые потрясли мир». 12+
15.00 «Клинический случай». 12+
15.30 «Кавказский пленник». 12+
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20, 23.45 Информационный канал. 16+
16.00 «Карибский узел». 16+
21.00 «Время».
21.45 «ТРИГГЕР». 16+
22.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ХУДОЖНИК». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 7.30, 8.25, 10.00, 15.00, 19.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 «Елизавета I: королева-убийца?»
8.30 Дороги старых мастеров. «Мстёрские голландцы».
8.40, 22.10 «МЕСТО ВСТРЕЧИ ИЗМЕНИТЬ НЕЛЬЗЯ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 «Артисты цирка Ермолаевы».
12.10 Цвет времени. Эдуард Мане. «Бар в Фоли-Бержер».
12.20 Спектакль «Ленком Марка Захарова».
14.00 «Екатеринбург. Особняк Тупиковых».
14.30 «Запечатленное время».
15.05 Новости. Подробно. Театр.
15.20 Моя любовь - Россия! «По мостовым средневекового Новгорода».
15.50 «Алгоритм Берга».
16.20 «ЮРКИНЫ РАССВЕТЫ».
17.25 Большие и маленькие.
19.45 Главная роль.
20.05 Открытая книга. Михаил Попов. «На кресах всходних».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 «Настоящее-прошедшее. Поиски и находки».
21.15 Цвет времени. Валентин Серов.
21.30 «Энигма. Соня Зимменауэр».
23.30 «Почерк эпохи». «Леонид Утесов. Музыкальное сердце».

«НТВ»
4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.30 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ТВЕРСКАЯ». 16+
22.10, 0.00 «БАЛАБОЛ». 16+

Җомга

28 октябрь
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35, 14.45 «Татар халык җырлары».
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
10.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 6+
11.00 «Нәсыйхәт». 6+
11.30 «Татарлар». 12+
12.00, 23.10 «БЕРДӘН БЕР». 16+
13.00 «Башваткыч». 12+
14.00 «Актуальный ислам». 6+
14.15 «Классный час». 12+
15.15 «Тизрәк! Алга! Җитезрәк!» һәм «Алты хәреф».
16.00 «Аулак өй». 6+
16.30 «Әдәби хәзинә». 6+
18.00 «Туган җир». 12+
19.00 «Болгар радиосы» концерты. 6+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 Телефильм. 12+
21.00 «Юлчы». 6+
22.10 «КВН РТ-2022». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.05 «Манзара». 6+
8.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра». 6+
8.40, 23.05 «Ком сәгате». 12+
9.40, 15.30, 0.15 «Нәсыйхәт». 6+
10.30 «Казаннан казанга». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30 «Татарлар». 12+
12.05 «Йөрәктән-йөрәккә». Шәүкәт Биктимеров турында телеочерк. 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.30, 0.40 «Калеб». 6+
18.20, 21.25 «Йөрәктән-йөрәккә». Марс Макаров турында телеочерк. 6+
19.15 «Туган җир». 12+
19.40 «Заман көзгесе». 6+
20.10, 22.10 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+

«ЭФИР»
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ЧУЖОЕ ГНЕЗДО». 12+
9.25, 11.25, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «МАНЕКЕНЩИЦА». 16+
10.30, 21.00 «ВЕРНИ МОЮ ЛЮБОВЬ». 12+
11.30 «СОБЛАЗН». 16+
12.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00, 23.45 «ПОЗВОНИТЕ МЫШКИНУ». 6+
14.30 «Десять месяцев, которые потрясли мир». 12+
15.00 «Просто физика с Алексеем Иванченко». 12+
15.30 «Мировой рынок». 12+
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.30 «Fam TV». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15 Информационный канал. 16+
18.40 «Человек и закон». 16+
19.45 «Поле чудес».
21.00 «Время».
21.45 Фантастика. 12+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.15 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.30 «Ну-ка, все вместе!» 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 7.30, 8.25, 10.00, 15.00, 19.30, 23.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 «Катя и принц. История одного вымысла».
8.15 Цвет времени. Пабло Пикассо. «Девочка на шаре».
8.30, 22.00 «МЕСТО ВСТРЕЧИ ИЗМЕНИТЬ НЕЛЬЗЯ».
10.20 «ДЕВУШКА СПЕШИТ НА СВИДАНИЕ».
11.35 Цвет времени. Эдвард Мунк. «Крик».
11.50 Открытая книга. Михаил Попов. «На кресах всходних».
12.20 Спектакль «Ленком Марка Захарова».
13.50 Власть факта. «Освальд Шпенглер и его «Закат Европы».
14.30 «Настоящее- прошедшее. Поиски и находки».
15.05 Письма из провинции. Бурятия.
15.35 «Энигма. Соня Зимменауэр».
16.20 «ЮРКИНЫ РАССВЕТЫ».
17.25 Симфоническая музыка эпохи романтизма. И. Брамс. Симфония №2. Риккардо Мути и Венский филармонический оркестр.
18.20 «Царская ложа».
19.00 «Тамбов. Дворец Асеевых».
19.45 «Смехоностальгия».
20.15 Искатели. «Загадочная смерть досточтимого мастера».
21.05 Линия жизни. Александр Цыпкин.
23.50 «2 Верник 2». Евгений Князев.

«НТВ»
4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.25 «Мои университеты. Будущее за настоящим». 6+
9.25, 10.35 Х/ф «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ». 16+
11.00 Х/ф «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СЕВЕРНЫЕ РУБЕЖИ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «ДНК». 16+
17.55 «Жди меня». 12+
20.00 «ТВЕРСКАЯ». 16+
22.10 «БАЛАБОЛ». 16+

Шимбә

29 октябрь
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Татар халык җырлары».
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 6+
7.00 «Sиңа Миннән Sәлам». 6+
9.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00 «Туган авылым». 6+
11.30 «Казаннан - казанга». 12+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Видеоспорт». 12+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
13.30 Концерт «Безнең заман - наше время». 6+
14.30 «Халкым минем...» 12+
15.00 «Яшик әле!» Разил Вәлиевнең юбилей кичәсе. 6+
18.00 «Кәмит Җәвит». 16+
19.00 «Tatarstan today. Открытый миру». 12+
19.30, 21.30 Новости в субботу. 12+
20.00 «Адымнар». 12+
20.30 «Җырлыйк әле!» 6+
22.00 «КунакБит- шоу». 12+
23.10 «ВСЕ ПАРЫ ДЕЛАЮТ ЭТО». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00 «Йөрәктән-йөрәккә». Шәүкәт Биктимеров турында телеочерк. 6+
7.00, 15.00 «Sиңа Миннән Sәлам». 6+
9.00 «Кәмит Җәвит». 16+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00, 18.15 «Башваткыч». 12+
12.05, 19.05 «Җырлыйк әле!» 6+
13.00 «Туган авылым». 6+
13.20 «Бир кулыңны». Зөлфирә һәм Алмаз Мирзаяновлар концерты. 6+
17.10 «Казаннан казанга». 12+
17.45 «Халкым минем». 12+
20.00 «Адымнар». 12+
20.30 «Гомер чишмәм». Рәсим Низамов концерты. 6+
23.00 Спектакль «Сәер кеше». 12+

«ЭФИР»
5.00 «Фронтовая Москва. История победы». 12+
5.30 «Россия. Связь времен». 12+
6.00 «Десять месяцев, которые потрясли мир». 12+
6.30 «Клинический случай». 12+
7.00 «Четверо в кубе».
7.30 «Лекс и Плу: Космические таксисты».
8.00 «Один день в городе». 12+
8.35 «5 ЛЕТ СПУСТЯ». 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ВСПОМНИ ВСЕ». 16+
15.00 «Клятва Гиппократа». 12+
15.30 «БЕГЛЫЕ РОДСТВЕННИКИ». 16+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ДАЛЬНЯЯ ДОРОГА». 16+
23.10 «МИССИС УИЛСОН». 18+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00 «Доброе утро. Суббота».
9.00 «Умницы и умники». 12+
9.45 «Слово пастыря».
10.00, 12.00, 18.00 Новости.
10.15 «ПроУют».
11.10 «Поехали!» 12+
12.15 «Видели видео?»
14.45 «А У НАС ВО ДВОРЕ...» 12+
16.55 «Горячий лед». Фигурное катание.
18.20 «Снова вместе. Ледниковый период».
21.00 «Время».
21.35 «КВН». 16+
23.55 «ОДИССЕЯ». 12+

«РОССИЯ»
5.00 «Утро России. Суббота».
8.00 Вести. Местное время.
8.20 Местное время. Суббота.
8.35 «По секрету всему свету».
9.00 «Формула еды». 12+
9.25 «Пятеро на одного».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30 «Доктор Мясников». 12+
12.35 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ». 16+
18.00 «Привет, Андрей!» 12+
21.00 «БЕЗ ВИНЫ ВИНОВАТАЯ». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Библейский сюжет».
7.05 М/ф «Аленький цветочек».
7.50 «ШЕСТНАДЦАТАЯ ВЕСНА».
9.15 «Обыкновенный концерт».
9.45 «Мы - грамотеи!»
10.25 Неизвестные маршруты России. «Ханты-Мансийский автономный округ - Югра. Из Когалыма к оленям».
11.05 Спектакль «Трактирщица».
12.25 «Эрмитаж».
12.55 Черные дыры. Белые пятна.
13.35 «Земля, взгляд из космоса».
14.30 «Рассказы из русской истории». Владимир Мединский.
15.30 У Чайковского в Клину. Романсы в исполнении Екатерины Семенчук.
16.50 «ДОСТОЯНИЕ РЕСПУБЛИКИ».
19.00 «Энциклопедия загадок».
19.30 Больше, чем любовь.
20.10 Спектакль «Кошка на раскаленной крыше».
23.10 Клуб «Шаболовка, 37».

«НТВ»
5.05 «Спето в СССР». 12+
5.50 «ИНСПЕКТОР КУПЕР». 16+
7.30 «Смотр».
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «Поедем, поедим!»
9.20 «Едим дома».
10.20 «Главная дорога». 16+
11.00 «Живая еда». 12+
12.00 «Квартирный вопрос».
13.00 «Секрет на миллион». 16+
15.00 «Своя игра».
16.20 «ЧП. Расследование». 16+
17.00 «Следствие вели...» 16+
19.00 «Центральное телевидение».
20.20 «Шоу Аватар». 12+
23.20 «Ты не поверишь!» 16+

Якшәмбе

30 октябрь
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Татар халык җырлары».
6.00 «Үткәннәрне барлап...» Айдар Фәйзрахмановның юбилей концерты. 12+
8.00, 13.00 «Адымнар». 12+
8.30 Мультфильм.
8.45 «Әти һәм мин».
9.15 «Тамчы- шоу».
9.45 «Яшьләр тукталышы». 12+
10.15 «Ачыктан - ачык». 12+
11.00 «Туган авылым». 6+
11.20 «УРБАС! Эра татарстанского регби». 12+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество». 12+
13.30 Концерт «Безнең заман - наше время». 6+
14.30 «Видеоспорт». 12+
15.00 «Наша Республика - наше дело». 12+
16.00, 0.40 «Ком сәгате». 12+
17.00 Хоккей. «Ак Барс» - «Нефтехимик». 6+
19.30, 22.00 «Семь дней». 12+
20.30 «Заман көзгесе». 6+
21.00 «Профсоюз - союз сильных». 12+
21.15 «Батырлар». 6+
21.30 «Болгар радиосы» концерты. 6+
23.00 «ДОБРО ПОЖАЛОВАТЬ В КАПКАН». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05, 12.35 «Халкым минем». 12+
5.30 «Нәсыйхәт». 6+
6.00 «Заман көзгесе». 6+
6.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
7.00 «Шаян хәлләр». 12+
7.40 «Җырларым-моңнарым тик сезнең өчен». Марсель Иванов җырлары. 6+
9.30 «Йөрәктән-йөрәккә». 6+
10.30, 0.10 «Калеб». 6+
11.10 «Тамчы-шоу». 6+
11.45 «Бергәләп өйрәник». 6+
12.05, 0.40 «Яшьләр тукталышы». 12+
13.00 «Туган авылым». 6+
13.20 «Әзелеп җырлый торган җыр булса». Рафаэль Ильясов концерты. 6+
14.45 Спектакль «Әниләр һәм бәбиләр». 6+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
18.10 «Кәмит Җәвит». 16+
19.05 «Ком сәгате». 12+
20.00 «Семь дней». 12+
21.10 «Элэктегезме?..». «Мунча ташы» спектакле. 12+

«ЭФИР»
5.00, 15.10 «Фронтовая Москва. История победы». 12+
5.30 «Россия. Связь времен». 12+
6.00 «Десять месяцев, которые потрясли мир». 12+
6.30 «Просто физика с Алексеем Иванченко». 12+
7.00 «Четверо в кубе».
7.30 «Лекс и Плу: Космические таксисты».
8.00 «Один день в городе». 12+
8.30 «БЕГЛЫЕ РОДСТВЕННИКИ». 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ДАЛЬНЯЯ ДОРОГА». 16+
15.30 «5 ЛЕТ СПУСТЯ». 16+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ВСПОМНИ ВСЕ». 16+
23.00 «КЛЕВЫЙ ПАРЕНЬ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.05, 6.10 «ТРИ ДНЯ ВНЕ ЗАКОНА». 16+
6.00, 10.00, 12.00 Новости.
6.55 «Играй, гармонь любимая!» 12+
7.40 «Часовой». 12+
8.10 «Здоровье». 16+
9.20 «Мечталлион». 12+
9.40 «Непутевые заметки». 12+
10.15 «Жизнь своих». 12+
11.10 «Повара на колесах». 12+
12.15 «Видели видео?»
14.30, 23.55 «ХОЛОДНОЕ ЛЕТО ПЯТЬДЕСЯТ ТРЕТЬЕГО...» 16+
16.25 «Горячий лед». Фигурное катание.
17.45 «Поем на кухне всей страной». 12+
19.55 «Мир на грани. Уроки Карибского кризиса». 16+
21.00 «Время».
22.35 «Что? Где? Когда?»

«РОССИЯ»
5.40 «ЗАЕЗЖИЙ МОЛОДЕЦ». 12+
7.15 «Устами младенца».
8.00 Местное время. Воскресенье.
8.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым».
9.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00 Вести.
11.30 «Большие перемены».
12.35 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ». 16+
18.00 «Песни от всей души». 12+
20.00 Вести недели.
22.00 Москва. Кремль. Путин.
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Энциклопедия загадок».
7.05 Мультфильмы.
7.50 «ДОСТОЯНИЕ РЕСПУБЛИКИ».
10.05 Диалоги о животных. Калининградский зоопарк.
10.45 Большие и маленькие.
12.50 Невский ковчег. Теория невозможного. Фаддей Беллинсгаузен.
13.20 «Игра в бисер» «Александр Зиновьев. «Катастройка».
14.05 Спектакль «Ленком Марка Захарова».
16.30 «Картина мира с Михаилом Ковальчуком».
17.10 «Пешком...»
17.45 Передача знаний.
18.35 «Романтика романса».
19.30 Новости культуры.
20.10 «Тайники души».
20.50 «ДЕТИ ДОН КИХОТА».
22.05 «Сквозь звёзды». Музыка Джона Уильямса к популярным кинофильмам.
23.35 «ШЕСТНАДЦАТАЯ ВЕСНА».

«НТВ»
5.00 «ИНСПЕКТОР КУПЕР». 16+
6.35 «Центральное телевидение». 16+
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача». 16+
11.00 «Чудо техники». 12+
11.55 «Дачный ответ».
13.00 «НашПотребНадзор». 16+
14.05 «Однажды...» 16+
15.00 «Своя игра».
16.20 «Следствие вели...» 16+
18.00 «Новые русские сенсации». 16+
19.00 Итоги недели.
20.20 «Ты супер!» 6+
23.25 «Звезды сошлись». 16+

Һәр төбәкнең мактанып сөйләрдәй шәхесләре була. Ут күршебез Мари Эл республикасында яшәүче мөселманнар исә заманында Россия күләмендә танылган дин әһелләре Насретдиновлар нәселе белән горурлана. Шушы көннәрдә Бәрәңге бистәсенең мәдәният йортында «Мари Эл җирендә ислам гореф-гадәтләре. Фидай-Мөхәммәт (1869-1924) хәзрәт һәм аның улы Хәлилрахман хәзрәт (1890-1964) Насретдиновлар мирасы» дигән беренче төбәкара фәнни-мәгърифәти конференция узды.

Бәрәңгедә – Насретдиновлар мирасы

● «Нәсел хәтирәсе» китабы авторлары Рәйхана Гаязова һәм Фирзия Сабирҗанова.

Аның эшендә катнашу өчен галимнәр, язучылар, журналистлар Мәскәү, Түбән Новгород, Казан, Йошкар-Ола шәһәрләреннән һәм Россиянең башка төбәкләреннән килгән иде. Җыен Бәрәңге районы башлыгы Әлфит Ибраевның, Марий Эл Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе Фәрит хәзрәт Шагеевның, Россия мөселманнары Диния нәзарәте рәисенең Идел буе федераль округындагы вәкаләтле вәкиле Мөнир Бәюсовның конференциядә катнашучыларны сәламләү чыгышлары һәм мөфти Равил Гайнетдиннең конференциядә катнашучыларга мөрәҗәгатен ирештерүдән башланды.

Насретдиновлар Бәрәңге районы төбәгендә берничә гасыр дәвамында мөселманнарны үзара берләштереп, динебезне ныгытып торучы данлыклы нәсел буларак билгеле. Төбәкне өйрәнүче Фирзия Сабирҗанованың конференциядә ясаган чыгышында Насретдиновлар һәм аларның нәселенең тормышы, эшчәнлеге шактый тулы яктыртылды.

Бу нәсел Татарстанның Арча районы Ташкичү авылында туып-үскән Насретдин бин Габдесәләмнән (1796-1868) башлана. Оренбург өлкәсе Сәгыйть бистәсендә Габдрахман мәдрәсәсендә белем алган егет шушы төбәктәге Яңавылга имам булып килә. Белемле, булдыклы Насретдинны бик тиз күреп алалар. Ул йортын да үзе салып чыга, арба-чаналарын да ясый, җирен сукалап, чәчеп, урып, игенен дә үстерә, тегү эшләрен дә белә. Әмма имам, иң беренче чиратта, тирә-юнь халкын үзенең матур мәкаме белән җәлеп итә һәм Бәрәңге халкы аны үзенә чакырып ала. Насретдин хәзрәт Бәрәңгедә 1771 елда төзелгән үзәк мәчеттә 45 елдан артык имам булып тора, соңрак аның эшен улы Хафизетдин дәвам итә. Бу нәсел хакында Насретдиновларның нәсел дәвамчысы Рәйхана Гаязова белән тарихчы Фирзия Сабирҗанова ике китаптан торган «Нәсел хатирәсе» дигән хезмәт тә бастырып чыгарган, алар бергәләп нәселнең 17 буынын барлаганнар.

Насретдиннең уллары Хафизетдин һәм Борһанетдин башта әтиләре мәдрәсәсендә белем ала, аннары Мазарбашы мулласы Әхмәди бин Ихсан-Әхмәмсәвидә укыйлар. Биредә аларга ислам дине нечкәлекләрен үзләштерү белән бергә йолдызлар (астрономия), мантыйк буенча да гыйлем бирелә. Шул ук вакытта кечкенәдән бик зирәк, талантлы, гыйлемгә омтылышлы Хафизетдин шактый күп китаплар күчереп яза. «Егет алга таба белем алуын Бохарада дәвам итәргә ниятли һәм Габдулла Мәчкәрәви дәресләрен дә тыңлап юлга кузгала», – ди Фирзия ханым. Ул биредә Ш.Мәрҗани белән очраша, галим туган ягына кайтып киткәнче, аңарда өч ел укырга өлгерә. Бу вакытта аларның дуслыгы ныгып өлгерә һәм беркайчан да өзелми, дин әһелләре озак еллар хатлар алышып яши. Бәрәңге егетләре укуга да бик сәләтле була. Ш.Мәрҗани үзенең иң алдынгы 21 шәкертен билгеләгәндә, аларны 4-5 урыннарда язып куя.

Хафизетдин юриспруденция һәм табиблык белән дә кызыксына, шул ук вакытта Ш.Мәрҗани турында хезмәт яза, басмага әзерләнгән «Коръән»нең корректоры да була. Хафизетдин, гомумән, тирә-юньдәгеләрне үзенә гыйлемлеге белән җәлеп иткән. Ул кая гына барып чыкса да, белгечне үз тирәләрендә калдырырга теләгәннәр.

Хафизетдин берничә тапкыр өйләнә. Бәрәңгедә Хафизетдин бабаларының эшен дәвам итүче Зөлкарнәй дөньяга килә. Дүртенче никах исә әтисе Насретдин үтенече буенча энесе вафатыннан соң тол калган итагатьле киленне ятлар кулына тапшырмас өчен укыла.

Революциягә кадәр Бәрәңгедә 4 мәчет эшләгән. Аларда Х. Насретдинов нәселеннән булган муллалар һәм аның уллары Фидай-Мөхәммәт (1869-1924), Зөлкарнәй (1882-1917) имамлык иткән, шәкертләргә белем биргән. Моннан тыш алар бистәдә ислам дине белән бергә дөньяви белем укытуны да кертүчеләр буларак мәгълүм.

Фидай-Мөхәммәт Бәрәңге авылында туа, 21 яшенә кадәр атасыннан гыйлем ала, төрки телләрдә һәм гарәпчә язылган китаплар укый. Ул истәлекләрдә бик күркәм холыклы, тапкыр сүзле, ачык күңелле кеше буларак сурәтләнә. Егет 19 яшендә өченче мәчеттә мөәззин итеп билгеләнә. Бәрәңгедә беренче мәхәллә мөәззин Гаделшә бине Габделгазый бине Үтәгән вафат булгач, аның вазифасын үти. Шул вакытны Габид әл-Бәрәңгеви кызы Бибисаҗидәгә никахлана. Әмма аларга бергә озак яшәү насыйп булмый, Саҗидә яшьли бу дөньядан китә, аның Хәлилрахман исемле улы кала. Шуннан соң Фидай-Мөхәммәт Гайнелнәвал исемле хатынга өйләнә, аларның алты баласы дөньяга килә.

Хәлилрахман башта Казанның Апанай мәдрәсәсендә укый, 20 яше тулганда патша армиясенә хезмәткә алына. Яшь солдат, хезмәтен тәмамлагач, мәхәббәт хисләренә бирелеп, мулла гаиләсеннән икенләгән дә исәпкә алмыйча, Польша кенәзенең кызына өйләнә, хатынын Бәрәңгегә алып кайта. Әмма поляк кызы бу яктагы тормышка җайлашып китә алмый – ислам динен дә кабул итәргә, татар телен дә өйрәнергә теләми, бала да тапмый. Хәлил хәзрәт хатынын берничек тә күндерә алмагач, аерырга карар итә. Поляк киленне, бирнәсен төяп, Казаннан карета яллап, Польша чикләренә кадәр илтеп куялар.

Аннары Хәлилрахман хәзрәт 3 ел Бохара мәдрәсәсендә белем ала. Аны әтисе кабат Бәрәңгегә кайтара, бистәдә мәдрәсәдә балаларга белем бирә башлый. Хәлил хәзрәтне 1918 елда булачак хатыны Гайшә белән таныштыралар, бу никахтан җиде бала туа.

Хәлилрахман Насретдиновның Бәрәңгедәге Кызыл мәчеттә имамлык иткән вакыты диннар эзәрлекләнгән елларга туры килә. Атеистлык дулкыны Бәрәңгене дә аямый, бистәдәге дүрт мәчетнең берсе дә исән калмый. Дипломатик сыйфатларга ия Хәлилрахман хәзрәт, дин әһелләренә карата тискәре мөнәсәбәт башлангач, Мәскәүгә китә. Хәлилрахман хәзрәт башкалада Фидаев фамилиясе белән җәмигъ мәчетенә йөри башлый, 1932 елдан шушы Аллаһ йортында мөхтәсиб һәм казый булып эшли, ә инде 1936 елда аны Мәскәү җәмигъ мәчетенең имам-хатыйбы итеп билгелиләр. Шуннан соң ул Насретдинов фамилиясе белән таныла. Бөек Ватан сугышы елларында Мәскәүдә бердәнбер эшләп килгән җәмигъ мәчетен тотып, фронтка китүчеләргә хәер-фатихасын бирүче, ватаныбызның җиңүе өчен бертуктаусыз догада торучы мөхтәрәм хәзрәт буларак билгеле.

1942 елның маенда Үзәк Диния нәзарәтенең беренче пленумы була. Бу җыенда башында Гитлер торган Алман иленә җиһад игълан итәләр. Анда Хәлил хәзрәт тә катнаша. Х.Насретдинов Бөек Ватан сугышы барган елларда Мәскәүдә халыктан ут эчендәгеләр өчен акчалата ярдәм җыя, аңа танк алынып, фронтка озатыла. Хәлилрахман хәзрәткә бу гамәле өчен Сталиннан рәхмәт хаты да бирелгән.1945 елда Хәлилрахман хәзрәт Согуд Гарәбстанына хаҗ кылучылар төркемен җитәкли. Анда ул хәтта король Габделгазиз белән дә очраша.

Х.Насретдинов 1953 елда хакимият басымы нәтиҗәсендә эшеннән китә. Шуннан соң Мәскәү мөселман дини җәмгыяте имамны кире кайтару турында гариза яза, аңа СССР Европа өлеше мөселманнарының Диния нәзарәте мөфтие Ш.Хилалетдинов та теләктәшлек белдерә. Әмма үтенеч кире кагыла. Хәлилрахман хәзрәт соңгы көннәренә кадәр Мәскәү янындагы Малаховка бистәсендә – дачасында яши. Ул 1964 елда вафат була.

Х.Насретдиновның турыдан-туры нәсел дәвамчылары берсе дә дин юлын сайламаган. Бары тик Насретдин хәзрәтнең алтынчы буын вәкиле, Хәлилрахман хәзрәтнең әтисе Фидай-Мөхәммәтнең бертуган энесе Зөлкарнәй генә муллалык эшен дәвам иткән. Бәрәңге халкы аны бик яхшы хәтерли. Хәзер аның оныгының улы Рамил хәзрәт Зөлкарнәев, бистәдә дини тормышны җитәкли. Ул Бәрәңге бистәсе җирле дини мөселман оешмасы рәисе, имам булып тора. Ул Хәлилрахман хәзрәтнең туган ягына берничә тапкыр кайтып китүен искә алып сөйли.

Бүген Бәрәңге районында 15 меңгә якын кеше яши. Шуның яртысы диярлеге – татарлар, калганнарының күпчелеге марилар һәм 8 проценты руслар. Бәрәңге татарларының рухи тормышы актив төстә яңарыш кичерә. Бистәдә мөселман җәмгыяте 2 яңа мәчет төзегән. Без, журналистлар, Бәрәңгедә бары тик татар телендә генә сөйләшүләргә игътибар иткән идек. Бистәнең туган якны өйрәнү музее хезмәткәрләре: «Бездә руслар һәм марилар да татарча сөйләшә», – дип аңлатты.

Район башлыгы Әлфит Ибраев үз чыгышында искәрткәнчә, татар халкы күренекле галимнәргә һәм мәгърифәтчеләргә бай. Мари Эл республикасында да тарихта данлы эзен калдырган милләттәшләребез шактый. «Кызганыч, бу дәрәҗәле шәхесләрне барлау эше моңарчы читтә калып килде. Дин өлкәсендә зур эз калдыручыларны шушылай олылау киләчәк буынны тәрбияләү өчен мөһим», – диде А.Ибраев.

Сөембикә КАШАПОВА.
Автор фотолары.

Авыл эте Акбай

Сезон ачылып аз гына вакыт үтте, «Әкият» Татар дәүләт курчак театры сәнгать сөючеләрне Т.Миңнуллин әсәре буенча куелган «Авыл эте Акбай» спектакле белән сөендерде. Берничә буын милләт балаларын тәрбияләп үстергән Акбайга театрның баш режиссеры Илгиз Зәйниев җан өргән.

Спектакль Екатерина Спиридонова иҗат иткән матур сәхнә сурәте һәм композитор Марат Әхмәтшинның җырлары белән җәлеп итә. Бер сәгать чамасы дәвам иткән тамашада сигез җыр яңгырый. Җырларның жанр төрлелеге шулай ук спектакльне баета. Татар халык җыры, рэп, шансон һәм тагын нинди генә җырлар юк монда! Бүген театр белгечләре, нәни тамашачылар театрында курчак югала, дип чаң кага. Дөрестән дә, чын курчак спектакльләре хәзерге заманда тансык күренешкә әйләнде. «Авыл эте Акбай» тамашасында исә ширма өстендә гел курчаклар гына уйный. Ара-тирә планшет-курчакларның күренеп китүе һәм шәүләләр театры чалымнары спектакльне тагын да баетып җибәрә.

«Авыл эте Акбай» – бәхетле сәхнә язмышлы әсәр. Ул күп мәртәбә Г.Камал театрында сәхнәләштерелде. Әсхәт Хисмәт башкаруындагы Акбай, Люция Хәмитнең чытлык Чарлие, Фирая Әкбәрованың Дүрткүзе, Рушания Юкачеваның Тәмлетамагы хәтердә һаман яши әле. 2013 елда яшь режиссер Лилия Әхмәтова бу әсәрне яңа буын актерлар белән сәхнәләштерде һәм бу спектакль шулай ук уңыш белән барды. Курчак театрында исә Акбайны 1998 елда Илдар Хәйруллин бер сәхнәләштергән булган инде. Бу яңа куелышта рольләрне Нияз Садыйков (Акбай), Юрий Чуктиев (Бүре, Күсе), Ришат Гыйздәтуллин (Сарбай), Рәмзия Фәйзуллина (Актырнак), Гөлнур Габдрахманова (Актүш), Фәнзилә Сабирова (Дүрткүз), Миләүшә Фәйзрахманова (Муйнак), Марс Гайфуллин (Бульдог) башкара, Тәмлетамакны Альбина Шаһгалиева һәм Ләйсән Миннәхмәтова чиратлашып уйный.

Көч түкмичә генә кәеф-сафа корып яшәргә омтылып авылдан качучыларны, туган телгә кирәксез дип караучыларны фаш иткән, дуслыкны, тугрылыкны алга сөргән бу «җылы» әсәр бүген генә иҗат ителгән сыман. Т.Миңнуллинның замана проблемалары, фәлсәфи мәсьәләләрне хайваннар аша гади генә тасвирлау сәләтенә сокланмыйча мөмкин түгел. Спектакльдәге һәр сүз көн кадагына суга. «Бүреләр хәзер көтүләре белән йөрмиләр, берән-сәрән генә калды. Ана этләр урманга килеп, бүре башларын әйләндерә, шуннан көчекләр туа. Алар ни эт, ни бүре түгел. Бүре нәселе корып бара. Шуңа күрә этләрне урманга кертмибез», – дип бүренең Акбайга зарын сөйләве нәкъ бүгенге тормыштан алып язылган сыман. «Урам этенең исеме булмый», «Кулга күтәрткән эт этмени?» ише гади генә булса да, мәгънәле сүзләр белән шыплап тулган бу спектакль. «Без кешеләр хөкемендә. Алар яхшы булса, без дә яхшы, алар начар булса, без дә начар. Мәрхәмәтлерәк булсыннар иде», – диюләре белән спектакльдәге этләр нәни тамашачыларның күңеленә табигатькә, тереклеккә, һәр җан иясенә карата миһербанлык орлыгы сала. «Элек бүреләргә каршы торучы этләр булган. Әллә нишләдек без», – дигән сүзләр адәм балаларының ваклануын, элеккеге куәтен югалтуын искәртә сыман. «Хуҗаң ат җигә. Бәхетле эт икәнсең. Их, җәйләрен ат арбасы астында ятулар! Кыш чанага утырып йөрүләр», – дип Сарбайның Акбай белән гәп коруы авыл романтикасын күзалдына китереп бастыра. Әсәрдә һәр сүз авылга, табигатькә, тормышка, хезмәткә мәхәббәт белән сугарылган. Болар кешене чирлегә әйләндергән, ялкауга чыгарган, чын яшәү мәгънәсеннән, асылыннан ерагаерга мәҗбүр иткән, гадәт-йоланы оныттырган шәһәргә каршы куела.

Тормышта җиңеллек, кызык кына эзләгән Тәмлетамак исемле песинең «Беркемгә кирәкмәгәч кайттым инде, тычкан да тотар идем», – дип кире авылга кайтып егылуында Туфан аганың сәламәт рухлы тормышка, табигатькә якын булып яшәүгә, милли асылга, хезмәткә кайтырга чакыруы булып ишетелә.

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Мәдәни җомга

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ – «ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир

Вахит Шәех улы ИМАМОВ

Җаваплы сәркатип Илгизәр ЗӘКИЕВ

Шылтыратыгыз:

222-09-83 (1562) – кабул итү бүлмәсе;

222-05-47 (1560) – җаваплы сәркатип, компьютер үзәге;

222-05-47 (1561) – иҗтимагый-сәяси тормыш, мәгариф һәм фән, сәнгать бүлекләре; хатлар һәм социаль көнкүреш, тәрҗемә бүлекләре;

222-09-84 (1266) – бухгалтерия.

Реклама хезмәте телефоны: (843)222-05-47 (1560)

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсенә күзәтчелек итү федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2019 елның 9 октябрендә ПИ №ФС 77–76961 нче санлы теркәү таныклыгы алды

Индекс П2355

Авторлар фикере редакция фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин

Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк

Хатлар, кульъязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

© Газетада чыккан материалларны күчереп бастырганда редакциядән язмача рөхсәт алу мәҗбүри

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:

ИНН 1655144950 КПП 165802012
ПАО «АК БАРС» банк, г. Казань
р/с 40702810600020010312
к/с 30101810000000000805
БИК 049205805 ОГРН 1021600000124

НӘШЕР ИТҮЧЕ – «ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан, Академия урамы, 2

Редакция, гамәлгә куючы һәм басмаханәнең адресы:

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2

E-mail: m-jomga@mail.ru

«Мәдәни җомга» газетасы Интернетта: www.madanizhomga.ru

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре хакында 562-10-61 номерлы телефон буенча шылтыратырга

Газета һәр атнаның җомга көнендә чыга. Бу санның чыгу көне 30.09.2022

График буенча бу санга 15 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 14 сәгать 30 минутта.

«Татмедиа» АҖ филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды

Газетаның сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 2600 данә

Заказ 2775

16+